PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№3 (315) – МАРТ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Шәймиева фамилиясен йөртүче хатын-кызлар турында

«Тел маркасын» тоткан әдип

Кубрат хан васыяте

АЛИНӘ ЗАҺИТОВА: ТАТАР КЫЗЫН ДӨНЬЯ АЛКЫШЛЫЙ

4 612750 670011

PRESSA.RU



16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Хәмидә Гарипова, Ксения Сёмина,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова,
Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: 2018 елгы Олимпия чемпионкасы
Алинә Заһитова. Фото «Студия-38» тарафыннан
тәкъдим ителде (Мәскәү ш., фото-видеолар җитештерү)

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: **3500** данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-612

Басарга кул куелды: 23.03.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Коммерция бүлеге белгече:
Екатерина Благодарова,
eblagodarova@inbox.ru, тел. (843) 222-09-76

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ЯЗ ИЛЧЕЛӘРЕ

Ярый, сайлаулар артта калды, ди, аның каравы, алда безне яз көтә. Һәм ул язны, сәяси карашлары нинди булуга карамастан, илебезнең барлык гражданнары да зарыгып көтә. Яз ул – сәясәттән азат, кочагына һәркемне алырга әзер. Хәер, аның хакында җәмгыятьтә тулы консенсус хөкем сөрә, шуңа ул, ниһаять, килеп җитсә дә, начар булмас иде инде. Әлеге шатлыклы мизгелне китереп җиткерер һәм, кышның бетмәс-төкәнмәс сөременнән талчыккан кешеләрне эрегән боз сөңгеләреннән өзелгән тамчылар чыңына, кардан арчылып килгән җирнең хуш исенә акрынлап ияләштерер өчен, бу саныбызны гүзәл затларыбызга багышларга булдык. Чөнки туташлар вә ханымнар – Язның тулы вәкаләтле илчеләре алар.

Бу санда сез безнең атаклы спортчыларыбыз һәм аларны җиңүгә нәрсә илһамландыруы турында укый аласыз. Спортта гына түгел, ә тормышта да җиңеп яши белүче әбиләр белән танышу мөмкинлеге бар – алар зирәк тә, сөйкемле дә, тәвәккәл дә. Алар әле коммунизмның һичшиксез җиңеп чыгасына һаман да чын күңелдән ышана, совет гаиләсенең һәрберсенең аерым фатирга лаек булачагына да. Дәүләт кайгыртуы астында – картлар йортында яшәүче бу гүзәл затларыбыз туган партияләренә дә, хакимияткә дә хыяллары чынга ашмаган өчен ачу сакламый. Алар инде тормышның күпкә катлаулырак икәнен әллә кайчан аңлаган, шуңа да фотограф камерасына карап елмаялар гына. Фотоларына карыйсың да, уйлап куясың: безнең укучы Олимпия чемпионнарын гына түгел, ә менә шушы әбекәйләр турында да укып белергә тиеш. Тормыш контрастларын тагын да аныграк күрер өчен.

Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиевның тормыш иптәше Сәкинә ханым турында да укый аласыз бу санда. Аның еллар буена гаилә учагын ничек сүндерми саклавы турында олы ихтирам һәм соклану белән сөйли Минтимер Шәрипович. Юкса инде без аларның үзләрен дә, мәхәббәт тарихларын да, тормышларын да бик яхшы беләбез шикелле, әмма юк, белеп бетермибез икән әле…

Әле тагын, тагын да санарга мөмкин кызыклы материалларны. Әмма сезгә алар турында уку түгел, ә үзләре белән танышу кызыклырак булыр, дип уйлыйбыз. Ул арада Яз да үз вәкаләтләре турында искә төшерер. Җилдереп килеп тә җитәр, хакимлек итәргә дә керешер. Юллары уң булсын! Булыр, һичшиксез, чөнки без юлларны җәя беләбез, әле ничек кенә!

Журнал битләрендә очрашканчы!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Кондрат Максимов. «Зимняя избушка». Раифа. 1958 ел. Кирилл Пономарёв коллекциясеннән

МАРТ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. «Безне «хыял командасы» дип атыйлар иде...»
Дөнья гимнастикасы йолдызы белән сөйләшү

6. Идеаль документны ничек тутырырга.
Муниципалитетлар өчен укулар

8. Татар авыллары эшкуарлары җыены.
Авыл кемнәре белән матур

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

12. Тагын бер кат мәхәббәт турында.
Беренче Президентның яраткан хатын-кызлары

19. Матурлыкның яше юк.
Картлар йортында әбиләр өчен бәйрәм

32. Авыр хәлдә калган хатын-кызларга ярдәм кулы.
«Бишек» социаль проекты.

36. Редакция кухнясы кунагы.
Илнар Ямаловтан татарчалаштырылган француз тәм-томы

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

42. Татар әдәбияты аксакалы.
Фатих Хөсни эзләре буйлап

48. Тарих сәхифәләре.
Бөек Болгар дәүләте һәм Хәзәр каганлыгы идарәчеләре

52. Безнең киштәдә.
«Оскар-2018» турында уйланулар

58. Ютазы районы.
Ни өчен үзгәреш җилләре көньяк-көнчыгыштан исә

84. Татар авыллары.
Могҗизалы Сәпәй

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

3. 03

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – республикадагы «Россия-2018» оештыру комитеты утырышында:

– Дөнья чемпионаты футболчылар өчен стадионнар һәм тренировка базалары әзерләү дигән сүз генә түгел ул. Гомумән, Казан илебезнең визит карточкасы булачак. Шәһәрнең үзен илебездәге яхшы калалардан берсе генә түгел, хәтта ки иң яхшысы итеп күрсәтүе кирәк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

5. 03



Минтимер Шәймиев, Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, – «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» конкурсының бүләкләү тантанасында:

– Миһербанлыкта хатын-кыз йөрәгенә тиңнәр юк. Ә без, ир-атлар, тагын да яхшырак булырга, 8 мартны лаеклы итеп билгеләп үтәргә, хатын-кызны ахырынача тыңларга тиеш – бу көндә генә түгел, ә ел буе. Безне орышалар икән, димәк, юкка түгел. Хатын-кызлар, сабыр итеп, һәрнәрсәгә түзә икән, димәк, без дә алардан калышмаска тиеш.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

2. 03

Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан мөфтие, – Астанада, «Евразия киңлегендә ислам цивилизациясе: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» дип исемләнгән Евразия голәмәләре форумында:

– Татар дин галимнәренең бәһасез хезмәтләрендә һәм карашларында без дустанә һәм сабыр исламның нигезләрен күрәбез. Иң күренекле татар дин әһелләре дөньяви белемнәрне ислам дине мәгариф системасына кертү ягында булган, шуңа күрә аларның мирасында беренче карашка шактый каршылыклы булган Европа һәм Азия, Көнбатыш һәм Көнчыгыш, ислам һәм христиан, төрки дөнья һәм рус мәдәниятләренең үзара керешеп китүе күзәтелә. Нәтиҗәдә, төрле милләтләр һәм диннәрнең тату яшәве кебек тиңдәшсез, бөек рухи үрнәк барлыкка килә.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Хыялың командасына **НИЧЕК** эләгергә

Идеаль документны **НИЧЕК** тутырырга

Татар эшкуарлары **НИГӘ** Казанга килгән

PRESSA.RU

Дарья Шкурихина – гимнастка, Пекинда узган 2008 елгы Олимпия уеннары чемпионы, нәфис гимнастиканың күп төрен берләштергән бәйгедә һәм аерым төрләрдә 2007 елгы дөнья чемпионы, ике тапкыр – 2006 һәм 2008 елларда – Европа чемпионы. Россиянең нәфис гимнастика буенча җыелма командасы (төркемле күнегүләр) составында чыгыш ясый. Спорт карьерасын тәмамлагач, Түбән Новгородта нәфис гимнастика буенча үз мәктәбен ача. Казанда ел саен уздырыла торган «Уңыш биеклегендә» нәфис гимнастика турнирының директоры вазыйфасын башкара. 2008 елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнә.

КЕЛӘМГӘ – **БӘЙРӘМГӘ ЧЫККАНДАЙ**

Аларны «dream team» – хыял командасы дип атыйлар иде. Нәфис гимнастикада төркемле күнегүләр буенча Россия җыелма командасының чираттагы буыны аларның дөнья чемпионатындагы уңышын 7 елдан соң гына кабатлый алды. Пекиндагы Олимпиадада һәрберсе диярлек травма белән – булган мөмкинлекләрнең чигендә чыгыш ясады. Һәм җиңүгә иреште! Дөнья гимнастикасындагы «йолдыз»ларның берсе Казан кызы Дарья Шкурихина иде.

АЛТЫН БӘҺАСЕ

Ул төндә командадан беребез дә йокламады. Дулкынлану дәрәҗәсе искиткеч, йөрәк чыгып китәрдәй булып тибә. Иртәгә язмышның хәл ителгәнен аңлыйсың. Җаваплылык гаять зур: Россия нәфис гимнастикада инде күптән җиңелү белми...

Һәм менә – Олимпиада финалы! Келәмгә чыгарга һәм мөмкин кадәр – хәлеңнән килгәнчә яхшы итеп чыгыш ясарга гына кирәк. Тезелешеп бастык та алга атладык... Чыгышыбызның бер мизгелендә «менә-менә, хәзер бетә, бик аз гына калды» дигән уй билләп ала, ләкин ялгыш, хәтта бик кечкенәсе дә алтын медаль бәһасе торырга мөмкин. «Ярый! – дим үз-үземә. – Туктат әле бу уйларыңны, үзеңне кулга ал һәм бөтенесен ахыргача чиста итеп башкарып чык!»

Программабызда соңгы ноктаны куйганда, елап җибәрдек. Йөрәк тоя: булды, без – олимпия чемпионнары! Әмма төп көндәшләребез соңрак чыгыш ясый иде әле. Капитаныбыз Лена Посевина шулчак сабыр итәргә чакырды: «Кызлар, нәтиҗә ясарга ашыкмагыз. Әйдәгез, бөтен бәяләрне дә көтеп бетерик». Баллар барысын да раслады.

СПОРТКА НИЧЕК ГАШЫЙК БУЛЫРГА?

Кумирларым беркайчан да булмады. Ә менә илһам, көч биргән кешеләр бар иде – күренекле гимнастлар Алинә Кабаева, Ирина Чащина... Мин интернеттан аларның чыгышларын караганнан соң, бер кочак фотосурәтләрен бастырып, өй диварларына элепябыштырып куя идем.

Ә ярышларны беренче тапкыр биш яшьлек чагымда нәфис гимнастика буенча спорт мәктәбендә күрдем. Ул вакытта әле бу уку йорты Казанның Горький исемендәге паркында урнашкан иде. Тасмалы кызлар шундый матур! Менә әнием мине беренче остазым Ләйсән Савицкая белән таныштыра. «Даша, ә син нәрсә ашарга яратасың?» – дип сорады шулчакта ул миннән. «Сумса һәм макарон!» – дип ихлас җавап бирдем. Ә ул елмая: «Ничек инде? Гимнаст кызлар андый нәрсәләр ашамый». Мин, ике дә уйлап тормастан, әниемә ярып салам: «Алайса мин гимнастика белән шөгыльләнмәячәкмен!». Бәхеткә, мине һичкайчан диета белән интектермәделәр. Әнием үсмер организмына энергия кирәк икәнен бик шәп аңлый иде. Инде спортта карьерамны тәмамлагач, бер сөйләшүдә ул йөрәгендә йөрткәнен әйтте: минем чемпион буласымны әнием һәрвакыт белгән. Менә шундый сизгерлек! Кадерле кешем һәрчак янәшәмдә

Фотолар Дарья Шкурихинаның шәхси архивыннан алынды

булды, ярдәм итте, рухландырды, ләкин гимнастикага мине чын-чынлап гашыйк итүче, әлбәттә, Ләйсән Инсафовна иде. Ансыз бернәрсә дә килеп чыкмас иде, дип уйлыйм. Мөгаен, беренче тренер нәкъ менә шундый булырга тиештер дә!

I'LL BE BACK*

Россия җыелма командасына юлым шактый урау булды. Атаклы тренер һәм педагог Ирина Александровна Винер-Усманова кул астында шөгыльләнер өчен Олимпия авылына Ләйсән ханым белән бергә килдем. Ул чакта миңа нибары унике яшь иде, һәм Мәскәүдәге шул тәүге елым спорт карьерамдагы иң авыры да булды. Физик яктан гына түгел, рухи яктан да кыенга туры килде. Нәфис гимнастика кайсыдыр ягы белән балетка охшаган – келәмдә барысы да җиңел һәм матур кебек күренә, ләкин моның өчен күпме хезмәт, сабырлык сорала... Япониядә узарга тиешле, минем өчен беренче дөнья чемпионатына Россия җыелма командасы составында әзерләндем, тик тренировка вакытында иң гади күнегүләрнең берсен эшләгәндә, аягымны сындырдым. Бу минем өчен шок булды. Казанга кайтырга, дәваланырга, укырга туры килде. Гипсны алу белән, мин спорт залына юл тоттым. Аяк шулкадәр авыртa, гүя мин аны әле яңа гына сындырганмын. Яңадан рентгенга төшердек, чатнаган урын төзәлмәгән булып чыкты... Гимнастикага кайта алмам дигән курку булдымы икән миндә, белмим. Андый теләгем дә юк иде инде! Мин башка ритмга күчеп беттем – рәхәтләнеп укый башладым, буш вакытлар да пәйда булды... Спортка кайтуымда әнием һәм тренерым мөһим роль уйнады. Аяк сыну аркасында шактый тазарып киттем. Ләйсән ханым сүзе белән әйтсәк, залга «атлап түгел, тәгәрәп» кердем...

ХЫЯЛ КОМАНДАСЫ

Без әллә ни әһәмиятле булмаган ярышларда чыгыш ясап, пыран-заран җиңелергә мөмкин идек. «Менә, Россия командасы шиңеп, төшеп бетте», – дип сөйли башлыйлар андый чакта. Ләкин Европа яки дөнья чемпионатына килүебез була... Үзебезне кулга ала беләбез бит! 2006 елда Мәскәүдә узган Европа чемпионатында алтын медальләрнең барысын да алып бетердек – безгә кадәр инде күп еллар моны берәү дә булдыра алмаган иде. Дөнья чемпионатында да шундый ук нәтиҗәгә ирештек. Безнең команда киткәч, Россиянең төркемле күнегүләр буенча җыелма командасы дөнья чемпионатының күп төрне берләштергән бәйгесендә 7 елдан соң гына алтын медаль яулый алды.

Командабызга әледән-әле төрле кызларны кертергә тырыштылар. Тик, беләсезме, әйтерсең лә, ул шул алты кешедән җыелган пазл: кайсыдыр бер «деталь»не алыштырасың гына – инде тулы сурәт килеп чыга алмый. Югыйсә тренировкаларда яңа кыз белән барысын да кабатлыйбыз, өйрәнәбез, ә ярышларда ничектер башкача...

Нәфис гимнастика буенча Россия җыелма командасының баш тренеры Валентина Алексеевна Иваницкая: «Команда эчендә барысы да әйбәт булганда, бөтен нәрсә шәп булачак», – дип, еш кабатлый иде. Вак-төяк низагларның һәрберсе келәмдә хата булып чагыла. Шуңа күрә без һәрчак катлаулы мизгелләрне урап узарга, дус булырга, бер-беребезгә булышырга тырыша идек. Төрле шәһәрләрдә яшәсәк тә, хәзер дә аралашып-сөйләшеп торабыз.

...Безнең йолдыз итеп күккә чөйгән Пекин Олимпиадасына бөтенебез дә диярлек травмалар белән килдек. Аеруча Аня Гавриленконың хәле авыр: аның тубык буыны сеңерләре өзелгән иде. Аннан башка җиңә алмаячагыбызны аңлыйбыз, һәм ул безне ташламады. Ярышларга бер атна кала, аягымны каймыктырдым. Бик көчле авырту көйдереп алды, елап басып торам, аска карарга да куркам. Кыюлыгымны җыеп, күз ташласам – аяк шешкән, күгәреп чыккан – мондый травманы бер атнада дәвалап бетереп булмый. Бөтенебезгә дә тешне кысып, бар үҗәтлекне эшкә җигеп чыгыш ясарга туры килде. Һәм без җиңдек! Шундый искиткеч җиңүдән соң нәфис гимнастика буенча төркемле күнегүләрдә Россия җыелма командасының тулысынча спорт карьерасын тәмамлавы турындагы хәбәр бөтен дөнья өчен шок булды.

ЯЗМЫШ ХӘБӘРЕ

Безне Мәскәүдә хөрмәтләп кунак итеп, машина ачкычлары тапшырырга тиеш иделәр, ә без исә арудан аякта көчкә басып торабыз, монда физик ару гына түгел, рухи талчыгу да бар иде. Ял итәсе генә килә, ләкин Олимпиада тәмамланып дүрт көн узуга, янә йончыткыч тренировкаларны башлап җибәрергә тиешбез. Юк, без моңа әзер түгел идек. Без бит әле шактый яшь тә, әйтик, миңа унҗиде яшь кенә иде. Ул вакыттагы карарым дөрес булмагандыр, дип уйлыйм. Спортка кайтырга тырышып карарга кирәк булган, ләкин «ничек инде мин – командасыз?» дигән курку бу адымны ясарга ирек бирмәде...

Лондонда узган чираттагы Олимпиадада күз яшьләрем елга булып акты. Мин безнең гимнаст кызлар өчен сөенеп утырдым һәм үземне алар янәшәсендә күрә идем, тик трибунада түгел, ә келәмле мәйданчыкта. Мин әле ярыш рухы белән ахыргача туенып бетмәгән булганмын, бәйге мәйданчыгына чыгасым килде! Андый зур ярышлардагы кебек хис-кичерешләрне башка һичкайда тоя алмыйсың. Ул кичерешләрне соңыннан һәрвакыт эзлисең, тик алар инде башка юк... Лондоннан кайткач, фатирыма бикләнеп, бик озак беркая чыкмый яттым. Күңелне бушлык биләп алган иде.

Тормышымны нәфис гимнастика буенча Россия яшүсмерләр җыелма командасының баш тренеры Екатерина Сиротинаның шалтыратуы үзгәртеп куйды. «Даша, әзерлек җыеннары Казанда узачак. Бераз эшләп алырга теләмисеңме?» – диде ул. Җыеннар Васильево бистәсендә үтәчәк ди, ә анда – яраткан әбием белән бабамның дачалары! Язмыш хәбәреме? Һәм менә алдымда егерме бала, ә мин алар белән нишләргә кирәклеген белмим... «Исәнмесез, минем исемем Дарья». Шунда ук Екатерина Сергеевнадан катгый шелтә ишетәм: «Нинди Дарья булсын ди?! Дарья Валерьевна!» Һәм шул бер көн миңа җитә калды. Төрле шәһәрләргә җыеннарга йөреп, укыта башладым. Ошап китте! Гүя канатлар үсте, үз эшемне булдыру, нульдән башлау теләге туды. Әнә шулай итеп Түбән Новгородта мәктәбем пәйда булды. Ни өчен Казанда түгелме? Фатир мәсьәләсе барысын да хәл итеп куйды – аны Түбән Новгород өлкәсе губернаторы бүләк итте. Мин аңа бик рәхмәтле. Тик туган шәһәремне дә онытмыйм: Казанда ел саен «Уңыш биеклегендә» дип исемләнгән нәфис гимнастика бәйгесе уза. ■

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

Әзерләде:
Ольга Туманская

* Мин кайтырмын – инглизчәдән тәрҗемә

УРЫННАРДА **ЯКЛАУ**

Норматив-хокукый документ – теләсә кайсы муниципаль берәмлек эшчәнлегенең һәм үсешенең нигезе. Татарстан һәм аның муниципалитетларының Россиядәге һәм чит илләрдәге партнерлар һәм инвесторлар арасында популярлыгы үсүне күздә тотканда, мондый документның тел тидермәслек булуы шул исәптән район һәм аның җитәкчесе имиджы өчен дә бик мөһим. Әлеге тезислар март башында Татарстан Юстиция министрлыгы базасында үткән һәм Казан федераль университеты Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе катнашында оештырылган муниципаль хезмәткәрләрнең ике көнлек стажировкасының нигезен тәшкил итә.

Автор:
Ксения Сёмина

– Хәтерегезгә төшерәм: җирлек чикләрен үзгәртү процессының беренче этабында аның башлыгы картографик материалларны килештерә һәм имзалый, ә бу вакытта җирлекнең вәкиллекле органы тарафыннан чикләрне үзгәртү инициативасы турындагы карары проекты әзерләнә. Әлеге карар проектын халык алдында тыңлау һәм тикшерү вакыты билгеләнә һәм ул үткәрелә. Шуннан соңгысы – җирле үзидарә органы вәкаләте. Ул чикләрне үзгәртү инициативасы кертелү турында карар кабул итә һәм тавышка куя. Әгәр бу мәҗбүри булса, гражданнарны җыелышка җыя, – дип аңлата аудиториягә ТР Юстиция министрлыгының территориаль оештыру һәм җирле үзидарә сферасын контрольдә тоту мәсьәләләре бүлеге башлыгы Гөлнара Касыймова.

– Ягъни мәсәлән, җирлек чикләрен үзгәртү процессында гражданнар җыелышы үткәрелмәскә дә мөмкинме? – дип ачыклamakчы була тыңлаучылардан берсе.

– Бары тик җирлектә яшәүче сайлау хокукына ия кешеләр саны 100 дән артмаган очракларда гына. Яисә, җирлектә 100 дән 300 гә кадәр халык яшәгәндә һәм җыелыш үткәрү зарурлыгы муниципаль берәмлек уставында беркетелгән булса, – дип аңлата лектор.

Муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү һәм торак пунктлар оештыру мәсьәләләренә багышланган әлеге практикум – министрлык тарафыннан Югары мәктәп белгечләре катнашында төзелгән бай программаның бер өлеше генә. Аңа коррупциягә каршы экспертиза үткәрүгә, муниципаль берәмлекләрнең үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкаруына, муниципаль берәмлек хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен юридик яклауга, җирле үзидарә органнарындагы кадрлар белән эшнең хокукый нечкәлекләренә караган мәсьәләләр кертелгән.

Аерым блок Татарстан муниципаль норматив хокукый актлары регистрына багышланган. Алып баручылар искәрткәнчә, документның гомумреспублика базасында булуы аның исәпкә алынуын гарантияли, шулай ук аның хокуклылыгын раслый.

– Документларны регистрга вакытында кертер өчен, сезгә районда кабул ителгән барлык норматив документлар реестрын алып бару зарур. Әгәр сезнең районда реестр әле кабул ителмәгән булса, димәк, тиз арада кабул итү зарур, аны алып бару даими булырга тиеш. Бу инструментны сез, беренчедән, үзегезне контрольдә тоту өчен, икенчедән, законсызлык мөмкинлекләрен киметү өчен файдаланасыз. Якын арада без муниципалитетларның реестр алып баруын контрольдә тоту ысулларын эшләячәкбез, – диде ТР Юстиция министрлыгының җирле үзидарә сферасында норматив-хокукый эш һәм муниципаль регистр алып бару бүлеге башлыгы Рәүф Гарипов.

Стажировка нәтиҗәләрен тикшерүгә багышланган түгәрәк өстәл программаның йомгаклау чарасы булды. Татарстан юстиция министры урынбасары Мөхәррәм Ибәтов тагын бер кат стажировканың аерууча мөһим моментларына тукталды, шулай ук республика муниципалитетлары юридик бүлекләре хезмәткәрләре өчен министрлыкның яңа белем бирү чараларын планлаштыруын хәбәр итте. Аерым алганда, «Дәүләт һәм муниципалитет-

Фотолар КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбеннән алынды

Реклама 16+

лар ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контрактлы система турында» 44 нче ФЗ буенча эшләү өчен һәм муниципаль контроль үткәргәндә эшкуарлыкны яклау мәсьәләләренә багышланган семинарлар үткәрү күздә тотыла.

– Республика Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән Икътисад министрлыгының йомгаклау коллегиясендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү белән шөгыльләнмәгән районнарны каты тәнкыйтьләде. Мин шунысын да әйтер идем: биредә күп нәрсә районнарның юридик бүлекләренә дә бәйле – ярдәм ташламалар сыйфатында да, төрле карар һәм күрсәтмәләрне гамәлгә кертү срокларын чигерү юлы белән дә күрсәтелергә мөмкин бит, әлбәттә инде, закон кысаларында. Мәсәлән, былтыр эшкуарлар өчен кисәтү кебек административ җәза кертелде. Аны куллану нигезләнмәгән карарлар санын шактый киметергә мөмкин. Эшкуарлар юристларның ярдәмен һәм яклавын тоярга тиеш, бигрәк тә кечкенә районнарда – анда кече һәм урта бизнесны үстерү шактый кыенга туры килә, – диде Мөхәррәм Ибәтов.

Ул шулай ук стажерлардан гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, норматив актларны татарчага тәрҗемә итү, җирле үзидарә турындагы республика законындагы үзгәрешләр, «Кодекс» системасы белән эшләү кебек мәсьәләләрне киләчәктә дә контрольдә тотуларын үтенде.

– Безгә сезнең белән адекват кире элемтә кирәк. Без киләчәктә дә мондый өйрәтү чараларын үткәрүне планлаштырабыз, безнең ресурсларыбыз да, Югары мәктәп ярдәме дә бар, әмма темалар һәм форматлар сайлау өчен без муниципалитетларның нинди мәгълүматка мохтаҗ булуын аңларга тиеш. Безнең моңа охшаш күп кенә сораштыруларыбызга районнар еш кына формаль җавап бирә. Без сезнең моңа җаваплырак каравыгызны теләр идек, – дип мөрәҗәгать итте түгәрәк өстәл барышында тыңлаучыларга ТР Юстиция министрлыгының җирле үзидарә органнарына хокукый консультатив-методик ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы Майя Пашкова.

Икенче көн Татарстан юстиция министры Рөстәм Заһидуллинның тыңлаучыларга таныклыклар тапшыруы белән тәмамланды.

“ – Без районнардагы юристлардан нинди дә булса нигез сораулар буенча даими рәвештә күпсанлы шалтыратулар кабул итәбез. Мондый төр стажировкалар исә аларга кайбер мәсьәләләргә тирәнрәк төшенергә мөмкинлек бирә, шулай ук үзләрен ышанычлырак итеп тоярга да.

Татарстан Республикасы юстиция министры Рөстәм Заһидуллин:

– Муниципалитет дәрәҗәсендә әзерләнә торган барлык норматив-хокукый документация юридик экспертиза үтәргә, идеалда исә – юристның турыдан-туры катнашында әзерләнергә тиеш. Әлеге сфера муниципалитет яшәеше һәм үсеше өчен нигез булып тора. Шунлыктан без базабызда район белгечләренең пилот стажировкасы үткәрелгән тәүге министрлык булдык. Программа министрлык эше спецификасын исәпкә алып төзелде. Өйрәтүгә эш стажы бер елдан артык булмаган юристларны чакырганга, программага база юнәлешләре кертелгән иде, чөнки аларны яхшылап үзләштерми торып, нәтиҗәле эшләп булмый. Без сорауларның һәр блогын кирәкле актуаль типлаштырылган документ һәм формалар җыелмасы белән тулыландырдык. Программа катнашучылар саны аз булуны күздә тота, чөнки җитди һәм катлаулы темалар шәхси якын килүне таләп итә. Һәм шул рәвешле без ышана алабыз – белгеч материалны үзләштерде һәм, мәсәлән, норматив актны дөрес төзеячәк яки муниципалитетны судта лаеклы яклый алачак. Безгә нинди дә база сораулары буенча даими рәвештә район юристлары шылтырата. Мондый стажировкалар аларга дөрес җаваплар табарга һәм үзләренә ышанычны арттырырга ярдәм итәчәк. Әлбәттә инде, без аларга теләсә нинди консультатив ярдәм күрсәтергә әзер, һәм министрлыкның максаты әле тагын шунда да: стажировкаларда катнашучылар аның бөтен хезмәткәрләре белән шәхси танышсын һәм кемгә нинди сорау белән мөрәҗәгать итәргә кирәген белсен.

КФУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Игорь Привалов:

– Бу программа – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның дәүләт хезмәткәрләренә стажировка үткәрү күрсәтмәсен үтәү нәтиҗәсе. Проектның төп бурычларыннан берсе – муниципалитетлар белән эш, чөнки анда норматив-хокукый документация базасын әзерләү һәм алып бару кайвакыт тиешле таләпләргә туры килми. Татарстан Юстиция министрлыгы стажировканы әзерләү өчен вакыт һәм кадрлар ресурсларын бүлде, һәм бу, һичшиксез, зур файда китерәчәк. Беренче чиратта – министрлыкның үзенә, чөнки ул, район юристларының һөнәри дәрәҗәсен күтәрү хисабына, урыннардагы юридик потенциалга хуҗа булачак. Укыту ике көн генә барды, әлбәттә, бу вакыт эчендә бөтен нәрсәне колачлау мөмкин түгел. Әмма әлеге проект дәвам итәчәк, һәм без аны, укып киткән белгечләр фикеренә таянып, үзгәртәчәкбез, яхшыртачакбыз. Моннан тыш, без хәзер министрлык белән бергә кире стажировка планын да эшлибез – республика Юстиция министрлыгы хезмәткәрләрен муниципалитетларга җибәреп, аларга андагы вазгыятьне күрсәтергә ниятлибез. Министрлыкта беренче стажировканы үткән белгечләргә исә минем үз урыннарында озаграк эшләүләрен һәм үз районнарына мөмкин кадәр күбрәк һөнәри ярдәм күрсәтүләрен телисем килә.

Татарстанның Буа муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге белгече Дамира Хәкимова:

– Бу вазыйфамда мин әле берничә ай гына эшлим һәм стажировкада нәкъ менә муниципалитеттагы юридик эшчәнлек үзенчәлегенә кагылышлы күп яңа мәгълүмат алдым. Дәресләрдә безгә хокук бозу ачыкланган очракларда үзебезгә яки муниципалитетка нинди штрафлар салыначагы һәм җаваплылыкның башка төрләре турында тәфсилләп сөйләделәр. Әлбәттә, моның өчен сәбәпләр булмасын иде. Шунлыктан мин аеруча игътибар бирергә киңәш ителгән документ һәм регламентларны кайтуга ук тикшерүгә керештем. Безнең районда йөкләнеш шактый зур – 45 мең халыкка нибары ике юрист туры килә, шунлыктан мин хәзер, яңа алган белемнәремнән файдаланып, эшемдәге төп нәрсәләрне ачыкларга һәм иң әһәмиятле моментларны күздән ычкындырмаска тырышам. Стажировка мине илһамландырды, дип әйтеп була – без министрлык хезмәткәрләре белән таныштык, алар белән хезмәттәшлек итүдән, сораулар бирүдән курыкмаска кирәклеген аңладык – алар һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер икән бит. Минем киләчәктә әле тагын укыйсым килә, дистанцион рәвештә булса да баш тартмас идем. Тагын да җентекләбрәк өйрәнәсе актуаль темалар бар, мәсәлән, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда эшкуарларның хокукларын яклау кызыксындыра.

PRESSA.RU

«АВЫЛ ТОТКАЛАРЫ» ҖЫЕНЫ

Казанда 1 – 3 март көннәрендә VII Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары җыены узды. Шәхси эшкуарлар, бер-бер артлы президиумга күтәрелеп, үзләренең эшләре турында сөйләде, тәҗрибәләре белән уртаклашты. Ләкин башка еллардан аермалы буларак, бәлки, вазгыять белән дә бәйле рәвештә, быелгы җыенда «татар теле» сүзе ешрак яңгырады. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында узган чарада модератор – Бөтендөнья татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе башкарма директоры Фәрит Уразаев һәр чыгыш алдыннан: «Татарча сөйләгез», – дип торды. Чынлап та, чыгышлар, нигездә, татар телендә узды.

Автор:
Руфия Фазылова

«КАЙМАКЛАР...»

Чарага гаилә фермалары, шәхси хуҗалыклар, крестьян-фермерлык хуҗалыклары җыелган иде. Арада умартачылык белән шөгыльләнүчеләр, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртеп сатучылар да бар. Алдагы елларда килүчеләр, бер-берсенә кул биреп, якын дуслардай күрешә. Танышып, телефоннарын алышучыларны да күзәтергә туры килде. Әйе, җыенның максаты да татар эшкуарларын берләштерү, бер-берсе белән очраштыру, элемтәләр булдыру...

Бу фермер, эшкуарларны курыкмыйча «авылның каймаклары» дип әйтергә була. Беренчедән, алар фермер булып теркәлгәч, авылдашларын эшле иткән. Икенчедән, әлеге ир, ханымнар тырышлыклары өстенә документ эшен дә яхшы белә. Һәм икътисадны, илдә барган сәясәтне аңлап эш итә. Шунсыз фермер хуҗалыгын алып барып булмый. Ирләр иртән трактор, машинасына утырып үз кырына чыгып китсә, хатын-кызлар, җиң сызганып, хуҗалыгында эшли. Кичен фермерлар документ эше белән утыра. Салым инспекциясе, башка оешмалар алдында ай саен хисап тотарга кирәк чөнки... Ни өчен боларны язаммы? Заман белән бергә җир кешесе дә үзгәрә, диясем килә. Совет чорындагы кебек, колхоз эшенә барып кайту гына җитми. Үз эшеңне башлыйм дисәң, җиде кат туныңны салырга кирәк. Менә шуның өчен иң-иңнәре генә, курыкмыйча, фермерлык, эшкуарлыкка алына да.

Инде янә VII Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлар җыенына әйләнеп кайтыйк. Өч көнгә сузылды ул. Беренче көнне эшкуарлар ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында фикер алышса, икенче көнне Әлки районына сәфәр кылдылар. Биредә абыйлы-энеле Шәйхетдиновлар яши. Альберт абый авыл хуҗалыгы продукциясен җыю, сөт ташуда махсуслашкан. Егермедән артык махсус техникасы гына бар. Шулай ук зур гына автосервис төзегән. Туганы Дамир Шәйхетдинов исә көнбагыш мае ясап сата, орлыклы культуралар белән шөгыльләнә.

– Авыл җирлегендә нәрсә эшләп була, барысына да алынып карадык, – диде Дамир абый. – Авылдан читкә китәсе килмәде. Ә районда әллә ни мөмкинлекләр күп түгел: тимер юл да, су юлы да юк, шәһәрдән дә шактый ерак без. Шуңа күрә кул җитәрдәй эшкә алынырга булдык...

Шәйхетдиновлар 170 авылдаш, райондашларын эшле иткән.

Җыенның йомгаклау өлеше Казанда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында узды. Шунда ук Татарстанда, РФ төбәкләрендә җитештерелгән хәләл продукция һәм халык кәсебе товарлары күргәзмә-ярминкәсе оештырылган иде.

...Чарага килгән эшкуарлар белән сөйләшүдән рәхәтлек алып кайттым. Һәрберсенең үҗәтлеге, тырышлыгы сокландыра, гаҗәпләндерә. Авылда һичьюгында дүрт-биш кенә шундый кеше булса да, вазгыять икенче төрле булыр иде. Авыллар кабат яшьнәп китәр иде кебек.

Журнал укычыларыбызны да «ут күршеләребез» булган ике эшкуар белән таныштырырга булдык.

Фото: Александр Ефремов

Күршеләр ничек яши, аларның тәҗрибәсе нинди икән?

ЧУВАШИЯ УҢГАННАРЫ

Чувашиядән унлап эшкуар килгән иде, араларында азу ярганнары да, әле яңа гына эш башлаганнары да бар. Әсхәт Баһаветдинов белән Әмир Алимов Батыр районының Кыр Бикшеге авылыннан. Авыл чагыштырмача зур икән, 350 хуҗалык бар. Ике авылдаш, ике дус, егерме елдан бирле бергә җир эше белән шөгыльләнә. Дөрес, КФХ булып Әсхәт абый гына теркәлгән, ә Әмир Алимов Кыр Бикшеге авыл җирлеге башлыгы вазыйфасын башкара.

– Иген, яшелчә үстерәбез, – ди Әсхәт абый. – Нигездә, авылдашларның пай җирләренә чәчәбез, җирне арендага алдык. Барлыгы 250 гектар җир эшкәртәбез. Безгә колхоз заманыннан бирле эшкәртелми яткан җирләр эләкте. Менә шуларны акрынлап «терелтәбез». Каралмаган җирдән уңдырышлы туфрак ясау өчен берничә ел, шактый акча кирәк. Чувашиядә дә шул ук хәл: колхозлар таркалгач, хуҗалыклар ятим калды. Фермалар таралды, җирдә алабута үсеп утыра. Инде шөкер дим, соңгы елларда хәл аз булса яхшы якка үзгәрде. Хуҗасыз җирләр юк, барысын да фермерларга бүлеп бирделәр.

Әсхәт Баһаветдинов белән Әмир Алимов башта Ульяновск өлкәсендә эшләгәннәр, чөнки анда колхоз системасы иртәрәк беткән. Аннан Чувашиядә җирләр арендага бирелә башлагач, үзләренең пай җирләрен алганнар. Бүген инде аякта нык басып тора торган КФХга әйләнгәннәр. Ике комбайн, дүрт трактор, чәчү, уру җайланмалары – барысы да бар.

– Техниканы дәүләт программасы белән алдыгызмы? – дим.

–Юк, бездә бит Татарстандагыча түгел... Бездә Татарстандагы кебек җир пайлары да зур түгел, бер кешегә нибары 1 гектар да 43 сутый туры килә.

– Татарстанлылар да кәгазь эше күп, салым зур дип зарлана, – дим.

– Ә бездә бөтенләй диярлек бер программа да эшләми.

VII Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары җыенына Россия Федерациясенең 41 төбәгеннән һәм Татарстаннан 750 кече бизнес вәкиле һәм фермер хуҗалыклары җитәкчесе килгән иде.

Барысын да үз көчең белән генә эшлисең. Бердәнбер субсидия бирелә – элиталы орлык алырга. Әле КФХ булгач, эшчеләргә яхшы хезмәт хакы түләргә кушалар. Рәсми рәвештә эшләүче дүрт механизаторыбыз бар.

Кышын да тик тормый фермерлар. Әсхәт Баһаветдинов хуҗалыгында унике баш сыер бар. Кышын, нигездә, шул сөтне саткан акчага тормыш алып баралар. Хатыны, өч баласы бар. Малларны 7нче сыйныфта укучы улы караша. Олы кызы КФУны тәмамлап, Казан мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укыта.

– Картайган көндә бер «уенчык» алып кайттык, икенче сыйныфта укучы улыбыз бар, – дип елмайды эшкуар.

Фермерлар икенче проблема турында да сөйләде – җыелган игенне урнаштыру кыенга төшә икән. Иген уңмаган елны бәясе кыйммәт, ә уңган елны арзан. Киткән чыгымнар белән санасаң, әллә ни файдасы да калмый, диләр алар.

– Игенне саклау өчен амбарлар да бар, – диде Әмир Алимов. – Гадәттә, язын сатсаң, отышлырак була, игеннең бәясе кыйммәткәрәк чыга. Быел исә икеле, бәя артмас кебек, килосын биш сумнан сатабыз.

Эшкуарларның илле гектар җирендә карабодай үсә. Алдагы елларда бу культура отышлы булган, тик быел чыгымнар акланмаган.

– Әлеге дә баягы, уңыш күп булган елны карабодайның да бәясе түбән, – ди Әмир абый. – Узган ел 17 сумнан саттык, быел – 7 сум. Ике тапкырга диярлек ким бит. Узган ел карабодай саткан акча язгы чәчүгә кадәр ягулык алырга җитте, быел юк...

Фермерлар карабодайны кырдан җыеп ала да эшкәртергә, чистартырга читкә алып бара. Махсус җайланмалар сатып алырга тагын акча кирәк.

– Инде шактый еллар бу өлкәдә эшләп, үзеңне җаваплы фермер итеп күрсәткән булсаң, ашлама, ягулыкны әҗәткә дә биреп торалар, – ди Әсхәт абый. – Кайвакыт шулай эшлибез дә. Зарлану ир кешегә килешми, шулай да... Ягулыкның бәясе айга ике тапкыр арта, ашлама да кыйммәтләнә. Яңа гына эшли башлаган фермерлар ничек чәчү чәчәрләр, белмим. Әле бит эшләр өчен никадәр техникасы кирәк. Ярый без көздән ягулыкны 30 сумнан алып калдык, язгы чәчүгә җитә. Ә ашламаны арзанрак бәядән алып булмады. Аны сакларга урын кирәк, авылдан ерак булырга тиеш ул, тикшереп торалар.

Чувашиядән килгән әлеге фермерлар белән сөйләшү рәхәт – гади дә, булдыклы да алар, үз эшләренең чын мәгънәсендә профессионаллары.

– Галстук тагып, ереләнеп йөрү – канда юк безнең, – ди Әсхәт абый. – Без шул эш белән «чирле». Чәчүләр төшемә керә башлады инде. Янәсе соңга калганмын икән... Кемдер минем җиргә кергән... Ашлама җитми калган кебек... Әлбәттә, бу эш белән баеп булмый, әмма җирдә эшләп рухи рәхәтлек алам. Монысы, мөгаен, иң кыйммәтлеседер.

БАШКОРТОСТАН КУНАКЛАРЫ

Башкортостаннан 80ләп эшкуар килгән иде. Араларында умартачылар аеруча күп. «Башкорт балы» дигән матур савытларларга тутырылган бал (ул бит, яхшы беләбез, үзенә күрә бер бренд та) бүген Россиянең төрле шәһәрләрендә сатыла. Ә бу нәкъ әлеге фермер, эшкуарларның хезмәте нәтиҗәсе булып чыкты. Умартачалак юнәлешеннән тыш, Башкортостанда авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүче КФХлар да күп икән. Соңгы елларда сөтчелек терлекчелегенә зур игътибар бирелә башлаган. «Әле берничә ел элек кенә җирләрдә чүп үләне үсеп утыра иде, бүген андый күренеш юк. Нәтиҗәдә Башкортостанның икътисадый үсеше сизелә », – диде эшкуарлар.

Тагын бер үзенчәлекле юнәлеш буенча эшләүчеләр – балык ыслап сатучы ирле-хатынлы Азат һәм Римма Маннановлар белән таныштым. Күгәрчен районының үзәге – Морык авылыннан килгән

PRESSA.RU

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов:

– Сезнең белән очрашу, танышу, аралашу, тәҗрибә уртаклашуыгыз, киңәш-тәкъдимнәрегезне ишетү безнең өчен бик файдалы. Бирედәге чыгышларның күбесе авылны, милләтне, динне, телне кайгырту зарурлыгы турында булды. Барыбызны да милләтебезнең, авылның киләчәге борчый. Татарлар өчен генә түгел, бөтен милләтләр өчен авыл нигез булып тора. Без кабул иткән, тормышка ашыра торган 38 республика программасының күбесе авылны кайгыртуга багышланган. Әлбәттә, без аларның барысын да дәүләт хисабына гына башкара алмыйбыз. Сезнең дә ярдәм кирәк. Авылны яшәтүнең төрле формаларын, юлларын табарга кирәк. Мисал өчен, үзара салым программасы, халыктан җыелган 1 сум акчага дәүләт тагын 4 сумны өсти…

Әгәр эш урыннары, сезнең кебек эшкуарлар булмаса, авылларыбызның киләчәге юк. Татар күп, ишле булырга тиеш! Сез – үрнәк, татар халкының иң булдыклы егетләре! Сезгә карап, бүтәннәр дә үзгәрәчәк. Киләчәктә дә җыелып, киңәшләшеп торырбыз.

алар. 1997 елдан бирле балык ыслау белән шөгыльләнәләр. Шулай ук умарталары да бар.

– Авыл хуҗалыгы институтында бергә укыган группадашым Рөстәм үзләренең районында балык ыслау эшенә алынгач, безне дә кыстый башлады, – ди Римма. – Эшли башлаганда дүрт стенасы гына булган бер бинаны сатып алдык. Ә техник яктан әллә нәрсә кирәкми аңа, балыкларны киптерү өчен өслек, утын ягу өчен мич булса, бетте, шул җитә дә. Эшне скумбрия балыгын ыслаудан башладык. Анысы – иң җиңеле. Әлбәттә, башта төрле кыенлыклар аша узарга туры килде. Тәҗрибә булмаганлыктан, йә балыкны бозып куябыз, йә ныграп тозлап җибәрәбез, йә артык пешеп китә…

Маннановлар хуҗалыгында бүген егермеләп кеше эшли. Кем әйтмешли, җайга салынган бизнес. Якын-тирә районнарны ысланган балык белән тәэмин итәләр. Ассортиментта илледән артык төр балык бар. Тозлап, ыслап, ваклап, чистартып савытларга тутырып чыгаралар.

– Химия кушмыйбыз, – ди эшкуар ханым. – Хәзер балык ыслау өчен «сыек төтен», тагын әллә ниләр бар. Алай бит тиз була. Ә без балыкны берничә көн ыслыйбыз. Башта тозда тора, аннан утта, аннан кибә. Шуңа да безнең балыкка сорау зур. Ни дисәң дә, кешене алдап булмый, бүген күпләр химиясез ризыкка өстенлек бирә.

Россиягә кертелгән санкцияләр Маннановлар өчен шактый кыенлыклар китереп чыгарган. Балык бәясе кыйммәтләнгән, элек ала торган нокталар ябылган. «Ә ни өчен безнең балыкны ысламыйлар?» – дигән сорау туарга мөмкин. Җавабы бик гади икән:

– Ысланган балык сыйфатлы булсын, дисәң, салкын диңгез балыгы гына бара, – диде Римма. – Әле менә бүген җыенда да: «Үзебездә үстерелгән балык белән эшләгез», – диделәр. Юк, алай булмый ул. Безнең балык ыслауга бармый. Күпме генә тырышсаң да, сыйфатлы продукция чыгарып булмый. Норвегиядән кайтарылган балыкка җитә алмыйсың. Безнең җылы суларда тотылган балыклар изелеп китә. Ә Россия балыкларын эшкәртмичә сатабыз.

Салым, штрафлар күп булуга зарланды эшкуарлар. Мисал өчен, Маннановлар унсигез ел «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять» булып эшләгән, икенче ел инде «Шәхси эшкуар» буларак эш итәләр.

– Тикшерүләр бик күп. Ничек кенә тырышсаң да, минус булырдай якларны барыбер табалар. «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять»кә, кимендә, йөз мең сум штраф салалар, ә «ШЭ»га, иң күбендә, 30 мең сум каралган, – дип аңлатты эшкуар ханым.

...Бер танышым Израильдә булып кайтты. Андагы авыл хуҗалыгы эшенең үсешенә шаккатып сөйләде ул. Фермер игенне чәчкән һәм якынча уңышның күпме буласын белә, чөнки технологияләр шулай көйләнгән. Ә бездә иген уңышы күбрәк лоторея билеты кебек: ел уңышлы килсә була, килмәсә – юк. «Чәчәбез дә, Аллаһы Тәгаләгә тапшырабыз инде. Игеннең уңышы туксан процент һава торышыннан тора чөнки», – ди фермерлар.

Соңгы биш елда, шөкер, күкләр безгә карата хәерхаһлы: Россиядә иген уңышы ел саен арта бара. 2017 елда рекорд куелды – ил буенча 131,1 миллион тонна бөртекле культура җыеп алынды. Һәм Россия тарихында беренче тапкыр, коралга караганда, иген сатып, казнага күбрәк акча керде. Бездә җитештерелгән иген, азык-төлеккә сорау зур, чөнки Россия, башка илләр белән чагыштырганда, экологик яктан иң чиста җирләрнең берсе. Мисал өчен, Америка фермерлары да үзләренә дигән ризыкны аерым җирдә үстерә, чөнки башка җирләр агуланып беткән. «Кычыткан, алабута үсә икән, димәк монда җир яхшы, натураль», – ди белгечләр. Ә бездә, шөкер, бөтен җирдә кычыткан, алабута үсә әле.

Озын сүзнең кыскасы, Россиянең киләчәге нәкъ менә авыл хуҗалыгы тармагында. Моны хәзер ил җитәкчеләре дә таный. Агымдагы елның март уртасында Краснодар краенда узган Бөтенроссия авыл хуҗалыгы җитештерүчеләр форумында Владимир Путин: «Россиягә төрле санкцияләр кертелгәч, корал сату кимеде. Шулай булгач, Россия якын киләчәктә авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча дөнья базарында лидер булырга тиеш», – дип белдергән иде. Шулай дип ышаныйк. Һәрхәлдә, бездә моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Дәүләт фермерларны гына кайгыртсын, бу егет-кызларның эшләү теләкләрен бетермәсен. Һәм җирнең, җир кешесенең кадере артсын иде.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Минтимернең яраткан хатын-кызлары **КЕМНӘР**

Картлар йортында әбиләр бәйрәмне **НИЧЕК** каршылый

Хатын-кызларны **НИНДИ** проблемалар борчый

Ир-атлар ханымнарны **НИНДИ** ризыклар белән сыйлый

PRESSA.RU

Шулай бервакыт Минтимер Шәриповичка «Казан» журналында басылган «Авылның беренче егете» дигән картина ошый. Аның авторы яшь рәссам Алексей Цыбисов булып чыга. Картина авторы, бу хакта ишеткәч, рәсемне Минтимер Шәриповичка бүләк итә. Шулай ук «беренче егет»нең тагын бер рәсемен ясый – Сәкинә тәрәзәсе каршында гармун тартып торган Минтимерне. Картинаның артына хезмәткәрләре мондый шигырь юллары да язып куя:

Көткән насыйбын гүзәл кыз.
Очрар да юлларымда,
Дияр: «Синеке йөрәгем –
Ал аны кулларыңа».
Хыял булып әверелер
Һәр сәгате, һәр көне,
Чын итә ала хыялларны
Без яшәгән Татарстанның
Иң кодрәтле егете!

МИНТИМЕРНЕҢ ЯРАТКАН **ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ**

8 март алдыннан «Татарстан» журналы Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев белән очрашты. Һәм без, әлбәттә инде, хатын-кызлар хакында сөйләштек – урамда яз бит!

Автор:
Татьяна Вафина

Татарстанның беренче Президенты яраткан хатын-кызлар Шәймиев фамилиясен йөртә. Һәркайсы аның тормышында үзенчәлекле роль уйнаган, һәркайсы турында ул бик күп кызыклы вакыйга сөйли ала, һәркайсына карата бик күп җылы сүзләре бар. Әнисе, әбисе, апалары, сеңлесе, хатыны, киленнәре, оныклары, оныгының кызы – барысы да хөрмәткә лаек ир-атның мактауга лаек сөеклеләре.

Фото Шәймиевләр гаиләсе архивыннан алынды



– Әни үрнәге – бала өчен иң шәп тәрбия ул. Чөнки баланы бары тик үз үрнәгеңдә генә тәрбияләп була. Гаилә нинди булса, бала да шундый.

Фото: Ната Смирнова

ӘНКӘЙ ӘНКӘЙ ИНДЕ УЛ

– Минтимер Шәрипович, әниегез сезне нәрсәгә өйрәтте? Аның турындагы иң җылы хатирәләрегез нинди?

– Әнкәем Нәгыймә мине бу тормышта кирәкле бөтен нәрсәгә өйрәтте. Гомерем буе ул минем янәшәмдә бара: карашы да, мөнәсәбәте дә, җәзасы да, рәхмәте дә. Әни үрнәге – бала өчен иң шәп тәрбия ул. Чөнки баланы бары тик үз үрнәгеңдә генә тәрбияләп була. Гаилә нинди булса, бала да шундый.

...Әнкәй әнкәй инде ул. Мин Һади Такташның мәктәптә укыганда ук өйрәнгән атаклы шигыреннән өзекне һич онытмыйм:

Ана! Бөек исем!
Нәрсә җитә ана булуга?
Хатын-кызның бөтен
матурлыгы,
Бөтен күрке ана булуда.

Кыска да, аңлаешлы да, җыйнак та, һәм иң мөһим фикер әйтелгән. Бу юлларда – минем әнием дә, җәмгатем дә. Сәкинә бәби табарга киткәч, мин, әлбәттә инде, төн буе йокламадым. Ниһаять шалтыраталар: «Хатыныгыз бәби тапты!» – диләр. Мин шунда ук Такташның әлеге сүзләрен исемә төшердем, аларны кәгазь битенә яздым да, Сәкинә янына киттем. Такташтан да яхшырак әйтә алмас идем бит барыбер. Шигырьне укыгач, ул елап җибәргән. Бу – яңа гына әни булган хатын-кызның сөенечле күз яшьләре. Әле хәзер искә алганда да, аның күзеннән яшь ага – шулкадәр күңеленә тигән булган әлеге шигъри юллар. Бу да, бүгенгедәй, нәкъ 7 март көнне булган иде. Беренче улыбыз Айрат нәкъ тугыз айдан туды безнең, 7 июньдә өйләнешкән идек.

Шунлыктан, әнкәем турында уйлаганда, аның безне кайгыртуын исемә төшерәм – безнең тамагыбызны туйдыру аның өчен бәхет булган икән бит. Ул заманда бу җиңел булмаган шул. Мин гаиләдә тугызынчы бала булып дөньяга килгәнмен, ә ул чакта ризык табу ай-һай авыр булган бит. Әнкәем нииндидер үләннәрдән, кычыткannan, туңган бәрәңгедән дә тәләңне йотарлык тәмле кабартмалар пешерә иде. Булдыра алганча тырышты. Безнең тамак туйганны күргәч, әнкәемнең күзләре нурлануын һаман да хәтерлим әле. Безне саусәламәт итеп күрүенә дә әнкәйнең күңеле булгандыр.

Әнкәй безгә гомер биргән өчен генә дә аны яратмый мөмкин түгел. Асылда, ул сиңа үзен бәяләү хокукын да биргән, ә ничек бәяләү – анысы инде үз эшең. Ул булмаса, синең сүзләрең дә булмас иде бит – яхшылары да, аның синнән һичкайчан ишетергә теләмәгәннәре дә... Әниле булу зур бәхет ул, һәм ана булу да Аллаһ биргән иң олы бәхет. Табигать нәселне дәвам итү сәләтен хатын-кызларга биргән. Без, ир-атлар, хатын-кызның эчке кичерешләрен, уйларын беркайчан да аңлый алмаячакбыз, ул үзенең яшерен уйларын әйтеп салырга бер дә ашыкмый. Аллаһы Тәгалә мине ишетсен һәм һәр хатын-кызга ана булу бәхете тисен иде.

Безнең әниләребезнең хәзерге тормышны күрмәүләре аяныч. Ризык бихисап, балаларны нәрсә белән туендырыйм икән дип интегеп баш ватасы юк. Хатын-кыз хезмәтен җиңеләйтү өчен никадәр җайланма уйлап табылган хәзер – кер юу, савыт-саба юу машиналары, краннан кайнар су агып тора – көянтәләп ташыйсы да, учак ягып җылытасы да юк... Әнкәебез вакытында боларның берсе дә юк иде шул, ул шулкадәр арый иде – кайвакыт ашарга утыргач, кашыкны авызына да китереп җиткерә алмыйча, йокыга китә иде...

Минем өчен иң үкенечлесе һәм инде төзәтеп булмаслык югалту – әнкәем янына сирәк кайтуым. Һаман вакыт җитмәде миңа... Тик бу акланыр өчен сәбәп түгел! Әти-әни исән чакта алар белән ешрак күрешергә вакыт табу зарур. Аларга шул гына кирәк тә бит. Без бит аларның балалары, очрашуларны ничек тә кичектермәскә иде. Соңга калырга да мөмкинбез. Гомер бик тиз ага. Мин әнкәем янына сирәк кайттым. Безгә килгән чакларында исә, хәтерлим әле, ул сөйли дә сөйли, миңа бөтен нәрсәне сөйләргә тырыша, сөйләшеп туя алмый... Мин бит аның өчен ничә яшьтә булсам да сабый. Мин исә, артык арыгангадыр инде, кайчак аның сүзен тыңлап та бетерә алмыйча йокыга китәм. Моның өчен мине Сәкинә дә гел ачулана иде. Менә шуңа үкенәм.

PRESSA.RU

– Әнкәем бар иде, хәзер инде ул юк. Туйганчы сөйләшергә дә өлгермәдем дип үкенеп утырырга гына калды.

Кире кайтарып булмый шул ул вакытларны. Әнкәем бар иде, хәзер инде ул юк. Туйганчы сөйләшергә дә өлгермәдем дип үкенеп утырырга гына калды.

МИНЕМ АПАЛАРЫМ

– Сез бервакыт «мине апаларым укырга өйрәтте» дигән идегез...

– Инде бакыйлыкка күчкән апаларым Дөргалия һәм Мәрзияне бары тик яхшы сүзләр белән генә искә алам. Без, сеңлем Мәдәния белән очрашканда, апаларыбыз һәм Хантимер абыебыз үрнәгендә үсүебезне еш искә төшерәбез. Авылда шулай кабул ителгән бит: әти-әни эштә, өлкәнрәк балалар кечерәкләрен кайгырта – бөтен тәрбия менә шул инде. Мәрзия апам мине китап укуга һәвәсләндерде, Дөргалия апам исә, төннәрен йокламыйча, саклады – чираттагы китап белән мавыгып, керосин лампасын әйләндереп каплавымнан курыкты. Көндез укырга вакыт юк иде бит.

Без үсеп җиттек тә таралыштык, өлкән апабыз Дөргалия генә, кияүгә чыгып, авылда калды. Еллар үткән саен, ул һаман күбрәк әнкәйгә охшый барды. Без аның янына туган нигезгә кайткандай җыела идек һәм һәрвакыт аның аналарча кайгыртуын тоеп яшәдек.

Минем тормышымда зур роль уйнаган тагын бер хатын-кызны – беренче укытучым Хәдичә апаны да әйтеп үтәсем килә. «Апа» сүзенең мәгънәләре күп төрле: ул синнән өлкәнрәк яшьтәге хатын-кызларга әйтелә. Укытучыбызга 18 яшь кенә булганга, без аны туган апабыздай якын күрә идек. Яшь булса да, ул бик акыллы һәм бөтен нәрсәне белә иде. Ул безне күп нәрсәгә – укырга, язарга, рәсем ясарга, биергә, Яңа ел бәйрәменә чыршы бизәргә өйрәтте... Ә иң мөһиме – чын, лаеклы кеше булырга өйрәтүедер.

ЗАТЛЫ ӘБЕКӘЕБЕЗ

– Оныклар тәрбияләүдә әбиләрнең роле бик мөһим. Бер буын аша булган бәйләнеш – иң ныклысы. Әмма кайвакыт әбиләр онproblemsкларын артык иркәли дә. Сезнең балачакның авыр елларга туры килүе аңлашыла, тик шулай да, әбиегез сезне иркәли идеме? Һәм сез хәзер үз оныкларыгызны иркәлисезме?

– Иркәли иде. Минем әбекәем Сәхипҗамал исемле, тик без аны Усы әбекәй дип йөртә идек – бездән сигез чакрым ераклыктагы Усы авылыннан ул җәяү килеп йөри иде. Легендар әбекәй ул. Бик пөхтә, һәрвакыт таяк тоткан, ал камзулдан, күчтәнәчкә пешкән йомырка яки татлы калач алып килә... Кайвакыт икешәр атна кунак була, безне чебешләрне, каз һәм үрдәк бәбкәләрен карчыгалардан сакларга өйрәтә иде. Шул вакытта төрле гыйбрәтле хикәятләр сөйли, яшәү серләренә төшендерә... Аның әкиятләрдән, мәкаль-әйтемнәрдән торган сабакларын хәзергәчә хәтерлим әле.

Фото: Шәймиевләр гаиләсенең шәхси архивыннан

Минтимер Шәймиев һәм аның олы апасы Дөргалия. 2014 ел.

Беренче укытучысы белән. 2005 ел.

Буранда калсаң нишләргә, кайсы үләннәр ашарга яраклы, кайсы җиләкләр агулы – боларның барысын да безгә әбекәй өйрәтте. Без аның бөтен нәсыйхәтләрен үти идек. Милләт рухы әбиләрдән оныкларга күчә. Менә мин дә хәзер, «Яңарыш» фонды эшләре белән шөгыльләнгәндә, әлеге кыйммәтләрне оныкларыма тапшырырга тырышам. Алар мине хуплый кебек тоела. Рухиятне торгызу зарур, бу өлкәдә эш күп әле. Әмма бит бу вакытта үзең дә уңай якка үзгәрәсең, күңел сөенгәнгә, канәгатьлек хисе туа. Әйтәләр бит, иртән хатының белән ачуланышмасаң – бу инде хәйриячелек, диләр. Чөнки, әгәр син эчтән тыныч булсаң, игелек эшләрлек теләк тә, куәт тә бар. Бу дөньяда бөтен нәрсә хатын-кыздан, яраткан хатын-кызлардан тора. Таш кыяларны буйсындырырлык куәтне безгә нәкъ менә алар бирә.

«ӨЙДӘГЕ ОППОЗИЦИЯ»

– Сезне таулар күчерергә рухландырган җәмәгатегезгә Президент хатыны исемен лаеклы рәвештә йөртү насыйп булды. Өйләнешкән чакта исә сез бу кадәр үк югары дәрәҗәләргә ирешәсегезне, гаиләгезнең хакимият белән сыналачагын белмәгәнсездер, мөгаен. Минтимер Шәймиев хатынының Президент Шәймиев җәмәгатенә «әверелүе» ничек булды?

– Сәкинә белән бер-беребезгә бер күрүдә гашыйк булдык. Чынлап торып. Әйе, шулай да була! Мин бишенче курста укыганда үземнең туган ягыма – Актаныш районына (ул чакта Калинин районы иде) диплом алды практикасына кайткач таныштык. Клубта. Ул миңа бик нык ошады, шунда ук биергә чакырдым үзен. Бер тапкыр биедек. Аннары дүрт тапкыр рәттән дус кызы белән биедем. Бер генә максат белән – аңардан Сәкинә турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат алырга тырыштым. Аннары икесен дә өйләренә кадәр озаттым. Алар техникум тәмамлаганнан соң безнең район кулланучылар җәмгыятендә эшли иде, кечерәк кенә йорт биргәннәр үзләренә. Икесен дә җитәкләп барам: дустыРитаның кулыннан йомшаграк итеп, Сәкинәнекен кысып тоттым. Рита өйгә кереп качты, Сәкинә исә кулын тартып ала алмады. Ул башта миңа бераз үпкәләбрәк:



PRESSA.RU

– Гади хатыннан Президент хатынына әверелүгә килсәк… дөресен генә әйткәндә, Сәкинә бу «әверелеш»кә әллә ни сөенгәндер, дип әйтә алмыйм. «Frau Сакина» дип язып куйган әлеге фотографиянең артына Минтимер Шарипович.

«Йә, нәрсә инде син, Рита белән биисең, ә мине җибәрмисең?» – диде. Миңа ни өчен аның дус кызы белән биюемне аңлатырга туры килде.

Аннары мине Мөслим районына эшкә җибәрделәр. Мин Сәкинәне дә үзем белән китәргә үгетләдем, тик ул ризалашмый гына бит – янәсе, Казанда укып бетерергә кирәк бит әле. Мин сагынам, юксынам, янына барам – ә ара якын түгел… Көтмәгәндә миңа колхоз рәисе булып эшләүче әткәй ярдәм итте. Аңа да Сәкинә бик ошый икән. Ул безнең очрашуыбызны белмәгән, бер тапкыр күргәч, ошатып калган да, гел күз уңында тоткан. «Өйләнергә кирәк сиңа, әнә, кулланучылар җәмгыятендә бер яхшы кыз эшли», – ди беркөнне. Аның башта укуын тәмамларга, аннары гына кияүгә чыгарга җыенуын ишеткәч, вакыйгаларны тизләтергә булды һәм Казанга Сәкинәнең әнисе янына кыз ярәшергә китте. Аны да, абыйсын да күндерә алган бит. Сәкинәгә дә ризалашырга туры килде. Шулай итеп без өйләнештек, һәм мин Сәкинәмне Казаннан ак пароходта алып киттем… Бу – минем тормышымдагы иң бәхетле көнем!

Президент хатынына «әйләнүгә» килгәндә исә… дөресен әйтим, баштарак аның бер дә үзгәрәсе килмәде. Башта, Минзәләдә «Сельхозтехника» районара берләшмәсендә идарәче булып эшләгән җиремнән Казанга күчергәндә, ул каттый каршы иде. Чөнки безнең үз хуҗалыгыбыз, директор йорты бар иде. Аңа анда бик ошый, ул оҗмахтагы кебек яшим, дия иде, Казанга бер дә кайтасы килмәде. Ә инде мин президент булгач, президентлыкның кайчан тәмамланачагын көтеп яшәде. Гомумән алганда, «өйдәге оппозиция» булды, мин аны, шаяртып, шулай атыйм.

Гомумән, ул минем өйдә озаграк торуым турында хыялланды һәм мин республика президенты вазифасыннан киткәч, җиңел сулап куйды. Әмма иртәрәк тынычланды шул! Без Болгар белән Зөяне яңартырга тотындык, һәм мин тагын көне-төне эштә югала башладым. Ул һаман хыялына ирешмәде кебек…

– Бу минем тормышымдагы иң бәхетле көн булды!

КИЛЕННӘРЕМ БЕЗГӘ ИСКИТКЕЧ ОНЫКЛАР БҮЛӘК ИТТЕ

– Сезнең ике улыгыз бар, алар армиядә дә хезмәт иткән, атаклы автоузышчылар да – мондый балалар – һәр әтинең горурлыгы. Шулай да һәр әти кыз бала турында да хыяллана. Киленнәрегез сезгә кызыгыз кебек якынмы? Улларыгыз сайлап алган кәләшләрдән канәгать калдыгызмы?

– Билгеле инде, без дә кыз бала турында хыялландык. Тик бит элегрәк менә ничек – хатын-кызга декрет ялы нибары дүрт айга бирелә иде. Бәби тапканчы ике ай һәм тапканнан соң ике ай. Аннары исә эшкә чыгу – мәҗбүри. Сәкинәгә ике кечкенә бала белән бик кыенга туры килде, мин иртәнге дүрттә китеп, төнлә генә кайта идем. Безгә әбиләр дә, бала караучылар да ярдәм иткәләде… Тик тагын бәби алып кайтмавыбызның төп сәбәбе менә шунда гына. Ә алып кайтасы булган икән!

Киленнәремә мөнәсәбәтем яхшы, улларым үзләре сайлады, мин фикеремне такмадым – аларның үз гомере, үз язмышы. Казанга Сәкинәне ярәшергә барган әткәем кебек булмадым. Әйе, улларыбыз үзләре сайлады, безгә моның белән килешергә генә калды. Киленнәребез безгә искиткеч оныклар бүләк итте.

– Безнең Камилә гел шундый эшлекле, тәвәккәл, үз дигәнендә нык торучан.

МИНЕМ БЕЛӘН ОНЫКЛАР ИДАРӘ ИТӘ

– Камилә – беренче оныгыгыз. Сезнең аны ничек яратуыгыз һәркемгә мәгълүм. Ләйләне дә шулай ук яратуыгызны беләбез. Алар турында сөйләгез әле. Сез оныкларыгызны нәрсәгә өйрәтәсез һәм алар үзләренең бабаларын нәрсәгә өйрәтә?

– Оныклар һәр елны, каникулларын безнең белән Боровое Матюшинода уздыра иде. Камиләне шахмат уйнарга өйрәтүемне хәтерлим, аның үзенең өйрәнәсе килде. Аңа бөтен нәрсә кызык иде. Бик күп китап укыды, җиденче сыйныфта укыганда үз теләге белән Достоевскийның бөтен әсәрләрен укып чыкты. Укырга ярату аңа миннән күчкәндер. Мин китап һәм журналлар укырга бик яратам. Электрон формат түгел, кәгазь кирәк. «Казань» журналы үзгәрә башлагач, заманча, кызыклы, укылышлыга әйләнгәч, бик сөендем. Хәзер менә «Татарстан» өчен шатланам, чөнки журнал укучыга якынайды, кешелеклерәккә әйләнде. Икесен дә яздырып алабыз.

Институтта укыганда, беренче курстан соң, Камилә МГИМОга күчәргә теләвен әйтте. Күчте дә. Анда таләп ителгәнчә беренче курска түгел, бөтен кирәкле имтиханнарны бик яхшы биреп, икенче курска күчте. Ул безнең гел шундый эшлекле, тәвәккәл, үз дигәнендә нык торучан. Кияүгә чыккач, мондый командирларча холкы белән нишләр инде, дип уйлый идем. Әмма искиткеч назлы һәм игелекле әни булып чыкты – улы Робертны бик ярата, аның өчен җанын ярып бирергә дә әзер.

Ләйләне исә Айрат улым минем туган көнемә бүләк итте. Шалты-



– Онығым Ләйләне улым Айрат миңа туган көнемә бүләк итте.

рата: «Әти, бүләкне кабул ит!» – ди. Хәзер оныгым белән бер көнне туган көннәребезне бәйрәм итәбез.

Гомумән алганда, онықларым да, оныгым Тимурның кызы Руслана да бар инде хәзер. Аңа бер яшь, рәхәтләнеп тәпи йөри. Оныкларының баласын күрү олы бәхет ул. Алар безнең нәселнең дәвамы, Сәкинә белән минем бу җирдә калдырган эзем бит.

ЯЗ БЕЛӘН СЕЗНЕ, КАДЕРЛЕЛӘРЕМ!

– Шәймиевләр гаиләсе хатын-кызлары нинди алар? Төрле буыннарда нәрсә дә булса кабатланамы? Алар Шәймиев булмаганнардан ни белән аерыла?

– Әлбәттә, минекеләр дә һәммәсе Шәймиев түгел инде хәзер… Камилә дә, кияүгә чыккач, фамилиясен алыштырды, тик бу мөһим түгел. Минем аларның барысын да яратуым мөһим. Тагын әле алар барысы да, Сәкинә кебек, кунакчыл, хуҗалыкны алып бара белә, бик оста пешерә. Дөрес, хәзер мине Сәкинә песиләрне ашатканнан соң гына ашата. Бу мәчеләр мәрәкәсе әллә ничә елдан бирле килә. Сәкинә Шакировна песиләрне бик ярата. Мин исә яратмыйм. Миндә алардан аллергия башлана. Шунлыктан безнең өйдә мәче юк. Әмма әйләнә-тирәдәге бөтен мыраухаҗаннар бездә көнене өч тапкыр ашый. Сәкинә алар өчен махсус ашарга пешерә һәм минем этемне алар янына җибәрми. Чөнки ул песиләрне өнәми… Шул рәвешле, безнең ишегалды ике өлешкә бүленгән кебек. Бер якта, вольерда, эт, икенче якта – мәчеләр гвардиясе. Симезләр, ялкаулар… Болай ашаткач, алар үзләренә ризык табуны кайгыртмый башлый бит, дип сукранып та йөрим кайчагында. Тычканнар һөҗүм итеп, үзләрен әсир итмәгә… Әмма барыбер колак салучы юк. Мин ияләндем инде.

– Әгәр сез гаиләгездәге барлык хатын-кызларны – әбиегездән алып оныгыгызның кызына кадәр бер табын тирәли җыя алсагыз, аларга нинди теләк теләр идегез?

– Булганнары өчен рәхмәт әйтер идем! Миңа шундый җете, вакыйгаларга бай, кызыклы гомер биргәннәре өчен рәхмәт. Бу тормышта минем белән яшәүләре өчен рәхмәт. Шундый яхшы балалар, оныклар, аларның балаларын бүләк иткәннәре өчен рәхмәт. Миндәге бөтен нәрсә алардан – минем сөекле хатын-кызларым тырышлыгыннан бит! Яз белән сезне, кадерлеләрем!

Барлык хатын-кызларга иң изге теләкләр белән: Минтимер бабагыз.



Шатлыклы мизгелләр

әбиләр ничек үзгәрә...

Югары Ослангадагы картлар йортында 8 март алдыннан күңелле һәм шатлыклы ыгы-зыгы булып алды. Җирле әбиләр «Татарстан» журналы командасы кулына «эләкте». Безнең корреспондентлар, фотограф һәм халыкара дәрәҗәдәге стилист Толли Кириллов аларны затлы-зәвыклы, берсеннән-берсе матур ханымнарга әйләндерде. Бүген үк журнал тышлыгына тот та чыгар үзләрен! Причёска, макияж, яңа имидж һәм истәлеккә рамга алынган фото – язның иң матур бәйрәме алдыннан хатын-кызларга шуннан да күркәм бүләк була алмый. Матур фотографияң булу һәм аңа соклана алу – бу бит хатын-кызны теләсә кайсы яшьтә дә дәртләндерә.

ПРОЕКТНЫҢ АВТОРЫ:

«Татарстан»
журналы редакциясе

ТОРМЫШКА АШЫРУЧЫЛАР:

Толли Кириллов,
халыкара дәрәҗәдәге дипломлы топ-стилист, имиджмейкер, Россия, Япония, Венгрия, Португалия, Италиядәге чәчтарашлык сәнгате буенча уздырылган халыкара бәйгеләр финалисты һәм җиңүчесе. Визажист, шоппер, модельлек сәнгате буенча мөгаллим.

Альбина Заһитова,
Кара уылдык экстракты, коллаген һәм кератин кулланып ясалган Be Color 12 Minute органик чәч буяу уникаль инновацион системасының Татарстандагы эксклюзив вәкиле.

Ната Смирнова,
«Татарстан» журналы фотокорреспонденты.

КАТНАШУЧЫЛАР
(Югары Ослангадагы инвалидлар һәм картлар интернат-йортында яшәүчеләр):

Федая Долгих

Нина Майорова

Анастасия Дворянинова

Надежда Лепихина

Александра Фуфлыгина

Сезнең алда – тылсымлы әверелешләр һәм фотосессиядән күркәм мизгелләр

PRESSA.RU

Шатлыклы мизгелләр

ШАТЛЫКНЫ БЕР-БЕРЕБЕЗДӘН ТАБАБЫЗ

Федая Долгих:
– Владимир һәм мин. Бер-беребездән дә якынрак беркемебез юк. Интернат-йортларның берсендә таныштык та, шуннан бирле аерылмадык. 40 ел инде бергә булуыбызга. Чиркәүдә өйләнештек. Ул мине кайгыртып яши – конфетлар бүләк итә, чәчәкләр. Ә мин исә көнкүрешебезне кайгыртам. Дус, тату яшибез. Шатлыкны бер-беребездән табып.

PRESSA.RU

БАЛАЛАР ӨЧЕН БУЛГАН ШАТЛЫК – ИҢ РӘХӘТЕ

Нина Майорова:
– Укытучыларның улымны мактаулары хәтеремдә: «Һәрчак кул күтәргән булыр, бөтен нәрсәгә җавабы әзер аның». Шулчакта ничек шатланганымны белсәгез! Балаларың өчен шатланудан да зуррак бәхет юктыр.

PRESSA.RU

Шатлыклы мизгелләр

ЯХШЫ КЕШЕЛӘРДӘН УҢДЫМ

Анастасия Дворянинова:
– Гомерем буена яхшы кешеләр белән очраштырып торды язмыш – эштә дә, тормышта да. Әгәр яшьлегемне яңадан кайтарып булса, барысын да нәкъ шушылай кабатлар идем. Дөресен генә әйткәндә, мин яхшы кешеләрдән уңдым.

PRESSA.RU

Шатлыклы мизгелләр

СПОРТ БЕЛӘН ДУС БУЛДЫМ

Надежда Лепихина:
– Әле хәзер дә өстәл теннисы уйнарга спорткомплекска йөрим. Карлар эрегәнче, чаңгыда җилдереп кайтырга да исәп бар. Гомерем буена спорт белән дус булдым. Спорт ул күңелсезләнеп, боегып ятарга ирек бирми торган нәрсә.

PRESSA.RU

ҮПКӘ САКЛАМАСКА КИҢӘШ ИТӘМ

Александра Фуфлыгина:
– Күңелсез хәлләрне онытырга, үпкә сакламаска киңәш итәм. Шулай иткәндә, бернинди картлык та куркыныч түгел!

PRESSA.RU

Шатлыклы мизгелләр

P.S.

ХАТЫН-КЫЗ КАЙСЫ ЯШЬТӘ ДӘ МАТУР

Толли Кириллов, топ-стилист:

– Һәрбер хатын-кыз, ничә яшьтә булса да, үзенең матур икәнлеген онытмаска тиеш. Хәзер инде без әбиләрне дә яулык бәйләгән элеккеге образда күз алдына китерә алмыйбыз. Бүгенге заманда мода һәм тудырылган шартлар теләсә кайсы яшьтә менә дигән кыяфәттә булырга мөмкинлек бирә. «Алтын» һәм «бриллиант» чорына кергән ханымнарга да аптырап торасы юк. Кием-салымнан һәм чәч буяуларыннан башлап, кыйммәтле булмаган декоратив косметикага кадәр – сайлап алырга барысы да бар. Үз яшегезгә ихтирам белән карарга киңәш итәр идем. Өлкән яшьтәге ханымнарның стиле дә күңелсез һәм эчпошыргыч булмаска тиеш. Хатын-кыз үзе моны теләсә генә картая ул. Олырак яшьтәге ханымнарда инде яшьләргә җитеп бетми торган тормыш тәҗрибәсе һәм зирәклек бар, моңа өстәп әле тагын – җуелып бетмәгән тормыш дәрте һәм яңалыкка омтылыш та.
Мин бу экспресс-үзгәреш проектында безнең героиняларга, нинди генә яшьтә булуларына карамастан, сөйкемле һәм күркәм була алуларын исбатлар өчен катнаштым.

ТӘКЪДИМ ГЕНӘ ТҮГЕЛ БУ, Ә БОМБА

Ната Смирнова, «Татарстан» журналы фотографы:

– Охшаш нәрсәләр бер-берләрен тартып китерә, диләр бит. Мин визажист һөнәрен үзләштереп бетереп тә өлгермәдем, менә шушы «бомба»-проектта катнашырга тәкъдим килеп төште. Картлар йортына барып, аларның үзгәреш, әверелешләрен төшерергә кирәк булып чыкты. Бу сәфәр миңа гаять көчле энергия, дәрт бүләк итте. Шундый сөйкемле әбекәйләр! Оялдылар да, курыктылар да. Кайсыберләре, «гомеремдә дә бизәнгәнем юк», дип, тартынды. Икенче берләре исә, киресенчә, визажистка чәчләрен буярга нинди төс сайларга икәнлеген әйтеп торды, иннек сайларга булышты... Мин хатын-кыз гомумән ямьсез була алмый, дигән караш тарафдары. Бары үзенең матурлыгын күрми генә кайберләре. Әмма аларга ул матурлыкны күрсәтергә өйрәтергә кирәк. Үзләренең кем буluларын белсеннәр!

ЗУР ЙӨРӘК БЕЛӘН ЭШЛӘНГӘН ҖЫЛЫ АКЦИЯ

Ләйлә Фазлыева, ТР Премьер-министрының урынбасары:

– Шулкадәр күркәм акция оештырды «Татарстан» журналы. Җылы акция!

Нинди матур хатын-кызлар, дип сокландым!

Акциянең төп идеясе – әлеге ханымнарның эчке дөньяларын ачып күрсәтү. Алардан эчке бер нур бөркелеп тора бит.

Махсус белгечләр ярдәме белән ханымнар шулкадәр гүзәл затларга әверелде.

Бу катлаулы дөньяда аларның шушы матурлыгын күрсәтү хатын-кызның кадерен ассызыклау да ул.

Безнең халыкта бит болай дияләр:

Әтиеңне башыңда тот,
Әниеңне уеңда йөрт!

Дөньяны әти-әниләр үз кулында тота. Аларның безгә – балаларына булган – мәхәббәте киләчәкне билгели.

Әти-әниләрне оныту, минемчә, зур гөнаһ ул, аларны онытып, тамырларыңны да югалтасың, үзеңне дә...

Минем коллегам – шагыйрә Алсинә Сәлахованың мондый юллары бар:

Әни кирәк бала өчен, әни кирәк,
Кочагына алып назлар өчен.
Гаепләрең булган чакларда да
Синең күңелеңне аңлар өчен.

Әти кирәк бала өчен, әти кирәк,
Авырлыктан сине яклар өчен.
Бер карашы, сузе, эше белән
Ялгыш адымнардан саклар өчен.

Акциядә катнашкан ханымнарга, һәм безнең әти-әниләребезгә иң изге теләкләремне җиткереп калам!!!

Реклама 16+

PRESSA.RU



АНАЛАР ӨЧЕН **УРЫН КАЙДА?..**

«Артык кашык» дигән гыйбарәне, гадәттә, гаиләдә кадере булмаган карт-корыга, ятимнәргә карата кулланалар. Ире ташлап киткән яки өеннән куып чыгарылган ана белән бала да «артык кашык»ка әйләнергә мөмкин. Ярдәм кулы сузардай туганнар, дуслар да калмый. Нишләргә? Төнне кайда уздырырга? Балага нәрсә ашатырга? Алга таба ничек яшәргә? Мондый хәлдә калган хатын-кызлар кая мөрәҗәгать итә ала?



Автор:
Руфия Фазылова

«НИЧЕК УРАМДА КАЛДЫРЫЙК?»

Туганнар шалтырата: «Авиатөзелеш районында күкрәк баласы белән бер яшь ана йөри. Исеме Альбина, барыр урыны юк. Төнне подъездда уздырган. Салкын бит, нишләтергә икән?» Чынлап та, кыш уртасында сабый бала белән урамда нишләмәк кирәк?! Шуннан телефон буенча төрле оешмаларның номерын җыя башладым. Беренче булып Казан шәһәренең 18 нче номерлы хастаханәсенә шалтыраттым. Әле берничә ел элек кенә барыр урыны булмаган аналар биредә вакытлыча яши ала иде. Моның өчен аерым палаталар бүленгән, ашату, бала кирәк-яраклары – барысы да бар. Тик, ни кызганыч, 18 нче хастаханәдә хәзер андый мөмкинлекне бетергәннәр булып чыкты. «Баласын вакытлыча калдырып торса гына, аналар өчен дә урын юк», – диделәр. Теге яшь ананың исә сабыен хастаханәдә калдырып китәсе килмәде. Аналык хокукыннан мәхрүм итәрләр, дип курыкты. Шуннан «Билгеле бер тору урыны һәм һөнәре булмаган затлар өчен «Шәфкатьлелек» адаптация

Фото: Александр Ефремов

үзәге»нә шалтыраттым. Әмма монда да җылы сүз әйтмәделәр: бала белән яшәргә рөхсәт юк, үзе генә килсә ярый, дигән җавап алдым. Аптырап, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы номерын җыйдым. «Авыр хәлдә калган хатын-кызлар белән турыдан-туры эшләмибез. Дәүләт тарафыннан андый аналар өчен махсус урыннар каралмаган», – диделәр. Шулай да социаль проектлар белән эшләүче Ирина исемле кызның телефон номерын бирделәр. Тик ул кыз да Альбинага ярдәм итә алмады. «Мин шәһәрдә түгел. Без әле авыр хәлдә калган аналар белән эшләргә җыенабыз гына. Проект ул. Торак, документлар артыннан йөрибез», – дип җавап кайтарды.

Шулай бәргәләнә торгач, туганнар Альбинаны баласы белән үзләренә алып кайттылар. «Ничек итеп күрә торып кешене урамда калдырыйк?» – диделәр. Ә икенче көнне туганнарым яшь ананы вокзалга илтеп куйды – Альбина туган шәһәренә кайтып китте.

Шушы вакыйгага кадәр бу проблема турында әллә ни уйланганым булмады. Чынлап та, зур шәһәрдә балаң белән ялгыз, тораксыз, акчасыз калу бик мөмкин бит. Әнә, Мәскәүдә «Әниләр йорты» исемле приют бар икән. (Православие диненә караган коммерциячел булмаган хәйрия фонды канаты астында яши.) Приют 2012 елдан бирле эшли. Алты ел эчендә 180 әни, 200дән артык бала приют аша узган. Монда психолог, юристлар, социаль белгечләр эшли. Авыр хәлдә калган хатын-кызларга тормышларын җайларга ярдәм итәләр.

АНАЛАР ӨЧЕН – «БИШЕК»

Бактың исә, Казанда да балалар һәм аналар өчен приют ачылган икән. Әле бер генә ел аңа, ул 2017 елның март аеннан бирле эшли. Җисеменә туры китереп, исемен дә «Бишек» социаль йорты» дип куйганнар. Бүген биредә 8 хатын-кыз һәм аларның 13 баласы яши. Приют дигәч тә, алты катлы торак йорт ул. Бишенче һәм алтынчы каттан алты бүлмәле фатирны арендага алып торалар.

Без килгәндә фатирда хуш исле ризык исе чыккан иде. Администратор Ольга Арсентьева аш бүлмәсенә язып эленгән исемлекне күрсәтә:

– Кызлар һәр көн дежур тора. Берсе ашарга пешерсә, икенчесе савыт-саба юа, приютны җыештыра...

Аш бүлмәсе гадәти фатирныкыннан берни белән дә аерылмый: суыткыч, газ плитәсе, кер юу машинасы, уртада зур өстәл. Күп вакыт аналар бергә җыелып ашый икән. Мин исә өстәлдә торган баскан токмачка игътибар иттем: вак итеп, үзебезчә киселгән ул.

– Токмачны кайсыгыз кисте?-– дип сорыйм.

Җыйнак, матур гына гәүдәле яшь ханым:

– Мин, – дип чатнатып татарча җавап кайтарды.

– Татар кызымы әллә син? – дим.

– Әйе, Гөлшат исемле.

Шуннан Гөлшат белән рәхәтләнеп татарча сөйләшеп киттек. Казанга якын гына урнашкан бер районнан булып чыкты. (Чын исем-фамилиясе, туган җирен язмавымны кат-кат үтенде.) Дүрт яшьлек улы һәм сигез айлык кызы бар, үзенә утыз тулган. Гөлшатның аянычлы язмышы турында ишеткәч, чәчләр үрә тора.

–Егерме биш яшемдә Украинадан килгән бер егет белән таныштым, – дип сөйләде яшь ана. – Язылышмыйча гына фатир арендалап яши башладык. Иремнең документлары тәртиптә түгел, теләгән очракта да язылыша алмый идек. Шуннан улыбыз туды. Һөнәрем буенча бухгалтер мин, бала белән утырганда да өйдә торып эшләдем. Ирем белән танышканчы кредитка машина алган идем, шуны түләдем. Соңрак ирем машинаны сатарга кыстый башлады. Ни өчен, дип төпченгәч, ул кызыл төстә, рульдә йөрергә оялам, диде. Мин риза булдым. Үзе дә яңа машинага, дип, йөз мең сумга якын акча җыйды...

Аннан соң барысы да кинодагыча була: Гөлшат баласын бакчадан алып кайткан җиренә иреннән дә, машина саткан 400 мең сум акчадан да җиләр исә. Хәтта ноутбукка кадәр алып чыгып китә ир дигәнең. Өстәвенә, бу вакытта инде Гөлшатның биш айлык көмәне дә була!

–Үрсәләнеп әллә ничә көн үкседем, – ди Гөлшат. – Ни өчен мин шундый бәхетсез булганмындыр... Әти мин кечкенә вакытта үк вафат булды. Әни белән мөнәсәбәтләр катлаулы. Кечкенәдән мине яратмады сыман, нәрсә генә эшләсәм дә, сүгә иде. Хәер, рәнҗемим, гомер биргән, үстергән. Тик мин балаларыма карата андый мөнәсәбәттә булмаячакмын. Сабыйларым дип яшим. Иң кадерле кешеләрем – алар...

Гөлшат язылышмыйча яшәүче ирен эзләтер өчен полициягә гариза язган. Тик файдасы булмаган. Озак кына бәргәләнгәннән соң яшь хатын «Бишек» приютына шалтыраткан. Һәм бер кулына чемодан тотып, икенчесе белән улын җитәкләп биргә килгән. Инде приютта яши башлавына бер ел була икән.

– Бала тудыру йортына киткәндә, улымны монда калдырдым, – ди Гөлшат. – Башка кешем дә юк бит. Иптәш кызларның үз тормышы, алар гаиләсенә кереп булмый. Туганнарга бара алмыйм, гаеп эзләүдән башка эшләре юк. Кызым белән туры приютка кайттык. Әлбәттә, әллә ничә кеше бергә яшәү рәхәт түгел, шулай да баш өстендә түбә, ашарга кайнар ризык бар. Фатир өчен акча түләргә кирәкми.

– Ә балаларның әтисе? Синең икенчегә көмәнле икәнеңне белгәнедер бит. Хәбәре юкмы? – дим.

– Белде. Хәбәре юк. Булмастыр да. Ничек мин кешедә шулкадәр ялгыша алдым икән?! Башыма сыймый...

PRESSA.RU

«МӘРХӘМӘТЛЕ КЕШЕЛӘР КҮП»

Гөлшатны приют директоры Элина Галиуллина мактап туя алмады: акыллы, бик тәмле ашарга пешерә, тырыш.

Элина бу өлкәдә җиде ел эшли икән. Казан Епархия канаты астында яшәүче «Умиление» автоном коммерциячел булмаган оешмасы балаларны, аналарны яклаучы оешма булып тора. Эшләп киткән чорда үзәкнең төп максаты көмәнле хатын-кызларны абортка барудан саклап калу була. Тора-бара үзәктә эшләүчеләр бер фикергә килә: көмәнле, балалы хатын-кызларга торак урынын булдырырга кирәк.

– Россиядә хатын-кызлар ел саен 800 мең аборт ясата, – дип, статистика белән таныштырды Элина. – Коточкыч саннар. Безнең психологлар Казанның хатын-кызлар консультацияләрендә эшли. Гүзәл затлар бу адымга баруларын күбрәк: «Баланы үстерергә мөмкинлек юк», – дип аңлата. Ә бит сугыш вакытында да бала тапканнар. Бүген тыныч тормышта бала алып кайтырга куркалар. Минемчә, хәзер җәмгыять, гаилә кыйммәтләре үзгәрде. Төп проблема әнә шунда. Әйе, чынлап та, абортка әзер хатын-кызлар арасында бик авыр хәлдә калучылар да бар. Менә шундый очраклар өчен дип приют ачтык.

Узган ел март аенда «Умиление» оешмасы «Спаси жизнь» проекты кысаларында РФ Президентының 1 миллион 800 мең сумлык грантын откан.

Элина Галиуллина, приют директоры

– Акча күчерелүгә приют өчен фатир эзли башладык, – ди Элина. – Тиз арада документларны тәртипкә китердек. Казан шәһәренең Совет районы админстрациясе белән килешү төзедек. Приютка социаль хезмәткәр билгеләделәр. 6 нчы балалар хастаханәсеннән даими рәвештә табиб, шәфкать туташлары килеп тора. Балалар кечкенә бит, еш авырыйлар.

Грант акчасы гыйнвар аена кадәр җиткән. Фатир өчен аренда бәясе, коммуналь хезмәтләр белән, ай саен 50 мең сум кирәк икән. Моннан тыш, ашау-эчү, порошок-сабын, подгузник кебек көндәлек кирәк-яраклар... Тагын «Бишек»тә штатта өч хезмәткәр – ике комендант белән психолог бар. Аларга да хезмәт хакы түләргә кирәк.

– Февральдән бирле хәйриячеләр акчасына яшибез, – ди Элина. – Приют өчен ай саен 170 мең сум акча кирәк. Әлегә, Аллага шөкер, очны очка ялгыйбыз. Мәрхәмәтле кешеләрне социаль челтәрләр аша табабыз. Тик халык ярдәменә генә ышанып булмый. Шуңа күрә тагын грант алыр өчен махсус проект эшләдек, Мәскәүгә җибәрдек. Алырбыз, дип ышанам, чөнки мондый приют Татарстанда бүтән юк. Ә ул бик кирәк. Бүген тагын унлап хатын-кыз бездән җавап көтә. Барысына да урын җитми, кызганыч.

«Бишек»кә һәркемне дә алмыйлар. Беренче таләп: хатын-кыз тәртипсез тормыш рәвеше алып барырга тиеш түгел. Приютка ир-атларны алып килергә ярамый. Эчмәү, тартмау, аерым кагыйдәләргә буйсыну – аналарга барысы да алдан аңлатыла. Риза булучылар килә. Приюттан аналарны чыгарып җибәргән очраклар да булган.

– Бер хәйрияче белән таныштым, – ди Элина. – Чит илдә яши. Казанда дүрт бүлмәле фатир алган. Приют өчен шуны бушка биреп торырга тели. Ул фатирда әлеге хәйрияче унбиш-егерме елсыз яшәргә җыенмый. Менә шул фатирны җиһазлап, тәртипкә китерә алсак, тагын, ким дигәндә, дүрт-биш ана өчен яшәү урыны булыр иде.

Приютка хәйриячеләр тегү машинасы, телевизор бүләк иткән. Кул эшләре белән шөгыльләнү өчен биредә зур булмаган бер бүлмә ясаганнар. Аналар балалары йоклаган арада тегәргә өйрәнә. Киләчәктә бу өлкәдә тагын да күбрәк эшләргә уйлыйлар. Хәтта үзләре теккән киемнәр коллекциясен дә булдырырга ниятләре бар.

Приютта яшәүче һәр хатын-кызның язмышы үзенчә катлаулы. Кемнәдер ире ташлап киткән, кайсыдыр унҗиде яшендә бала табып, туганнары белән араны өзгән. Үзләре балалар йортында тәрбияләнеп үскән яшь аналар да бар. Берсен, көмәнле икәнен белгәч, егете ташлап киткән. Бу бәхетсез язмышлы аналарны бер нәрсә берләштерә – балалары өчен янып торалар. «Алар өчен яшибез», – диләр.

ЧИТ ИЛ ТӘҖРИБӘСЕ

Казанда «Бишек» приюты оешу, минемчә, бик яхшы күренеш. Шәһәр зур, ни генә булмас. Яшәргә торагы, ярдәм итәрдәй туганнары булмаса, нәни баласы булган ялгыз анага фатир арендалап яшәү бик авыр, хәтта мөмкин түгел.

ТР Мөселманнары Диния нәзарәтенә караган «Зәкәт» фонды

координаторы Гүзәлия Вәлиуллова белән дә элемтәгә кердем.

– Авыр хәлдә калган хатын-кызлар өчен махсус берәр юнәлеш юкмы? – дим.

– Узган елның декабрь азагыннан бирле атнага өч тапкыр авыру бала тәрбияләүче аналарны бергә җыябыз, – диде Гүзәлия. – Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы «Яшьлек» клубында, ял формасында үтә ул. Хатын-кызлар аерым бүлмәдә фитнес, бию белән шөгыльләнә, психолог белән аралаша. Ә балалар укытучылар, волонтер студентлар белән шөгыльләнә: рәсем ясый, укый, яза. Малай-кызларның сәламәтлеге, мөмкинлегенә карап...

Балалы хатын-кызлар «Зәкәт» фондына, ярдәм сорап, еш мөрәҗәгать итә. Без күбрәк авыру балалары булган аналарга ярдәм итәбез. Гаиләдә авыру бала туугa, ирләрнең күбесе тизрәк проблемадан качу ягын карый. Шуңа күрә андый аналарның 90 проценты ялгыз, безгә мөрәҗәгать итүчеләрне күздә тотам. Кайвакыт ана кешенең ипи алырга да акчасы булмый. Андый вакытларда үзебезнең сайтыбыз, социаль челтәрләр аша акча җыю игълан итәбез. Ярдәм итәләр. Ә торак мәсьәләсенә килгәндә, бездә андый мөмкинлекләр юк шул.

ТРнда ялгыз аналарга түләнә торган пособие (2018 ел өчен):

– ялгыз ананың баласына – 814 сум;
– ата яки ана кеше алимент түләүдән качкан яки түләтеп булмаган очракта – 460 сум.

(Мәгълүматлар ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан алынды).

Алга таба уйларга була, әлбәттә. Күз күрер.

...2013 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, АКШта 12 миллион тулы булмаган гаилә яшәгән. Аларның 80 проценты – ялгыз аналар. Һәм иң кызыгы – анда хатын-кызлар өчен приютлар юк. Ни өчен дигәндә, дәүләт яшь баласы булган ялгыз аналар өчен шактый күп программалар булдырган. Вакытлыча торак белән тәэмин итү, бушка азык-төлек бирү. Мисал өчен, аз керемле көмәнле яки биш яшькә кадәрле баласы булган ялгыз ана аерым кибетләрдән бушка сөт ризыклары, яшелчә, җиләк-җимеш, бөртекле һәм кузаклыларны ала. Мондый ризыкларның махсус исемлеге дә бар. Тагын, баласына 13 яшь тулганчы, ялгыз ананың кереме аз икән, дәүләт махсус пособие түләп тора. Шуңа күрә анага ике, өч эштә эшләргә туры килми. Һәм ана йөклелек чорында, бала тудырган вакытта бушлай медицина ярдәме дә ала.

Россиягә килгәндә, 5 миллион ялгыз ана – исәптә, ягъни һәр өченче гаилә тулы булмаган санала. Бездә ялгыз аналар ирле хатыннарга караганда әллә ни зур өстенлекләрдән файдаланмый. Бала өчен бирелә торган пособиенең суммасы шулай ук. Бер өстенлек: федераль закон буенча, ялгыз ана эшеннән кыскартыла алмый, эш хакыннан салым азрак тотыла (бала санына карап ул төрлечә). АКШ белән чагыштырганда, гаилә институты бездә барыбер көчлерәк әле, ялгыз аналар санын күздә тотам. Ә дәүләт ярдәменә килсәк, әлбәттә, без калышабыз...

Әйе, элек, совет чорында, яшь балалы ялгыз хатын-кызлар өчен приютларның кирәге булмаган. Дәүләт мондый аналарга чиратсыз фатир (һичьюгында, тулай торактан бүлмә) биргән. Ни кызганыч, бүген андый мөмкинлекләр юк. Ярый әле соңгы елларда социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга аналар өчен социаль йортлар булдыру өчен дәүләт грантлар бирә башлады. Тверь, Санкт-Петербург, Пермь кебек зур шәһәрләрдә дә шундый йортлар барлыкка килгән. Нишлисең, замана таләбе. Ике, өч баласы белән кайда төн уздырырга белмәгән аналар өчен бу бердәнбер урын. Һәрхәлдә, әлегә... ■

PRESSA.RU

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

Фото: Лилиана Вәлитова

ТАТАРЧА ФРАНЦУЗ **ТАРТЫ**

«Риваять» төркеме солисты, «Болгар» радиосы алып баручысы, авыл советы депутаты, университет укытучысы, тамада... Илмир Ямаловның вазыйфаларын тагын санарга була. Милли җанлы, эчкерсез, ачык күңелле кеше ул. Йөзеннән беркайчан елмаю китмәс. Мин аны яз кояшы белән тиңләр идем. (Әлбәттә, кояш белән гадәттә хатын-кызларны чагыштыралар, шулай да...)

Март салкыннарында якты нур эзләп, Илмир янына юнәлдек. Аның җылысы журнал укучыларыбызга да барып ирешер, дип уйлыйм.

«ЙОМЫРКА БӘЛЕШЕ»

Ямаловлар гаиләсе Казанда, Җиңү проспектында яши. Без килгәндә Илмир аш бүлмәсендә йөри иде, алъяпкыч бәйләгән. Башында кәләпүш.

– Бик килешә икән, өйдә сине мондый халәттә еш күреп буламы? – дим.

– Дөресен әйтимме, әллә матур итеп ялганлыйммы? – дип авызын ерды Илмир.

– Дөресен әйт...

– Аш бүлмәсенә мин бары тик ашарга гына керәм. Монда хәтта кайда нәрсә ятканын да белмим.

– Бер ризык та пешергәнең юкмы? – дим. – Бер дә сиңа охшамаган. Син бик өлгер, бөтен җиргә житешәсең кебек тоела.

– Өйләнгәнче әле нәрсәдер әзерли идем. Күкәйдән унике төрле ризык пешерә беләм. Түгәрәк йомыркадан күкәй бәлешенә кадәр (Тагын көлә. – Р.Ф.). Хәтерлим, студент чагында, бик ашыйсы килгәч, берьюлы унике түгәрәк күкәй пешереп ашадым. Иптәш егет кайткач, ит белән күкәй кыздырып ашады. Тәмле искә йокымнан уяндым да, аның белән бергә янә утырып ашадым. Шуннан эч борып алды... Башка алай күп күкәй ашамадым, сабак булды. Хәзер менә шул чакларны искә алам да көлешәбез. Хатынга да кайвакыт: «Күкәй бәлеше генә пешереп бирәсеңме әллә?» – дим. Рузиям исә еш кына ит бәлеше пешерә. Иркәләп бетерде ул мине: кайткан җиремә һәрвакыт кайнар ризык. Күп вакыт ят, бер дә ашамаган әйберләр әзерли. Интернетта төрле рецептлар күп бит хәзер. Хатыннан уңдым, Аллага шөкер: өйдә тәртип, балалар тәрбиядә. Әле, киресенчә, кайвакыт Рузияне ачуланам да: «Мин иҗат кешесе, тәртипсезлек тә булырга тиеш!», – дим

– Ә мин башкача булдыра алмыйм, – дип сүзгә кушылды Рузия. – Аунап яткан әйбер булса, эчем поша. Тузан күрсәм, кәефем кырыла. Тәртип кешенең өеннән башлана. Аннары ул тышкы кыяфәткә, үз-үзеңне тотышыңа да күчә...

Шуңа игътибар иттем: ир белән хатын бер-берсенә «җанашым», «нәнием» дия. Кызык тоелды:

– Сез гел шулай эндәшәсезме? – дим.

– Әйе, – ди Рузия. – Кайвакыт, кеше алдына Илмирга исеме белән эндәшсәм, сәер итеп карап тора,

Автор:
Руфия Фазылова

ИЛМИР ЯМАЛОВТАН АЛМА ТАРТЫ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:

1. Катлы камыр – 200 г
2. Алма – 3–4 данә
3. Шикәр комы – 100 г
4. Дарчин – 1 чәй кашыгы
5. Сыер мае – 100 г

PRESSA.RU

үпкәли. Очрашып йөри башлагач ул миңа «нәнием», мин аңа «җанашым» дигән идек, шуннан бирле башка сүз кулланмыйбыз.

– Тагын әле кайвакыт «әтисе», «әнисе» дип тә әйтәбез, – ди гаилә башлыгы.

Илмир тумышы белән Тукай районының Мусабай-Завод, Рузия Урта Шөн авылыннан (Киров өлкәсе). Гаилә корып яши башлауларына май аенда биш ел була. Дүрт яшьлек уллары Раян, ике яшьлек кызлары Рузинә үсеп килә. Балалар үткен, шук. Татарча сөйләшәләр. Тел мәсьәләсендә Илмир аеруча нык тора икән:

– Татар балалар бакчасы, татар төркеменә йөрсәк тә, безнең белән рус балалары да йөри, – ди ата кеше. – Нәниләр бер-берсе белән русча аралаша. Инде барып сөйләшеп тә карадым. «Татарча белмәүче малай-кызлар күп», – диләр. Шуңа туган телебез өчен өйдә көрәшергә кала. Үзең уйлап кара, бала бакчада иртәнге сигездән кичке алтыга кадәр тора. Өйгә йокларга гына кайта дисәм дә була. Әлбәттә, ул рус сүзләрен дә кыстырып сөйләшә. Ата-ананың бурычы – баласын төзәтү. Бер рус сүзе әйтте икән, иренмичә: «Моның татарчасы ничек?» – дип сорарга кирәк. Бала бу яшьтә тиз сеңдерә: татарча да, русча да яхшы белә. Менә шулай көн саен төзәтә, яңадан сорый торгач, туган телләрен онытмый алар. Безнең Раян татарча фикерли, шуңа сөенәм.

«ХАТЫН ЯРАТМЫЙ»

Илмир: «Алма тарты пешерәм», – дидем. «Тарт» – француз сүзе, безнеңчә ачык пирог инде ул. Ни өчен әлеге ризыкмы? Чөнки ул тиз һәм бик җиңел әзерләнә. Җитмәсә, пирог өчен катлы камырны да ясап торасы түгел. Илмир аны кибеттән сатып алган:

– Безнең туңдыргычта катлы камыр бетми, гел алып торам, – ди гаилә башлыгы. – Рузия тавык ботын да камырга төреп пешерә, итле, гөмбәле рулет, башкасын да ясый.

– Катлы камырдан ризык әзерләү бик җайлы, – диде Рузия. – Кеше киләсе булса да тиз генә туңдыргычтан алып берәр нәрсә куеп җибәрәм. Миңа калса, камыр ризыклары белән дус булмаган кешеләр дә катлы камырдан теләсә нәрсә ясый ала.

Илмир, аңа хас булган җитезлек белән алмаларны әрчеп, турап куйды. Аннан табага атланмай эретеп, алмаларны шунда салды. Өстенә дарчин (корица), шикәр комы өстәде. Талгын утта алмалар биш минут пешәргә тиеш икән.

– Пирог өсте матур булсын, «Илмир бигрәк оста икән», дисеннәр, – дип шаярта-шаярта гаилә башлыгы катлы камыр җәяргә кереште.

– Моңа кадәр камыр ризыгыннан берәр нәрсә пешергәнең бар идеме? – дим Илмиргә.

– Бер-ике тапкыр бар. Телевидениегә бер тапшыруга чакырганнар иде, шунда итле рулет әзерләдем. Тагын бер тапкыр хатынның туган көненә шарлотка сыман ризык пешергән идем. Дөресен генә әйткәндә, Рузия минем аш-су бүлмәсендә буталганны яратмый. Шуңа кысылмыйм да, эндәшмим дә. Нәрсә әзерли, шуны мактый-мактый ашыйм.

– Ә нинди ризыкларга өстенлек бирәсең?

– Барысын да. Итле ризык булса аеруча яратам. Мин катлаулы кеше түгел, нәрсә бар, шуңа риза...

Сөйләшә-сөйләшә камыр җәйгән арада алмалар майда пеште. Әзер массаны икенче табага бушаткач, Илмир шуның өстенә камыр җәйде. Һәм җырлый-җырлый электр мичենә тыкты.

– Биеп, елмаеп курайда, тальянда уйнаганыңны күргән бар. Җырлаганыңны ишеткәнем юк иде әле, – дим. – Бөтен талантларың өстенә җырчы да булырга ниятең юкмы?

– Банкетларда, мәҗлесләрдә җырлыйм. Ә үземне җырчы дип күрмим. Уен коралларында уйнаудан зур рәхәтлек алам. Мин әллә ничә җирдә эшләп карадым. Алабуга мәдәният-агарту училищесын тәмамлагач, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына кердем. Һәм аспирантурада калдым. Өч ел университетта студентларга белем бирдем. Укытучылык эше миңа бик күп нәрсә бирде: вакытны дөрес бүләргә, үз өстемдә эшләргә өйрәндем.

– «Болгар» радиосына ничек килдең? Бу өлкә синең өчен яңалык дип беләм.

– Әйе, яңалык. Радиога кастингка барган идем, әле «Чәкчәк»ләрнең теге төркеме иде. Ул вакытта мине алмадылар. Аннан, яңа төркем оешкач, шалтыратып чакырдылар. Әлбәттә, сөендем. Иртәнге биштә торуны санамаганда, радиода эшләүнең авыр якларын күрмим. Мин тик тора торган кеше түгел. Тагын башка планнарым да бар: төрле өлкәләрдә эшләп карыйсым килә.

– Син әле депутат та, – дим.

– Туган авылым Мусабай-Заводта җирле депутат итеп сайладылар. Туган авылымны бик яратам, бүгенгә кадәр теркәлү урыным да шунда. Җай чыккан саен Мусабайга кайтырга тырышабыз. Сабантуй, башка бәйрәм дисеңме, концерт куймый китмим. Авылдашларның, җирле җитәкчеләрнең миңа карата мөнәсәбәте җылы, рәхмәт яусын.

«ПЛАНДА – БИШӘҮ»

Алма пирогы унбиш минутта әзер дә булды. Илмир шаяра-көлә мичне ачты.

– Телегезне йотасыз хәзер, – ди.

Алма тарты ачык пирог кебек дигән идем бит. Ә мичтә ул ябык килеш пеште. Илмир пирогны тәлинкәгә әйләндереп каплады, алмалар өстә утырып калды. Корицаның хуш исе бөтен фатирга таралды.

– Туктагыз, пирог елмаеп торсын әле, – дип Илмир өстәлдәге кызыл алманы алып кисәкләргә бүлде. Виноград төшләрен урталай кисте. Һәм пирог өстен бизәп тә куйды.

– Хәзер чәй эчәбез, яме! Тәмле булмаса да, тәмле дип яз инде...

– Ирең өйдә дә гел шулай күп сөйләп, шаяртып йөриме? – дим Рузиягә. Юк кына әйбердән дә мәзәк ясый.

– Шундыйрак. Ул өйдә чакта без бер минут та тик тормыйбыз. Йә кунакка, йә кибеткә чыгып китәбез. Ут инде ул, ут...

– «Ут»ның яндырган чаклары, ягъни кәефсез вакыты буламы?

– Нигездә юк. Банкетлардан арып кайткан чагында керә дә диванга егыла. Бернičә сәгать үтүгә янә көлә, сөйли. «Әһә, моның аккумуляторы көч җыйган», – дим.

Рузиянең катлы камырга төреп пешергән тавыгы янына Илмир әле генә табадан төшкән ачык пирогын кисеп куйды. Шул арада гаилә башлыгы барыбызны бергә фотога төшерде, аны тиз генә социаль челтәрләргә куйды.

– Йә, кызлар, пирогы нихәл? – ди.

– Баллы, сусыл, кыскасы, тәмле, – дим.

Чынлап та, ачык пирог тәмле килеп чыккан. Алдашып торасы да булмады! Сыер маенда пешкән алма туклыклылык, ә корица шәрык ризыкларына хас бер татлы тәм бирә.

– Илмир, моннан соң бәйрәмнәрдә Рузиягә менә шушы пирогны пешерә торган бул, – дим.

– Мине аш-су бүлмәсенә кертсә, – дип кинaя белән елмайды ир.

Илмир белән җитдирәк темаларга да сөйләштек. Җиденче сыйныфта укыганда әтисен югалта ул. Үзе әйткәнчә, әйтерсең бер мизгел эчендә олыгаеп китә.

– Әти вафатыннан соң дистә ел узгач әни янә кияүгә чыкты. Флер абый әйбәт кеше, тик күңелем белән башта бу яңалыкны авыр кичердем. Һич онытасым юк, Алабуга мәдәният агарту училищесында укып йөргән чак. Ялга кайткач, әни каршыма килеп утырды да: «Улым, Флер абыең, бергә яшик, дип әйтә. Син ни уйлыйсың?» – диде. Иң беренче сүзем: «Мин аның өенә бармыйм!» – булды. Флер абый безнең авылныкы, үз йорты белән яши. Әни маллар асрады, ул килеп булышып йөрде. Мин бу турыда белсәм дә, әнинең кияүгә чыгуына әзер түгел идем. Әллә көнләшү булды, әллә яшьлек шунда. Тора-бара бу яңалыкка күндем, Флер абыйны үз иттем, әтием урынына күрәм, дисәм, һич ялган булмас. Киресенчә, әни янында ышанычлы терәк булу, миңа тынычлык бирә. Ни дисәң дә, без атна саен кайтып йөри алмыйбыз. Үзем әти булгач, әнигә карата мөнәсәбәтем тагын да яхшырды. Авылга кайткач, сәгатьләр буе сөйләшеп утырабыз. Ирсез көе ике баласына белем-тәрбия бирде ул. Аңа булган кадер-хөрмәтемне әйтеп бетерә торган түгел. Әнигә шалтыратмыйча калган бер генә көнем дә юк, әле көнгә ике дә була. Исән-сау гына булсыннар.

– Ә гаиләдә бер-берегезгә карата көнләшү юкмы? – дим.

– Мин бик тугры кеше. Хәтта йөргән кызларым да юк диярлек иде. Берәү белән очраша башласам, бетте – күзгә башкалар күренми. Хатынымны да көнләшмим, тормышта аннан башка проблемалар да җитәрлек. Рузия дә, колак ишетмәгән булсын, көнләшеп аптыратмый. Иҗат кешесе өчен бик мөһим ул. Без «Риваять» төркеме белән еш кына гастрольләргә чыгып китәбез. Мисал өчен бүген таң аткач кына кайттым. Әгәр хатын минут саен борчып шалтыратса, тавыш чыгарса, иҗат итәргә теләк дә, мөмкинлек тә булмас иде. Моның өчен бик зур рәхмәт аңа.

Бу темага Рузия белән дә сөйләшеп алдым. Ни дисәң дә, гаиләдә иң авыр йөк аңа төшә бит: иртән биштә торып ирен эфирга ашатып-эчертеп җибәрә. Аннан уллары Раянны балалар бакчасына җыя. Әле кечкенә Рузинә дә бар.

– Көнләшмим, иремә ышанам мин, – ди Рузия. – Аллага шөкер, безнең гаиләдә гармония. Ирем, балаларыбыз дип яшим. Барысына да өлгерергә тырышам. Раянны бакчага илткәндә, элек Рузинәне дә алып бара идем. Хәзер кечкенәсен өйдә үзен генә калдыра башладым. Балалар бакчасы күршедә генә, ун минутта әйләнеп кайтам. Аннан өй эшләренә чумам. Декретта утырганга дүрт елдан артты инде, кайвакыт эшкә дә чыгасы килә...

– Рузия өйдә булса, миңа рәхәт, тыныч, – ди Илмир. – Балалар дип борчыласы юк. Безнең планда биш бала алып кайту. Инде икебез дә утыз дистәне тутырдык, шулай булгач, ашыгырга кирәк.

Чынлап та, Ямаловлар ишле гаилә булырга телиләр икән. Салмачи бистәсендә җир алганнар. Инде бүгеннән үк шунда зур йорт салып, балалар, оныклар үстерү турында хыялланалар. Бирсен Ходай. Мондый милли җанлы, матур гаиләләрдә шундый ук сәләтле, акыллы татар балалары да үсәр.

1. Әрчибез!

2. Турыйбыз!

3. Салабыз!

4. Өстибез!

5. Бутыйбыз!

6. Эретәбез!

7. Пешерәбез!

8. Бушатабыз!

9. Җәябез!

10. Каплыйбыз!

11. Куябыз!

12. Әйләндерәбез!

PRESSA.RU

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Фатих Хөсни нигезендә **НӘРСӘ** урнашкан

Кубрат хан **НИНДИ** васыять калдырган

Быел «Оскар» **НИК** гаҗәпләндерде

Ютазы җилләре **КАЙ** яктан исә

«КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ» ПРОЕКТЫНЫҢ КАРТАСЫ

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

«ДӨНЬЯГА БИЕКТӘН КАРАРГА ЯРАТАМ...»

Фатих Хөсни турындагы истәлегендә әдәбият галиме Фоат Галимуллин болай дип яза: «Фатих Хөсни фатиры югары катларның берсендә. «Олы кешегә менеп-төшеп йөрүләре кыендыр бит, түбәнгерәк катта урнашмагансыз», – дим. Фатих абый, гадәттәгечә уенын-чынын бергә кушып: «Дөньяга биектән карарга яратам, өстән дөнья күбрәк ачыла», – ди...» Әлеге факт, миңа калса, Фатих Хөснинең иҗат принципларын да аермачык күрсәтә – әсәрне иң югары дәрәҗәдәге камиллеккә ирештерү, аны булдыра алган кадәр биеклеккә күтәрү. Юкса «Фатих Хөсни теле», «Фатих Хөсни өслүбе» дигән төшенчә булмас та иде, бәлки, татар әдәбиятында.

Автор:
Луиза Янсуар

«МИНЕ ФАТИХ ХӨСНИ ЯЗДЫ!»

«Тел маркасы»н тоткан әдип ул Фатих ага», – дигәннәрен ишеткәнем бар аның хакында язучыларның. Әлеге «марка»га, ягъни «биеклек»кә җитүне һәр башлап язучы прозаик алдына куя зәвыклы татар укучысы. Фатих Хөсни аеруча үз итеп эшләгән «кече жанрларда» аны җилдереп узучылар юк әле, дип әйтсәк, ялгышмабыз, минемчә. Хәер, әдәбият – алыш мәйданы түгел, язучы өчен, иң беренче чиратта, гомерлек өйрәнү мәктәбе ул. Ә минә Хөснидән өйрәнеп, аның мәктәбен үтеп, үз тел-өслүбен булдыручылар, прозаны яңа горизонтларга алып чыгучылар, ягъни аның шәкертләре, бар яңа заман әдәбиятында.

Безнең буын Фатих Хөсни әсәрләрен укып кына түгел, ә яттан белеп, аның барлык сыр-бизәкләрен күңеле аша үткәреп, геройларының язмышларын үз язмышыдай кичереп үсте. Китапларындагы хәлләрне, вакыйгаларны аңына сеңдереп. Минем, мәсәлән, җәй көне агач ботагыннан хуш исле алма өзеп капканда, Айдарга «иң эре», «иң матур» алманы ыргыткан Вәсилә күз алдыма килеп басмый калмый. Әлеге геройлар безнең хәтер генофондына мәңгегә кереп урнашкан, күрәсең. Тел мәсьәләсенә килгәндә дә шулай: Фатих Хөсни әсәреннән берәр өзекне укысалар, аның кемнеке икәнен шунда ук ваемлап аласың. Әллә каян «мине Фатих Хөсни язды» дип кычкырып торачак. Язучының исә мондый сүзләре теркәлеп калган: «Кемгә, нигә кирәге бар аның – олы газаптан башка туган һәм кешеләргә булышмый торган матур сүзнең! Матур идеядән башка матур тел була алмый, дусларым». Шулай итеп, ул әдәбиятка тагын бер үтә дә җаваплы бурычны йөкли – кешеләргә булышу бурычын. Димәк ки, әхлакый-сәнгати категорияләргә дә алып чыга безне.

Татар әдәбиятында өр-яңа үзенчәлекле кыска лирик новелла-хикәяләр, шулай ук, беренче карашка, бер-берсеннән шактый ерак торган лирика белән юморны укмаштырган повестьлар жанрын искиткеч камиллеккә җиткергән әдип буларак билгеле Фатих Хөсни. Үзе искә алганча, аңа классиклар зур йогынты ясаган, бигрәк тә – Антон Чехов. Фатих Хөсни, остазы Чеховча, кеше психологиясен бөтенләй кötелмәгән вак һәм эре детальләр аша чагылдыра белүче язучы да.

Фотолар: Луиза Янсуар, Фатих Хөсни музее архивыннан

«Татарстан» журналы инде ике ел дәвамында алып барган **«Кече ватан патриотлары» проектының максаты** – татарстанлыларны республикабызның исемнәре онытылыбрак барган талантлы шәхесләре, әдәбият-сәнгать әһелләре белән таныштыру. «Татарстан» журналы республикада яшәүче халык арасында уздырган сораштырулар шуны күрсәтте: күпләр ХХ йөзнең күп кенә күренекле шәхесләрен инде онытып бара. Абдулла Алиш, Гаяз Исхакый, Шәйхи Маннур… хәтта әлеге исемнәрне ишеткәч тә «танылган кеше инде», «шундый урам бар», «кем дип әйтсәм дә читенсенәм…» кебек җаваплар алырга туры килде.



Проект кысаларында без Татарстан районнарына чыгабыз. Анда, кече ватанда, талантлы якташлары турындагы истәлекләрне кадерләп саклаучы кешеләр белән очрашып, күренекле шәхесләрне яңадан «кайтарабыз». Кайбер туристик маршрутларның шактый еракта булуына карамастан, барыбер барабыз. Музейлар, туган нигез, без язган шәхесләрне кайчандыр белгән җирле кешеләр – болар барысы да Татарстанның олы байлыгы.

Теленә яңадан әйләнеп кайтсак, мин аның мондый үзенчәлеген дә ассызыклап үтәр идем: без бүген авыл культурасы белән бергә югалтып барган аутентик яңгырашны, еллар буена эшкәртеп, баетып, сүз сәнгатенең иң асыл биеклегенә күтәрә алган сүз остасы ул. Бүген татар әдәби теле тирәсендә барган бәхәсләрне куертучыларга әйтәсе килә: «Фатих Хөсни әсәрләрен укыйк та әдәби телебезнең ни дәрәҗәдә бай, затлы булуын ваемлыйк, шушы байлыкны югалтмаска омтылыйк!» Билгеле, сөйләм теле дә, шуның белән беррәттән, әсәрләрнең теле дә туктаусыз үсеш-үзгәреш кичереп тора. Тел ул, гомумән, даими яңарып торучан катлаулы һәм бик хәрәкәтчән структура. Әмма аның ярлылануы, көнкүреш калыпларына гына «төшеп бетүе» котылгысыз рәвештә безнең рухыбызның ярлылануына да китерәчәк ләбаса.

«Фатих Хөсни – чын мәгънәсендә телнең сихерчесе. Ул озынозын аралар белән язарга ярата. Һәр яңасына аяк басканда, син әле авторның үзеңне кая китерәсен белмисең. Аның җөмләләре махсус катлауландырылган һәм бизәкләр белән баетылган була, әйтерсең, җете, зиннәтле татар орнаменты. Еш кына, нинди дә булса кызыклы эпизод, образлы чагыштыру, урынлы, ә кайчак укучыга хәтта урынсыз да тоелып куйган хатирә белән мавыгып китеп, автор безне бөтенләй башка юнәлеш буенча алып китә, төп сюжеттан ераклаша. Гөлҗимеш куаклары арасыннан талгын гына агып яткан елга дияр-сең – ул да, яр тигезсезләнгән, боргаланган-сыргаланган урыннарда, әнә шулай хикмәтле борылышлар ясый бит. Кайбер тәнкыйтьчеләр Фатих Хөснине әлеге «лирик элмәк»ләре өчен гаепли дә. Әмма прозасының бар күркәмлеге шунда лабаса бу әдипнең».

Рафаэль Мостафин, язучы.

«Фатих Хөсни – һәр әсәренең теленә-яңгырашына иң нык игътибар иткән, җөмләләрен сингармонизм законына буйсындырган, музыкальлеккә ирешкән әдип. Бервакыт ул миңа:

– Күз белән генә язу җитми, колак белән дә язарга кирәк, – дигән иде. Юк, әдәбиятыбызның классигы һич тә, күргәнең, ишеткәнеңнең һәммәсен дә язарга кирәк, дип әйтми, бәлки язган чагында камиллеккә

PRESSA.RU



Фатих Хөснинең туган нигезе урынында хәзер мәчет урнашкан

ирешү ягын кайгырта, шуңа өнди. Чөнки ул үзенең һәр әсәрен, мәрмәр чүкеп ясагандай, тәмам җиренә җиткермичә туктый белмәгән әдип».

Кыям Миңлебаев, язучы.

Башка шактый гына прозаиклар шикелле үк, чәчмә жанрга тезмә жанр, ягъни шигърият аша килгән әдип Фатих Хөсни. «Шагыйрь буларак башлаган язучылардан гадәттә әйбәт прозаиклар чыга» дияргә яраталар безнең әдәби мохиттә. Ул бу гыйбарәнең иң күркәм бер үрнәге.

«НИГЕЗЕ СУЫНМЫЙ...»

Без Олы Мәтәскәгә килеп төшкән көн чалт аяз, якты булса да, зәмһәрир суык иде. Күркәм, җыйнак авыл иртәнге нурларга коенып алдыбызда җәйрәп ята – менә ул, Фатих Хөснинең әсәрләренә кереп урнашкан хозурлык кайдан икән. Мәдәният йорты каршысына килеп тукталдык. Монда авыр ябалдашларын кояш алтынга манган төз наратлар «гаскәре» каршы алды. Ишектә, ягымлы елмаеп, Фатих Хөсни музее директоры Занфира Хуҗиәхмәтова пәйда булды. Күптән таныш, үз кешеләрдәй кабул итте ул безне.

– Ә Фатих Хөсни нигезен күреп булыр микән? – дип үтендем Занфира ханымнан.

– Ә сез аны яңа гына узып киттегез ләбаса, – дип елмайды Занфира ханым, – ул урында мәчет безнең хәзер. Җирле эшкуар салдырды. Монда ике адым гына бит, әйдәгез, кереп чыгыйк...

Мәчеткә юл тоттык. Занфира ханым «Мин хәзер», дип, елдам гына бер йортның капкасыннан кереп югалды. Мәчет ачкычын «кирәге чыкканда кереп алыр өчен» күршеләрдә калдыралар икән. «Монда гадәтләр һаман да «үзебезчә», «авылдагыча», – дип уйлап куйдым мин. Һәм, куырып алган салкынга карамастан, күңел җылынып китте.

– Фатих аганың рухы тыныч булсын инде – аның туган нигезендә хәзер көн дә дога яңгырый, биредән кеше өзелми. Ул бит әсәрләрендә һәрчак тамырлары белән җиргә береккән гап-гади хезмәт кешеләрен, авылдашларын күрсәтте, аларны олылады, менә хәзер шул кешеләрнең оныклары килә мәчеткә. Үз балалары белән оныклары еракта – чит илләрдә бит, гел кайтып йөри алмыйлар. Аңа карап нигез суынмый, узганбарганда «бу бит Фатих ага нигезе» дип уйлап китәбез еш кына...

Ә икенче «нигезе» – Мәдәният йортының икенче катында аның. Фатих Хөсни музее зур булмаган җыйнак кына бүлмәдән гыйбарәт. Ул исәндә әдипнең кабинеты нинди булган, шуны кабатлый. Идәндә шул ук палас, ул утырып эшләгән өстәл, баса торган машинкасы, үз куллары белән ясаган урындыгы һәм бизәкле, инициаллары уелган, шигырьләргә кергән таягы...

Фатих Хөсни музее 1998 елда җирле үзидарә башлыгы Миңнеәхмәт Габдуллович Вәлиуллин һәм музейның беренче директоры Люция Имамиева көче белән Фатих Хөснинең вафатыннан соң ачыла. Алар икәүләп язучының шәхси әйберләрен, архивларын җыеп алып кайталар, һәм аның эш кабинетын формалаштыралар. Хәтта гантельләргә кадәр Фатих Хөсни ничек куя торган булса, шулай ята, әйтүләре буенча.

– Бездә аның хатлары, язмалары, открыткалары, бүләкләре саклана. Күрегез әле, никадәр хат белән открытка! – дип, шкафларга ишарә итә Занфира ханым. – Минем үз гомеремдә берәүнең өендә дә шулкадәр корреспонденция күргәнем булмады. Фатих ага барысын да хасиятләп җыеп барган, тәртипләп саклаган. Без ул тәртипне бозмаска тырышабыз. Кайчак музейга аның иҗаты буенча диплом эше язучы студентлар, диссертациягә материал туплаучы аспирантлар килә – алар рәхәтләнеп өйрәнә архивларны. Әмма тәртибен бозмаска кушабыз, кисәтәбез... Ә менә монда шундый ук ул яраткан пөхтәлек белән бүләкләрен урнаштырдык: медаль-орденнары, Тукай премиясе...

– Ә китапханәсе тулаем шушындамы? – дип сорыйм.

– Зур өлеше биредә, – ди Занфира ханым. – Шул исәптән аңа язучылар автограф белән бүләк иткән китаплар да.

– Хәзер музейлар, бигрәк тә авылныкылар, шактый мөшкел хәлдә. Сездә дә шул хәлме?

Әмма Занфира ханым мине сөендерергә ашыга:

– Юк, килмиләр, дип әйтмәс идем. Хәтта башка төбәкләрдән дә кабул итәбез кунакларны. Менә әле күптән түгел генә Оренбургтан килеп киттеләр. Берәве хәтта хатлар арасында туганыныкын абайлап алды. Чиксез гаҗәпләнде: «Мин аны кайчандыр Фатих Хөснигә хат язгандыр дип башыма да китереп караганым булмады! Менә могҗиза!» Әйткәнемчә, студентлар еш килә, мәктәп укучылары...

Мин Фатих Хөснинең өстәле артына утырып, урындыгын һәм язу машинкасын «сынап» карыйм. Урындыгы искиткеч җайлы, йомшак һәм утырганда җылы булсын өчен,

Фатих Хөсни музее директоры Занфира Хуҗиәхмәтова

Фатих Хөснинең гантельләре

1998 елда ТР Министрлар кабинеты карары буенча Олы Мәтәскә урта мәктәбенә Фатих Хөсни исеме бирелә. Ә Мәдәният йортында Фатих Хөсни музее ачыла.

төбенә тире дә салып куелган. Таягы урындык артына «эләктерелгән». Машинка да бирешми әле – бүген утырып роман языйм дисәң, рәхәтләнеп файдалан гына. Өстәлдә Фатих Хөснинең калын пыялалы күзлеге һәм лупасы йокымсырый. Сукыраеп барган язучының аерылгысыз юлдашлары, дигән уй йөгереп уза башымнан. Миндә Фатих Хөсни никтер һәрчак иженче бер язучы белән ассоциация уята – Борхесны әйтүем. Икесе дә, сукыраюга карамастан, гаҗәеп пөхтә, әйберләрен дә, архивларын да, кабинеттагы барлык эш атрибутларын да тәртиптә тоткан язучылар. Без, бүгенге информацион гасыр буыны вәкилләре, бөтен язганнарыбызны бер селтәнүдә delete төймәсенә басып сөртеп ташлый алабыз – смсларны да, хатларны, «опус»ларыбызны да... Ә бу язучы михрабы безне һәр хатка, һәр котлау открыткасына, һәр предметка сак карарга, ихтирамлы булырга өйрәтә...

Ул арада Занфира ханым Фатих Хөснинең гантельләрен дә «сынап» карарга өнди. Шулай итәбез дә – авыр булсалар да, тешне кысып, күтәрәбез.

– Көн дә шулар белән шөгыльләнгән, өстәвенә әле йөгерә торган да булган, – дип елмая музей директоры. – Язучы кешегә тәнен язарга кирәк бит аңа – эшләре утырып эшләнә, ә хәзерге кебек спортзаллар, фитнес-заллар булмаган ул чакта...

УҢЫШ БЕЛӘН ХӘТӘР – ЯНӘШӘ

1908 елның 3 февралендә Татарстанның хәзерге Саба районы Олы Мәтәскә авылында дөньяга килгән Фатих башлангыч белемне авылында ала. 1924 елда ул Казанга килә, Мулланур Вахитов исемендәге күргәзмә-тәҗрибә мәктәбенә укырга керә. Шунда укыганда шигырьләр яза башлый, беренче әсәрләре «Безнең юл», «Авыл яшьләре», «Яңалиф», «Атака» журналларында басылып чыга. Бу уңыш яшь егеткә дәрт өсти – ул үзен мәкалә-очерклар, проза һәм драматургия өлкәсендә дә сынап карарга ниятли.

1929 елда Фатих Хөсни Казан дәүләт университетының экономика факультетына укырга керә. Аны тәмамлагач, армиягә алына – 1933–1935 елларда Казандагы Беренче укчы дивизиядә элемтәче, соңрак хәрби корреспондент булып эшли. Армиядән кайткач, Татар АССРның Финанс министрлыгында, төрле газета редакцияләрендә хезмәт куя, журналист буларак авылларга чыга, завод-фабрикаларга йөри, эшчеләр белән таныша, хезмәт кешесенең тормышын өйрәнә. Дусты Ибраһим Гази аны әдәби җыеннарда дәртләнеп бәхәсләшә һәм әдәбият турындагы дискуссияләрдә актив катнаша торган активист буларак искә ала: «Күн пәлтәдән, тезенә кадәр шнурланган ботинкалардан, яшь, дәрте ташып торган Хөсни студентны яисә шагыйрьне хәтерләтүдән бигрәк, бронемашина шоферына охшап тора иде. Әмма ул шагыйрь иде, башлап язучы шагыйрь, армый-талмый бәхәсләшергә әзер шагыйрь...»

1929 ел Фатих Хөсни өчен уңышлы ел була: 4 актлы «Усаллар» пьесасы аерым китап булып басылып чыга. Исеме «Чаян», «Совет әдәбияты» журналлары, «Кызыл яшьләр», «Кызыл Татарстан» газеталары битләрендә даими күренә башлый. Озак та үтми, ул үзенең тәүге эре әсәрен – «Җир тыңлый» романының беренче китабын да бастырып чыгара. Әмма беренче уңышларыннан соң зур иҗади планнар белән яшәгән Фатих Хөснигә хәтәр, система гөрзие булып, көтмәгәндә-уйламаганда китереп суга. Романны кискен тәнкыйтьлиләр, ә Фатих Хөснинең үзен «ялгыш идеология тарафдары булуда», «кулаклар фәлсәфәсен данлауда» гаеплиләр. Бер сүз белән әйткәндә, аның әсәре аякка басып килүче яшь совет иленә кирәкле булудан бигрәк, аңа «дошман әсәр» буларак бәяләнә.

Орден-бүләкләре

«Татарстанның халык язучысы» мактаулы исемен раслаучы таныклык

PRESSA.RU

Язучының хатлары

«Татар пролетар язучылары ассоциациясе» утырышында романны бөтенләй пыран-заран китереп ташлыйлар. Фатих Хөснине ватанын һәм анда яшәүче хезмәт халкын «пычратуда» гаеплиләр. Ул елларның нинди идеологик басым еллары булуын искә төшерсәк, бу карарның ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеген аңлау кыен түгел. «Татар пролетар язучылары ассоциациясе» протоколына караганда, баштарак Фатих Хөснинең тәнкыйтькә әллә ни исе китми. Әмма тора-бара, вердикт «бу әсәр – пролетар әдәбиятта ничек язарга ярамауның үрнәге» дигән рәвешне алганнан соң, ул ике ут арасында кала. 1931 елның июлендә «Атака» журналында Фатих Хөснинең тәүбәсе басылып чыга. Яңалифтә басылган әлеге тексттан язучыга янаган хәтәрнең кайтавазы яңгырап тора – Фатих Хөсни тәүбәсендә киләчәктә үзенең сәяси ялгышын төзәтергә, язылачак әсәрләрендә совет хакимиятнең казанышларын яктыртырга, кулаклар белән аяусыз көрәш алып барырга вәгъдә бирә.

Шулай итеп язучыга әле иҗат юлының башында ук уңыш белән хәтәрнең һәрчак янәшә йөргәнлеген үз җилкәсендә татырга туры килә. Әлеге куркыныч романга ул 1960 нчы елларда гына кабат әйләнеп кайта. Нәтиҗәдә безгә бик яхшы таныш булган «Утызынчы ел» романы пәйда була.

Сәгате һәм утырып эшләгән урындыгы. Урындык башында үз кулы белән ясаган атаклы таяк

«ХӘРБИ ҖЕПШЕКЛЕК», ЯКИ «ЙӨЗЕК КАШЫ»

Вакыйга язучының күңелендә җуелмас эз калдыра. Әмма аны әдәбиятта «авыл прозасы», «авыл темасы» дип йөртелә торган сыеныр почмак коткара. Алга таба әсәрләрендә нәкъ менә авыл кешесенең тормыш-көнкүрешен гаҗәеп нечкә лирик кичерешләр гаммасына һәм юмористик-иронияле калыпка, пафоска төреп сурәтләү осталыгына ирешә Фатих Хөсни. Ул тудырган «кече жанр» тәнкыйть тарафыннан җылы каршы алына. Ниһаять, «үз сукмагын» таба ул татар әдәбияты мәйданында.

Бөек Ватан сугышы елларында Фатих Хөсни берара «Сталин әләме» дигән фронт газетасы белән хезмәттәшлек итә. Хәрби корреспондент буларак, фронтны айкап чыга. Сугышта күргән һәм кичергән күпчелек вакыйгалар аның әсәрләренә нигез була.

1942–1943 елларны «хәрби җепшеклек» еллары дип атап йөртү гадәткә кергән. Нәкъ менә шушы чорда СССРның мәдәният әһелләренә иҗатларында милли символларны кулланырга рөхсәт бирелә – патриотик тәрбия максатыннан, билгеле. «Җепшеклек» дулкыны»нда күп кенә матур милли әсәрләр иҗат ителә. Татар әдәбиятының иң асыл классик әсәрләреннән саналган «Йөзек кашы» повесте да әнә шул чорга карый. Әмма «җепшеклек» ничек кинәт кенә пәйда булса, «игълан ителсә», шулай ук тиз арада «гамәлдән дә чыгарыла». 1944 елның 9 августында ВКП (б) ҮК тарафыннан «Татар партия оешмасындагы массачыл-сәяси һәм идеологик эшне яхшыртуның торышы һәм дәрәҗәсе турында» дигән карар кабул ителә. 1944 елда Татар ВКП (б) өлкә комитетын З.И. Моратов җитәкли һәм ул милли интеллигенцияне кискен контрольдә тотуны шарт итеп куя. Әдәбият та, театрларның репертуарлары да, татар теле, әдәбияты һәм тарихы белән шөгыльләнүче галимнәр дә даими күзәтелә, тикшерелә башлый. 1946 елның 31 октябрендә узган сугыштан соңгы беренче язучылар җыенында күп кенә язучыларның әсәрләре тәнкыйтьләнеп, үзләренә «төзәлергә» киңәш бирелә. Фатих Хөсни, инде бу сынауны бер мәртәбә узган кеше буларак,

1996 елда ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлеге Фатих Хөсни исемендәге премия булдыра. Әлеге премия ел саен халыкта резонанс уяткан елның иң яхшы проза әсәренә, яисә Фатих Хөснинең биографиясен өйрәнүгә багышланган хезмәт өчен бирелә.

элеккечә ирония һәм лирика канатына төренеп, зур саклык белән эш итә. Аның «Авыл өстендә йолдызлар», «Җәяүле кеше сукмагы» кебек классик мирас булачак әсәрләре басылып чыга.

Сәфәргали образы минем үземә гаять якын образ. «Җәяүле кеше сукмагын» кат-кат укыган бабам гел кабатлый торган иде: «Кызым, бу бит безнең турыда...» Тар-кысан авыл мохитеннән «зур дөньяга» чыккан гади авыл малае язмышы аша тулы бер тарихи чорга, үз эпохасына, аның «кечкенә» һәм «зур» кешеләренә бәя бирә Фатих Хөсни. Әлбәттә, совет системасының таләпләренә туры килердәй итеп. Әмма әсәрнең полифониясенә, катламнарына, аһәңенә ныграк колак салсаң, сүз белән турыдан-туры язылмаса да, барыбер «ишетелгән» авазларны тоеп алырга бик мөмкин.

1955–1957 елларда Фатих Хөсни ТАССР Язучылар берлегенең идарә секретаре вазыйфасын башкара. 1958 елдан ул бары тик профессиональ язучылык эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Гомеренең алдагы елларында әсәрләрен Камал театры сәхнәсеннән күрү бәхетенә ирешә мэтр-язучы, яшь каләм әһелләре, студентлар белән тәҗрибә уртаклаша. Вакытлы матбугатта әдәби-тәнкыйди мәкаләләр белән еш чыгыш ясый, телнең сафлыгын яклап күтәрелә. 1972 елда «Гыйльменисa һәм аның күршеләре» җыентыгы өчен Габдулла Тукай исемендәге бүләккә лаек дип табыла. Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары белән бүләклиләр аны. 1993 елда Фатих Хөснигә «Татарстанның халык язучысы» дигән исем бирелә. 1996 елда вафат булган әдип Казанда җирләнгән.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

АЛАР – ЗАТЛЫ НӘСЕЛДӘН

Фәүзия Садыйкова, Олы Мәтәскә авылындагы күршеләре:

– Кышкы урманнан боз булып катып кайтып төште бу, минсиңәйтим! «Нәрсә чаңгы киеп урманда нужа куып йөрисең, монда беткәнмени әллә ул нужа?» – дип шаяртам. Ә ул бик сабыр, әдәпле кеше иде. Көлә генә: «Эх, белсәң иде син кышкы урманның рәхәтлеген! Мин бит шул урманны күңелемә җыеп, тутырып алып кайттым!» – ди. Әсәрләре өчен шулай кирәк булгандыр инде, юкса ул табигатьне ничек шулкадәр нечкәлек белән тасвирлап язып бирә алыр иде. Безнең урманнар шаулап тора бит аның әсәрләрендә...

Авылны урап йөрергә бик ярата иде, тирә-як басу-кырларга чыгарга. Мунча керми калмый, кайткач, авыл картлары белән капка төбендә сөйләшеп утырмыйча китми. Үзе генә дә кайта иде, улы Рафаэль белән дә. Кайчакта эте белән дә – ауга чыгарга яратты.

Алар бит иң авыр елларны күреп үскән буын – 20 нче еллар ачлыгын, аннары сугышны. Дөрес, гаиләләре, нигезләре ныклы иде Фатих абыйларның, хәлле кешеләрдән алар. Затлы нәсел дә бит – барысы да укымышлы кешеләр, укытучылар. Әмма, шуңа да карамастан, беркайчан да борын чөеп йөргәннәрен хәтерләмим. Бик тәрбияле, тыныч, зирәк булдылар. Телгә җор иде Фатих абый, әмма усал түгел, юморы да ягымлы, акыллы. Күрәсең, алма агачыннан ерак төшмидер, балалары да зур кешеләр булдылар, чит илгә китеп тә, югалып калмадылар.

ӨЕ ТУЛЫ КӘГАЗЬ-КИТАП ИДЕ...

Нәкыя Сәләхиева, Фатих Хөснинең туганы:

– «Килдегезме? Менә әйбәт булган!» – шулай дип каршы ала иде безне һәрчак. Кешегә игътибарлы, ихтирамлы кеше иде. Язучы булгач, шулкадәр дә олы кеше булгач, үзен эре тотса да аптырамассың. Әмма андый чагын хәтерләмим. 70 еллык юбилеен Камал театрында уздырдылар. Театр халык белән шыгрым тулы иде. Шунда да ул безне, туган-тумачасын, кул биреп каршы алды, урнаштырды. Ирек Баһмановның уйнаганы хәтердә калган ул кичәдә... Аннары Фатих агаларның фатирларына кунарга кайттык. Фатих аганың эш бүлмәсендә дә, өйләрендә дә кәгазь белән китап бик күп иде. «Бу боларның барысын да ничек укып чыга алды микән?» – дип чиксез аптырый идем.

Балаларын бик яратты ул. Алар белән тәмам мәш килә иде. Безнең өйдә аны ихтирам белән искә алалар. Зур кеше булып та кече күңелле булып кала ала белгәнгә...

ШӨКЕР ИТЕП ЯШИ БЕЛДЕЛӘР

Рафик Сәләхиев, Фатих Хөснинең туганы:

– «Акча ул – таш астында, ә таш аждаһа башы астында» – дияргә ярата торган булган Фатих ага. Әти бик еш искә ала иде аның бу сүзләрен. Акчаны хәләл көчең белән тир түгеп эшләп алырга кирәк, ул җиңел килми, дип әйтүе булгандыр, күрәсең, Фатих аганың. Үзе ул аны гомере буена өстәл артында утырып, кәгазь каршына бөгелеп эшләде. Ахыр чиктә, сукырайды. Алар бит тормышның акчасыз чагын да, ачлыгын да, сугыш михнәтен дә күргән кешеләр. Шуңа да булганына шөкер итеп яши белделәр. Күпме авырлык күрсәләр дә, шаянлыгын, күтәренке рухын, көрлеген җуймаган әнә, Фатих ага. Бик шаян кеше булган дип сөйлиләр. Кызганыч, мин аны әтиләр сөйләгән буенча гына беләм инде. Аның әсәрләренә прототип булган геройлар да исән калмады хәзер. Гомер уза бит, бер урында тукталып тормый. Т

PRESSA.RU

БӨЕК БОЛГАР ҺӘМ ХӘЗӘР ДӘҮЛӘТЕ ИДАРӘЧЕЛӘРЕ

«ТАТАРСТАН» МАХСУС ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН

Азов–Кара диңгез буе далаларында 630 нчы еллар тирәсендә барлыкка килгән Бөек Болгар дәүләтенең гомере бик кыска була, шушы дәүләтне оештыручы Кубрат хан вафатыннан соң, 960 нчы елларда ул таркала. Көнчыгыш Европа халыкларының язмышында VII гасыр урталарыннан башлап X гасыр ахырларына кадәр – 350 ел чамасы! – яшәгән Төрки каганлыгы зур роль уйный. Ни кызганыч, безнең татар тарихы белән турыдан-туры бәйләнгән шушы ике дәүләтнең дә тарихы бик начар өйрәнелгән. Язма чыганаклардагы мәгълүматлар тулы түгел. Аларның хакимнәрен дә юньләп белмибез хәтта. Без белгәннәр түбәндәгеләрдән гыйбарәт.



Автор:
Фаяз Хуҗин

КУБРАТ – БОЛГАРЛАР ЮЛБАШЧЫСЫ

Әлеге шәхес тарихи чыганакларда, Болгар дәүләтенең хакиме буларак, беренче мәртәбә 630 нчы еллар башында (төгәлрәк 632 ел дип әйтүче галимнәр дә бар) булып үткән вакыйгалар белән бәйле рәвештә телгә алына. Кубрат – болгарлар юлбашчысы, рәсми титулы билгеле түгел. Болгариядә аны «хан» дип атау гадәткә кергән. Бөек Болгар дәүләтен «каганлык» дип йөртмәгәч, аның хакимен (идарәчесен) дә «каган» дип атау дөрес булмас иде, әлбәттә. Шуңа күрә, Кубратны гади халык арасында киң таралган «хан» дәрәҗәсенә күтәрү, минемчә, чынбарлыкка хилафлык китермәс кебек.

Хәтерегездә булса (журналыбызның узган елгы 2 нче санын карагыз), Азов буе болгарлары һәм Түбән Идел, Каспий буе далаларында күчмә тормыш алып барган башка халыклар 558 елда Истәми каган гаскәрләре тарафыннан җиңеләләр. Нәтиҗәдә алар Төрки каганлыгы составына кушылалар. 630 нчы елларга кадәр Кубрат төркиләр буйсынуындагы бер төбәкнең (бәклекнең) идарәчесе булгандыр, дип фаразларга нигез бар. Төрки каганлыгы, зәгыйфьләнеп, таркалу чорына килеп кергәч, Кубрат үз сәясәтен үткәрә башлый, мөстәкыйльлеккә омтыла. Дала халыклары арасында гегемонлыкка дәгъва кылган аварларга каршы сугышлар алып бара.

Әмма Кубрат – төрки-огурларның атаклы Дуло ыруыннан чыккан Орхан/Органа исемле хакимнең бертуган агасының улы – әлеге вакыйгалардан күпкә элегрәк Византия сәясәтчеләре арасында билгеле шәхес була. Язма чыганакларда сакланган мәгълүматларга караганда, Орхан агасы аны әле яшүсмер

Фотолар автордан алынды

Кубрат хан йөзеге.

чагында ук Византия императоры Ираклий сараена тәрбиягә бирә. Биредә ул рум телендә сөйләшергә һәм укырга-язарга өйрәнә, сәясәт, дипломатия серләренә төшенә. Соңрак ул Ираклий белән хәрби союзга керә, Византия чикләренә һәрдаим янап, яу чабып торучы аварларга каршы юнәлтелгән килешү төзи. Һәм бу килешү шартларын тормышка ашыруда сизелерлек нәтиҗәләргә дә ирешә. Һәрхәлдә, Кубратның император Ираклий кулыннан чит кавемнәргә сирәк бирелә торган патрикий титулы алуы һич тә очраклы хәл түгел, бәлки аның Византия алдындагы казанышларын күз алдында тотып эшләнгән гамәлдер.

Кубратның христиан динен кабул итүе – ә бу факт безнең тарихчылар арасында һичбер шик тудырмый һәм ул мәктәп дәреслекләренә дә кертелгән – аның Византия императоры сараенда тәрбияләнүе нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Әйе, бер карасаң, мантыйкка да каршы килми бу. Болгарларда һәм башка төрки халыкларда дини толерантлык хөкем сөргән тәңречелек киң таралган булса да, арада будда һәм зараостризм тарафдарлары да, несториан-христианнар да очрап торган. Шулай булгач, Кубратның христиан динендә булуын гайре табигый хәл дип кабул итмәскә кирәк, минемчә. Ләкин...

КУБРАТ ХАН ВАСЫЯТЕ

Ләкин шикләнергә дә урын бар. Ни өчен дисәгез, Кубрат ханның христиан динен кабул итүе турындагы хәбәр VII гасыр ахыры – VIII гасыр башында Александриядә (Мисыр) яшәгән Иоанн Никиусский (Никиуслы) исемле чиркәү әһеле калдырган язмаларда гына телгә алына. Әлеге документ латинча түгел, ә борынгы эфиоп телендә язылган һәм, белгечләрнең әйтүенчә, анда авыр аңлашыла торган сүзләр күп. Безне кызыксындырган әлеге хәбәр – ә ул төрле имеш-мимешләргә таянып язылганга охшый, диләр галимнәр – башка чыганаклар белән расланмый. Алай гына да түгел. Иоанн Никиусский язмаларында христиан динен кабул иткән «варварлар юлбашчысының» исеме «Кубрат/Куврат» түгел, ә «Кетрадес» дип бирелгән. Кетрадесның Кубрат булу мөмкинлеге бары тик фаразлана гына. Бу фаразны яңа, өстәмә дәлилләр белән раслау яки аны кире кагу өчен галимнәргә күп эшләргә кирәк әле.

Әлбәттә, Кубратның кайсы дингә өстенлек биргән булуы безнең өчен алай ук мөһим түгел. Иң мөһиме шул: Кубрат хан менә дигән сәясәтче һәм дипломат, дәүләт эшлеклесе, хәрби җитәкче булган. Болгарларның беренче тапкыр халыкара күләмдә танылуы Кубрат хан идарә иткән чорга туры килә. Кубратның вафатыннан соң, аның уллары үзләренә буйсынган халык белән төрлесе төрле якка таралып бетә. Алар хәтта Көнбатыш Европага, хәзерге Венгрия, Германия, Италия җирләренә килеп урнашалар. Кубрат хан оештырган Бөек Болгар дәүләте хәзерге болгарлар (Дунай болгарлары) һәм татарлар тарихы белән тыгыз бәйләнгән.

Шунысын да онытырга ярамый: болгарлар, аларга кадәрге һәм алардан соң яшәгән төрки кабиләләр (мәсәлән, кыпчаклар) украин халкының этник яктан формалашуына да билгеле дәрәҗәдә йогынты ясаганнар. Шулай булмаса, хәзерге Украина җирендә, Полтава өлкәсендә, Кубрат хан хәзинәсе табылган Малая Перещепина авылы янында беренче болгар ханына атап һәйкәл торгызып куярлар иде микән?

Һәйкәл дигәннән. Ә нигә безнең үзебездә, башкалабызда Кубрат ханга һәйкәл куймаска?! Ул һәйкәлне мин «Кубрат хан васыяте» дип атар идем. Хәтерлисездер: үләр алдыннан Кубрат, улларын чакырып, аларга дус һәм бердәм булырга куша, үзара ызгыш-талашлар чыгармыйча, дошманнар алдында тез чүкмичә, дәүләтне сакларга, исән-имин килеш киләчәк буыннар кулына тапшырырга васыять итә. Бу васыятьне скульптурада гәүдәләндерү бик актуаль бүгенге көндә.

ХӘЗӘР КАГАНЛЫГЫ ИДӘРӘЧЕЛӘРЕ

Алар турында бик аз беләбез. Аларның исемнәре генә билгеле, гамәлләре түгел. «Шул чордагы Европа халыклары караңгылыкта яшәгәндә күк йөзендә балкып киткән якты йолдыз кебек» (академик В. Григорьев сүзләре) өч гасырдан артык яшәгән дәүләт ич ул, югыйсә.

Хәзәр каганлыгы – Төрки каганлыгының дәвамчысы. Хәзәрләр элеккеге традицияләрне нык саклаганнар, дәүләт төзелеше ягыннан да, хуҗалыгы, мәдәнияте, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре һәм гореф-гадәтләре ягыннан карaганда да үзләренең элгәрләреннән аерылмаганнар. Хакимият башында каган/хакан торган. Аны элгәрерәк чорларда Тәңренең җирдәге илчесе

1. Болгар атлы сугышчысы. V – VII гасыр башы. М. В. Горелик реконструкциясе.

2. Бөек Болгарстан ханы – Кубрат. VII гасыр. М. В. Горелик реконструкциясе.

буларак кабул иткәннәр: барлык җирләр һәм шул җирдәге байлык – аныкы, халкы тулысынча аңа буйсынган, гаскәр – аның кулында, сугышны ул башлый, солыхны ул төзи. Уңышлы яулар нәтиҗәсендә кулга төшерелгән байлыкларны, мөмкин кадәр гадел булырга тырышып, каган булә. Кыскасы, ул чикләнмәгән хокукларга ия була.

Әмма бу хәл озак дәвам итмәгән. IX гасыр чыганакларында инде каган реаль хокукларга ия хаким рәвешендә түгел, бәлки ниндидер бер дәүләт символы, элеккеге хокукларыннан мәхрүм ителгән бер изге шәхес буларак кабул ителә. Элеккечә аны сайлап куялар (яисә ул «вазыйфа» нәселдән нәселгә күчә). Яңа сайланган каганны сарайга алып киләләр, муенына бау бәйлиләр һәм аны буа башлап сорыйлар: «Ничә ел идарә итәргә чамалыйсың?». Теге уйлаган арада муенын һаман да тыгызрак итеп кыса баралар, инде җаны чыга башлаганда гына мескен каган җавап бирә: «Фәлән ел утырырга телим тәхеттә». Ул әйткән ел дәвамында каган үлеп куя икән, бу – аның бәхете, үлми икән, аны бөтен йоласына туры китереп көчләп үтерәләр һәм, дәүләт күләмендә берничә көнлек траур ясап, күп кеше катнашында олылап күмеп куялар. Ибн-Фадлан язмаларында «изге корбан» итеп куелган каганның исәнлеген белдереп, өч-дүрт ай саен аны халыкка күрсәтеп торулары турында хәбәр бар.

Болгар шлемы. Керчь. VI гасыр.

Тәхеттә менә шундый символик каган утырган чорда дәүләт белән бәк идарә итә, каганның элеккеге вазыйфаларын тулысынча ул башкара.

БУЛАН КАГАН ҺӘМ ОБАДИЯ

Хәзәр дәүләтенең өч гасыр ярым дәвердә идарә иткән дистәләрчә хакимнәре арасыннан безгә билгеләре түбәндәгеләр: Булан, аннан соң Обадия, аннан Езекия, Манассия, Ханукка (Обадиянең туганы), Исаак (Хануккаҗның улы), аннан соң Завулон, тагын бер Манассия, Нисси, Манахем, Вениамин, Аарон, Иосиф – барлыгы 13 каган. Игътибар итегез – аларның барысы да яһүдләр токымыннан (Буланның гына исеме төрки – Болан).

Шул исемлектән өчесе безгә күбрәк билгеле. Кылган гамәлләре белән. Булан (Болан) һәм аның онығы Обадия VIII гасыр ахырында – IX гасыр урталарына кадәр идарә иткәннәр (төгәл еллары билгеле түгел). Тарихка дәүләт күләмендә яһүд динен кабул итүче буларак кереп калганнар.

Билгеле булганча, Булан каганга кадәр дәүләт дине булып ислам дине хезмәт иткән. Бу дин 737 елда, озакка сузылган гарәп-хәзәр сугышында Хәзәр дәүләтенең Мәрван җитәкчелегендәге гарәп гаскәрләре тарафыннан җиңелүе нәтиҗәсендә кабул ителә. Рус галимнәре бу фактка артык зур әһәмият бирмиләр. Имеш-

3. Хәзәр ханы Иосиф. М. В. Горелик реконструкциясе.



4. Хәзәр атлы сугышчысы. X – XII гасырлар.

тер, азсанлы югары катлау кешеләре генә бу динне тоткан, хәзәрләр үзләре, шул дәүләттә яшәүче башка халыклар, шул исәптән болгарлар да, элеккеге мәҗүсилекләреннән (тәңречелектән) аерылып җитмәгәннәр әле. Бу фикер белән тулысынча килешеп бетеп булмый. Чөнки, беренчедән, археология материаллары, икенчедән, язма чыганаклар башкача фикерләргә мәҗбүр итәләр. Хәзәр каганлыгы территориясендә 1970 нче еллардан башлап IX гасырга (бәлки элгәрерәк чорга да?) караган мөселман зиратлары казып өйрәнелгән. Ә инде Хәзәр дәүләтенең башкаласы Итилдә күпсанлы мөселман халкы, шул исәптән болгарларның да яшәве, аларның дистәләгән үз мәчетләре булуы турында укып-ишетеп белмәгән кеше сирәктер, минемчә.

Тагын бер кызыклы факт: Обадия каган яһүд динен гади халык арасында бик актив рәвештә тарата башлагач, болгарлар баш күтәрә, ризасызлык белдерә, һәм аларның бер өлеше Урта Иделгә, анда элгәрәк китеп төпләнгән ырудашлары-кабиләдәшләре янына күчеп китә. Бу факт язма чыганакларда сакланып калган.

Ә менә Хәзәр дәүләте халкының яһүд диненә күпләп күчүләре турында бернинди мәгълүмат юк. Әйе, югары катлау кешеләре кабул иткәннәр бу динне. Ләкин массакүләм рәвештә кабул итү булмаган. Бу хакта археология материаллары да ачык сөйли: бүгенгә кадәр яһүдләр йоласы белән күмелгән бер генә кабер дә ачылмаган әле. Шулай да «Хәзәр каганлыгы – яһүдләр дәүләте» дигән уйдырма тезис халыкара мәйданда бик актив таратыла хәзер.

ИОСИФ/ЙОСЫФ КАГАН

Ул – соңгы хәзәр каганнарыннан. Бәлки әле иң соңгысыдыр. Кайбер тарихчылар ул рус кенәзе Святослав явы вакытында, 965 (972?) елда үлгәндер, дип фаразлыйлар. Иосиф «патша» тарихка ничек кереп калган соң?

Ул 954–961 елларда Кордова (Испания) хәлифәсе Габдрахман II, дөресрәге, аның сарай чиновнигы яһүд Хасдай ибн-Шафрут белән Иосиф патша арасында хат алышу булып ала. Әлеге дә баягы яһүдкә Хорасан сәүдәгәрләре аркылы ерак Идел–Каспий буйларында урнашкан «яһүдләр иле» турында хәбәрләр килеп ирешә. Нинди ил ул? Нинди халыклар яши анда? Зурмы ул, кечкенәме? Шәһәрләре бармы? Иосифка җибәргән хатында Хасдай ибн Шафрут аннан шул сорауларга җавап бирүен үтенә. Йосифның Кордова хәлифәсенә җибәргән хаты ике нөсхәдә сакланып калган. Берсе, кыскача варианты, әле 1577 елда ук, икенчесе, киңәйтелгән варианты, 1877 елда табылган. Бу документлар тарихчылар өчен кыйммәтле чыганаклар булып тора. Биредә хәзәрләрнең төрки кабиләләрдән килеп чыгышы турында мәгълүмат бирелгән. Дәүләтнең чикләре дә күрсәтелә, әмма инде Иосиф биредә бераз алдаша, чикләрне киңәйтебрәк күрсәтә. Аңа буйсынган халыклар арасында славяннар (вятичлар, северяннар һ.б.лар), аланнар, буртаслар, болгарлар, суварлар, черемислар – барлыгы 13 халык – «аларның барысы да миңа буйсыналар һәм миңа салым түлиләр», дип санап кителгән.

Хәзәр дәүләтендә яшәгән халыклар арасында болгарлар белән аланнар күпчелекне тәшкил иткәннәр. Ни кызганыч, аларның безгә мәгълүм идарәчеләре арасында төрки кавемгә караганнары юк.

ЗУР ҖИР ШАРЫНЫҢ КЕЧКЕНӘ КЕШЕЛӘРЕ

Соңгы арада дин белән сәясәт, спорт белән сәясәт, сәнгать белән сәясәт арасында чикләр югалу гадәти хәлгә әйләнеп бара диярлек. Пхёнчханда узган быелгы Олимпиада заманча дөнья моделен формалаштыруда сәясәтнең сәясәт кенә булмавын аермачык күрсәткәндер, мөгаен. «Оскар» мәсьәләсенә килгәндә, киноакадемия корифейлары, әлбәттә, үзләрен сәясәттән ерак торучылар буларак тәгаенли. Әмма моңа карап кына дөнья киноиндустриясенең иң мәртәбәле премиясе сәяси, аннан да бигрәк конъюнктур булуыннан туктамый.

Автор:
Луиза Янсуар

Гадел һәм стереотиплардан азат икәнлекләрен беренче урынга куя «Оскар» комитеты вәкилләре. Бу Американың үзенә күрә курсы да түгелме икән әле. Тик бу гаделлек һәрчак нәрсәдер бәрабәренә булган гаделлек – шунысын да онытмыйк. Моны, мисал өчен, 2017 елда прокатка чыккан шактый үзенчәлекле картиналарның гомумән исемлектә урын алмавы анык күрсәтте. Ә 2017 ел безне яхшы кинолар белән шактый сөендерде бит югыйсә.

Сүз кычкырып торган арт-хаус, ягъни фестиваль фильмнары турында да бармый, ә нәкъ менә «Оскар»га ярашлы сыйфатлы уен фильмнары турында. Минем шәхси исемлегемдә, мәсәлән, Мартин Скорсезеның «Молчание»сы, Кеннет Лонерганның «Манчестер у моря»сы, Ильдико Эньединың «О теле и душе»сы, Йоргос Лантимосның «Убийство священного оленя»сы, Людвиг Шаммасянның «Отступник» картинасы һ.б. кайбер ленталар бар иде. Әмма «Голливуд конъюнктурасы»ннан кала тагын әле «Голливуд форматы» күп нәрсәне хәл итә.

Шулай да быел гаҗәпләндерделәр. 13 номинациядә тәкъдим ителеп, 4 номинациядә җиңү яулаган «Форма воды» фильмы да, «иң яхшы фильм» дип табылгач, күпләрдә ачыктан-ачык ризасызлык тудырды. Гәрчә Голливуд «бүгенге заманның иң талантлы визионерларыннан берсе» дип исәпләгән Гильермо дель Торо ел дәвамында фаворитлар исемлегендә булса да. Тик иреклe тәнкыйтьчеләрнең күбесе моннан шактый көчлерәк кандидатлар бар иде, дип лаф орды. Мөмкин булган, фараз ителгән җиңүчеләр рәтендә кискен социаль, «караңгы» «Прочь», яхшы сугыш драмасы форматында эшләнгән, Ноланның фирма стилен саклаган «Дюнкерк», Черчилль биографиясенә нигезләнгән һәм нәкъ голливудча төшерелгән «Тёмные времена» да исәпләнде. Дөрес, «Форма воды»ның сайлануы, аңлавыбызча, гайре табигый күренеш түгел, ә шактый көтелгән чишелеш. Чөнки быел Комитет карары буенча инклюзиягә кагылышлы, азчылыкны тәшкил итүчеләрнең проблемаларын чагылдыручы картиналарга аеруча басым ясалды. Һәм бу курс, чыннан да, «Оскар» номинантларын сайлауда ук күзгә ташланды. Әйтик, күпләр өчен Лука Гуаданьинонын «Зови меня своим именем» фильмының «Иң яхшы фильм» исемлегенә кертелүе көтелмәгән сюрприз булды. Көтелмәгән – чөнки бу асылда инди-фильм, ул Берлин, Канн, Венециядә премияләр «урып алса», аңлашылыр иде.

Быелгы номинантлар исемлеге жанр һәм тематика ягыннан шактый төрле күренсә дә, эчтәлек һәм сәнгати чишелеш ягыннан әллә ни мактанырлык түгел, минемчә. Әмма булганына шөкер итә белергә кирәк, дигәндәй... Әйдәгез, быелгы «Оскар»га лаек дип табылган фильмнарның кайберләренә тукталып узыйк. Болар минем шәхси фаворитларым, әлбәттә.

НОМИНАНТЛАР:

«Прочь»	«Форма воды»	«Дюнкерк»	«Тёмные времена»	«Леди Бёрд»	«Секретное досье»	«Призрачная нить»	«Три билборда на границе Эббинга, Миссури»	«Зови меня своим именем»



«МИН БИТ – МЕКСИКАЛЫ. МИҢА ЯРЫЙ!»

«Форма воды» 18+

Режиссёры: Гильермо дель Торо

Номинант иде: иң яхшы фильм, иң яхшы режиссёр (Гильермо дель Торо), иң яхшы саундтрек, иң яхшы куючы рәссам, иң яхшы хатын-кыз роле (Салли Хокинс), икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле (Ричард Дженкинс), икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле (Октавия Спенсер), иң яхшы сценарий, иң яхшы оператор эше, иң яхшы костюмнар, иң яхшы тавыш, иң яхшы монтаж, иң яхшы монтаж тавышы буларак.

«Оскар» алды: «Иң яхшы фильм», «Иң яхшы режиссёр», «Иң яхшы саундтрек», «Иң яхшы куючы рәссам» номинацияләрендә.

Сюжеты: Вакыйгалар 1962 елда АКШ һәм СССР арасындагы каршылык, салкын сугыш фонында бара. Элайза – Балтимордагы яшерен хәрби лабораториядә җыештыручы, ул бертөрле һәм күңелсез тормыш белән яшәүче «кечкенә кеше». Балачактагы травма нәтиҗәсендә саңгырау калган. Көннәрдән бер көнне лабораториягә яңа объект китерәләр – Көньяк Америка сулыкларында табылган амфибияне. Элайза белән «объект» арасында җылы мөнәсәбәтләр урнаша, һәм Элайза аны коткару идеясе белән яши башлый.

Иң югары ноктасына җиткән хайп фонында карадым мин аны. Фильмнан әллә ни тирән мәгънә эзләмәскә дә була. Була – эзләргә һәм... табарга да. Минем өчен яратканнарым исемлегендә иң беренчеләрдән түгел, әмма ихтирам йөзеннән, аңардан башларга кирәктер.

«Оскар»га кадәр үк «Форма воды» инде быелгы фаворитлардан санала иде: Венециянең «Алтын арыслан»ы, ике «Алтын глобус». Амфибия-хәшәрәт пәйда булган беренче кадрлар ук миндә – совет чоры китапларын укып, совет фильмнарын карап үскән балада – аермачык ассоциация уятты: «Человек-амфибия»нең америкача варианты. Шулхәтле америкача ки, ул хәтта стилистик яктан да Американың иң яраткан жанры – комиксны хәтерләтә. Күпмедер дәрәҗәдә «Амели», «Пена дней» кебек Европа эстетикасын сеңдергән, шулай да Американың «алтын чоры» тузаны белән өретелгән комиксны. Гильермо дель Торо Россия кино тәнкыйтьчесе Антон Долин белән интервьюсында «Человек-амфибия» фильмы белән таныш түгеллеген раслады. «Синекенә охшаш совет фильмы бар, диделәр миңа, әйе. Менә, карарга хыялланам хәзер, – диде ул. – Гаҗәеп хәл: ул фильм 1962 елда чыккан икән, минем картинам да 1962 елдагы вакыйгаларны сурәтли...»

Торо фильмын күпмедер дәрәҗәдә хоррор буларак та билгели: «Мин монстр турында әкият төшердем, гадәттә, хатын-кызны кочаклаган монстр кешеләрдә биологик дәрәҗәдә курку тудыра. Әмма мин тудырган монстр кешеләр ботарлаган һәм җансызга әверелдергән дөньядагы иң табигый, иң кешелекле образ». Монда ул үзенең тамырларыңын да зур роль уйнавын билгели. Фильмдагы хәшәрәтне кыргый халыклар (сүз Көньяк Америка индеецлары турында бара) Алла урынына күрә, дип кат-кат ассызыклана. Димәк, шул рәвешле режиссёр безгә нинди генә данлыклы, алдынгы чорлары булмасын, Америка асылда барыбер ерткыч колония булып кала бирә, дигән идеяне җиткерә. җәмгыятьнең кыерсытылган, чүпкә исәпләнгән «кечкенә вәкиле» – җыештыручы Элайза, гомосексуал Джайлс, кара тәнле Зельда турында гына бармый, ә яңа заман империясенең озын-озак елларга сузылган тулы бер сәясәте хакында да. Үз мин-минлегенә мөкиббән, башка төрле хакыйкатьнең булуы мөмкин түгеллегенә җаны-тәне белән инанган Стрикленд, димәк ки, Америкаsuccessfully чагылдыра, дия алабыз.

Менә шушы фонда Америка кино тәнкыйтьчеләренең «Форма воды»га өстенлек бирүләре – уйландыра. Һәм – хөрмәт уята. Чынбарлык моделен шулкадәр бүгенгегә якын итеп күрсәтә алган Гильермо дель Торо – үзе дә. Хәер, бер әңгәмәсендә визионерыбыз болай дигән иде: «Мин бит – мексикалы. Миңа ярый!» Димәк, Американың иң популяр конфет кәгазенә төреп хәзер «артык уңайлы» булмаган хакыйкатьләрне дә җиткерергә мөмкин, дигән иллюзия туа күңелдә. Дөрес, төреп. Әмма шулай да... «Без чынлап та шушы ноктага килеп җиттекме», дигән сорау бөтерелде башта, караганда. Әллә бу конъюнктурага туры килгән иң баллы тәгам генә булдымы икән? Лентаның буеннан-буена «СССР тематикасы», кораллану артыннан куу кебек тарихи параллельләр китерелеп торды бит...

«XXI гасыр башында да мондый әкиятләргә Оскар биргәч инде...» – дип, җитди кабул итмәвен белдереп, тел шартлатты бер танышым, «Форма воды»ны карагач. «Ә бәлки, бүгенге дөнья чынлап та беркатлылыкка, әкияткә сусагандыр», – дип уйлап куйдым эчемнән генә. Шулайдыр. Моны раслаучы икенче бер фильм бар чөнки.

Кызыклы фактлар:

- «Хәшәрәт»нең кыяфәтен 9 ай дәвамында ясыйлар. Гильермо дель Торо әлеге фильмны карьерасындагы иң катлаулы картина дип исәпли.
- «Хәшәрәт» костюмын кияр өчен һәр съёмка алдыннан Даг Джонска кимендә 3 сәгать вакыт таләп ителә. Актёр әле мондый катлаулы рольдә төшкәнен хәтерләми.
- Баштарак фильмны аклы-каралы итеп төшерергә ниятлиләр, әмма студия бюджетны күтәрергә карар кылгач, режиссёр аны төсле итәргә була.

Быел Андрей Звягинцевның «Нелюбовь» картинасы чит телдә төшерелгән фильмнар арасында «Оскар»га тәкъдим ителгән иде. Әмма ул икенче мәртәбә номинантлар исемлегендә калды. 2015 елдагы «Левиафан»ы да алтын сынны яулый алмаган иде. Шулай да Звягинцев Америка киноакадемиясенең фавориты булып кала бирә һәм – Европа кино фестивальләренеке дә. «Нелюбовь» картинасы быел, Кристофер Ноланның «Дюнкерк» фильмы белән Дэмьен Шазеллның «Ла-Ла-Ленд»ын узып, француз кинопремиясе «Сезар»га лаек дип табылды. «Нелюбовь»ны Европа киноакадемиясе дә билгеләп узды, Канн фестивалендә ул махсус жюри призына ия дип табылды.

Моңарчы «Оскар» премиясенә лаек булган СССР һәм Россия нәфис фильмнары – «Война и мир» (режиссёры – Сергей Бондарчук, 1968), «Москва слезам не верит» (режиссёры – Владимир Меньшов, 1980), «Утомлённые солнцем» (режиссёры Никита Михалков, 1994).

PRESSA.RU

«МИН БУ ФИЛЬМДА ГОМЕРЕМ БУЕНА ТӨШӘР ИДЕМ...»

«Зови меня своим именем» 18+

Режиссёры: Лука Гуаданьино

Номинант иде: иң яхшы фильм, иң яхшы ир-ат роле (Тимоти Шаламэ), иң яхшы саундтрек (The Mystery of Love, композиторы һәм башкаручысы – Суфьян Стивенс) буларак.

«Оскар» алды: «Иң яхшы адаптацияләнгән сценарий» номинациясендә (Джеймс Айвори).

Сюжеты: 1983 ел. Италия. 17 яшьлек Элио Перлман әтисе һәм әнисе белән җәйге виллада каникулын уздыра. Әтисе – Америка профессоры, әнисе – тәрҗемәче. Элио музыкаль әсәрләр яза, күп укый. Аның тыныч, салмак җәйге ялы әтисенең ассистенты, аспирант Оливер килеп төшү белән асты-өскә килә. Элио Оливерга гашыйк була һәм үзенең «барысы шикелле түгел» икәнлеген ваемлый. Бу кыска вакытлы җәйге роман һәр икесенең тормышын гомерлеккә үзгәртә.

Картинага Америкада, һәм дөнья күләмендә ни өчен шулкадәр зур кызыксыну булганын аңлату, бер яктан, җиңел – чөнки бу «тематик» лента. Режиссёры да үзенең ориентациясен яшермәүче гомосексуалист. Җитмәсә, «Зови»га ул бүгенге киноиндустриядәге иң затлы, ир-ат эталоны саналган актерларның берсе – Арми Хаммерны җәлеп иткән. Икенче фишкасы – Гуданьино моңарчы без әле исемен дә ишетеп белмәгән, шулай ук быелгы «Оскар»га тәкъдим ителгән «Леди Бёрд» фильмында төшеп, «ачылмыйча» калган «яңа йолдыз»ны кабызды. Тимоти Шаламэ Голливуд мохитендә зарыгып көтеп алынган, күптән сагынылган образларның берсе булган, күрәсең, аны хәзер Күккә генә чөймиләр.

Ярый, кызыксыну «тема»га бәйле булсын, ди. Ә ярату – нәрсәгә? «Зови»ны сорап-сорап күрсәттерәләр, кайда гына тәкъдим ителмәсен, Арми Хаммер белән Тимоти Шаламэ – кадерле кунак. Гуаданьино бу эффектка бераз гына ачыклык кертә: «Фильм минем өчен гаиләгә тиң». Моны Тимоти Шаламэ да асызыклый: «Зови меня своим именем»ны төшерү процессы азагына якынлашкан саен барыбыз да моңсуланды». Арми Хаммер гомумән: «Әгәр мөмкин булса, мин бу фильмда гомерем буена төшәр идем», – ди.

Әлеге ореол үзен аермачык сиздерә – ул фильмның геройларында үзенә бер энергетика буларак һаман да яши. Бәлки шуңа да «Зови меня своим именем» актерлары белән социаль челтәрләр, аккаунтлар шыплап тулган. Фильмны цитаталарга бүлеп, яттан диярлек сөйлиләр. Һәм, әйтергә кирәк, ЛГБТ вәкилләре түгел, ә темадан бөтенләй ерак торучылар. Һөнәре, кызыклаулар һәм кызыксынулар спектры гаять төрле булган кешеләрне сайлап, шәхси сораштыру уздырып карадым: нәрсәсе белән җәлеп итә сезне «Зови меня своим именем» фильмы? 80% респондент «ихласлыгы», «тормышта бик сирәк очрый торган самими яратуны сурәтләве», «әле дөнья кере сеңеп өлгермәгән икәүне иң матур чакларында гәүдәләндерүе» кебек җаваплар арасыннан иң еш кабатланганы «барыбыз да гарык булган цинизмнан азат булуы белән» булды. Димәк, бүгенге югары технологияләр, тизлекләр, уңайлыклар заманында кешеләргә ИХЛАСЛЫК һәм ЯРАТУ җитми. Югыйсә, секунд эчендә смсың дөньяның икенче почмагына барып җитә ала – яз гына, бул гына эчкерсез-ихлас! Әмма юк, психологлар яшьләрдәге мондый үзенчәлеккә басым ясый: җан сызланулары кичермәс өчен, яңа буын вәкилләре, бәлки, мәхәббәттән бөтенләй ваз кичәрләр, ди. Тикшеренүләргә ышансак, яңа буын «мәхәббәт» белән «секс» төшенчәләрен бер-берсенә бәйләми, табигый җенси омтылышларны канәгатьләндерү организм өчен файдалы дип саный, әмма ул рухи тетрәнүләр бәрабәренә тормый, дип таба.

Минем өчен «Зови меня своим именем» конъюктурадан бөтенләй ерак торган, чын мәгънәсендә югары сәнгать әсәре таләпләренә җавап биргән шәхси «Оскар»ым иясе. Юкка гына аны «фильм түгел, ә поэзия» дип атамыйлар.

Фильмдагы кульминация: Элионың әтисе белән диалогы. *«В самый неожиданный момент Природа умело находит наше самое уязвимое место и наносит удар... и только сердце с телом знают... Сердце и тело нам даются только один раз»*. Лука Гуаданьино картинасы, «Форма воды» кебек үк, үткәнне – 80нче елларны чагылдыра, әмма перспективада ул безне Греция, эллиннар чорына ук алып китә. Бүген шоуга әверелгән гей-парадлар турында әле сүз дә була алмый. «Тема»ның мейнстрим түгел, ә «идән астында» яшәгән еллары. Һәм менә шул чорда ата белән ул, җәмгыять тарафыннан кабул ителмәсә дә, мәхәббәтеңне сайларга кирәклеге турында сөйләшә. «Син һәрчак безнең гаилә әгъзасы булачаксың», – диләр алар Оливерга да. Яратуның абсолют, чикләүләрсез була алуын чагылдырган әлеге мөнәсәбәт күтәрелгән теманың бүген тагын да актуальрәк икәнлегенә ишарә итә. «Мин сине фәлән-фәлән өчен яратам, улым», – дими бу атаана. «Син – безнең улыбыз, шуңа күрә без синең барлык карарларыңны да кабул итәргә әзербез», – диләр. Картаюга һәм үлемгә таба барган өлкән буынның яшьләргә васыяте кебегрәк тә кабул ителә сүзләре: яратыгыз, авыртсын йөрәгегез, әмма гомерегез буена бары тик шул хис кенә сезне кеше итеп саклаячак.

Сюжеты буенча камералы тоелса да, асылда шартлаткыч эффектка ия җитди ишарә ята «Зови меня своим именем» картинасы нигезендә: тигезлекнең искәрмә түгел, ә норма булуына ишарә. Режиссёр бу мәхәббәтнең, башка миллионнарча мәхәббәтләр кебек үк, тигез хокуклы булуын күрсәтә. Ә аннан да бигрәк – геройларының, иң беренче чиратта, кеше булуын. Бу кычкырып торган «Смерть Сталина» картинасыннан күпкә көчлерәк энергетик төен, тирәнрәк итеп уйлана калсаң.

Кызыклы фактлар:

- Фильмның сюжеты Андре Асиманның 2007 елда дөнья күргән «Позови меня своим именем» романына нигезләнгән. Гуаданьино киләчәктә фильмның сиквелын төшерергә ниятләве турында белдерде.
- Сценарий авторы – 89 яшьлек Джеймс Айвори «Оскар» церемониясенә герое Элионы уйнаучы Тимоти Шаламэ сурәте төшкән күлмәктән килде, аннан ул күлмәкне яшь актерга бүләк итте.
- Фильмның премьерасында карачылар аны 10 минут дәвамында аягүрә торып алкышлады – мондый хәлнең Нью-Йорк кинофестивалендә әле булганы юк иде.

БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БЕР АРБАДА

«Три билборда на границе Эббинга, Миссури» 18+

Режиссёры: Мартин МакДона

Номинант иде: иң яхшы хатын-кыз роле (Фрэнсис МакДорманд), икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле (Сэм Рокуэлл), иң яхшы фильм, икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле (Вуди Харрельсен), иң яхшы сценарий, иң яхшы монтаж, иң яхшы саундтрек буларак.

«Оскар» алды: «Иң яхшы хатын-кыз роле (Фрэнсис МакДорманд)», «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» (Сэм Рокуэл).

Сюжеты: Кызы үтерелгәннән соң берничә ай узгач, җинаятьчеләр табылмау өчен кайнаган ачуына һәм кайгысына чыдый алмаган Милдред Хейс, шәһәр читендәге 3 билбордны арендалый. Аларда ул полиция башлыгы Уильям Уиллоубига карата ачыктан-ачык кискен мөнәсәбәтен белдереп язулар урнаштыра. Әнә шул мизгелдән кечкенә генә Эббинг шәһәрчеге кыл икегә бүленә: соңгы стадиядәге рак белән җәфаланучы, әмма полициядәге эшен ташламаучы Уиллоуби һәм асылда кызының үлемендә үзен гаепле дип исәпләүче, шуңа да җанынан тынгы таба алмаучы Милдред яклыларга.

Картинаны Венеция кинофестивалендә «иң яхшы сценарий» өчен бүләкләгәннәр иде, Сан-Себастьянда ул караучыларның симпатиясе өчен приз яулады. Рейтингы буенча «Три билборда» Россия кино прокатындагы иң популяр фильмнарның берсе. Аны хәтта, ярым шаяртып, «америкача Звягинцев» дип тә атадылар.

Әллә Россия кино һәм театр сәнгатен соңгы берничә дистә елда басып алган «чернуха»дан арыганга, әллә мондый төр социаль картиналарның психологик нигезе аксаудан ялыкканга, «Билборд»тан әллә ни көтмәдем. Әмма фильм кире уйларга мәҗбүр итте. Натуралистик шәрәлегеннән бигрәк, шул фонда шактый нечкә эшләнгән психологиясе белән җәлеп итте: ситуация даими кара комедия һәм драма, урыны-урыны белән хәтта ки фаҗига чигендә тора.

Моңарчы Фрэнсис МакДорманд Элизабет Страутның «Оливия Киттеридж» әсәре буенча төшерелгән «Что знает Оливия» мини-сериалында Милдредка шактый охшаш героиняны уйнаган иде. «Билборд»тагыча, анда да берничә сюжет линиясе Оливия язмышы белән тоташып, тетрәнгеч новеллаларны хасил итә. Анда да – шкафтагы скелетлар, җайсыз кешеләр, көнкүреш драмасы һәм ерткычлык белән янәшә яшәүче иң югары кешелеклелек кыйммәтләре, кече күңеллелек. Оливия/Милдред типажы – нәкъ Фрэнсис МакДормандныкы, соңгы еллардагы амплуасы, дисәк, ялгышмабыз. Фильмны ахырынача «тотып» тора аның героинясы. Харрельсен һәм Рокуэлл белән ансамбльдә дә ул – төп нерв җепселе.

Фильмда – өч билборд һәм төп өч персонаж язмышы. «Без барыбыз да олы бер Җир шарының кечкенә кешеләре» – аның төп идеясен шулай билгеләргә буладыр. Ә «Без барыбыз да – бер арбада, ул котылгысыз рәвештә упкынга тәгәри һәм моннан берәү дә имин котылмаячак» дигәне, бәлки, төп мотивтыр. Бер кешенең кайгысы икенче кешегә кагылмый, дип уйлау – иң җиңел ысул. Фильмның башыннан азагынча Фрэнсис МакДорманд героинясы моның алай түгеллеген һәм җимергеч ысуллар, һәм юмор, һәм үзенә генә хас миһербанлык аша дәлилли. «Арба»дагы геройларның һәрберсенең үз драмасы, фаҗигасе, алар асылда – бер-берсенең көзгесе. Берсенең авырткан урынына китереп бассаң, икенчесендә дә ул чагылмый калмый. МакДона һәм сценарист, һәм режиссёр буларак моны аяусыз, абсурд чигендә торган элементлар аша күрсәтә.

«Три билборда» фильмында диалоглар зур әһәмияткә ия, элеккеге драматург тарафыннан эшләнүләре аермачык сизелә. «Милдред ролен махсус Фрэнсис МакДорманд өчен яздым, – ди режиссёр. – Нәкъ менә ул торды күз алдымда: йөзе, мимикасы, куәтле, экранны биләп алырга сәләтле энергетикасы. Әгәр ул риза булмаса, кемне сайларга икәнен уйламадым да, юк андый актер минем өчен».

«Три билборда на границе Эббинга, Миссури» фильмын карарга уйласагыз, «афәрин!» Әмма попкорн чәйни-чәйни түгел, зинһар! Чөнки тамакка утырган төердән кайчак үз тирә-юньеңне дә йота алмый торасың.

Кызыклы фактлар:

- Төньяк Каролинадагы кечкенә генә Сильве шәһәрчегендә төшерәләр фильмны. Съёмкалар арасында Вуди Харрельсен җирле халыкка автографлар өләшү белән шөгыльләнә, алар белән фотога төшә. Берсендә хәтта гитарада уйнап «концерт» та оештыра.
- Фрэнсис МакДорманд башта фильмнан баш тарта. Әмма ире аны кире уйларга мәҗбүр итә: «Авызыңны яп та, уйна бу рольне», – ди.
- Мартин МакДонаны сценарий язарга «Джорджиа, Флорида яки Алабама арасында» урнашкан ачылмаган җинаять турында хәбәр итүче реаль билбордлар этәрә.

2017 елның

иң яхшы фильмнары исемлегенә кергән дә/кермәгән дә әлеге фильмнарны һичшиксез карарга тәкъдим итәм:

- **«Молчание»,** Мартин Скорсезе
- **«Нелюбовь»,** Андрей Звягинцев
- **«Прочь»,** Джордан Пил
- **«Призрачная нить»,** Пол Томас Андерсон
- **«Секретное досье»,** Стивен Спилберг
- **«Хэппи-энд»,** Михаэль Ханеке
- **«Последний портрет»,** Стэнли Туччи
- **«Патерсон»,** Джим Джармуш
- **«Манчестер у моря»,** Кеннет Лонерган
- **«Дюнкерек»,** Кристофер Нолан
- **«Бегущий по лезвию»,** Дени Вильнев
- **«Ла-Ла-Ленд»,** Дэмьен Шазелл
- **«Тоня против всех»,** Крэйг Гиллеспи
- **«Леди Бёрд»,** Грета Гервиг
- **«мама!»,** Даррен Аронофски
- **«Квадрат»,** Рубен Эстлунд
- **«Сплит»,** М.Найт Шьямалан
- **«Темные времена»,** Джо Райт
- **«Послушница»,** Маргарет Беттс
- **«Отступник»,** Людвиг Шаммасян
- **«Роман Израэл, Esq.»,** Дэн Гилрой
- **Ферма «Мадбаунд»,** Ди Риис
- **«О теле и душе»,** Ильдико Эньеди
- **«Сначала они убили моего отца»,** Анджелина Джоли
- **«Хижина»,** Стюарт Хэзелдайн
- **«Убийство священного оленя»,** Йоргос Лантимос

PRESSA.RU

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+

ЮТАЗЫ РАЙОНЫ



PRESSA.RU

КӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШНЫҢ ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЛӘРЕ

Татарстанның Ютазы районы административ үзәгенә, Урыссу бистәсенә, узган ел 70 яшь тулды. Әмма, бик күп заманча яшь шәһәрләр кебек, ул елдан-ел яшәрә генә бара. Аның белән бергә бөтен район да... Район башлыгы Рөстәм Нуриев безгә Ютазының өр-яңа тарихында иң күренекле булган яисә менә-менә шундыйга әвереләчәк урыннарны күрсәтте.

КАЙТЫРЛАР ДИГӘН ЫШАНЫЧ БАР

Экскурсиябезнең беренче объекты – быел адресын үзгәрткән Урыссу гимназиясе булды. Аның җете төсләр белән балкып утырган яңа бинасы әйләнә-тирәдәге табигатькә шулкадәр туры килеп тора: биек калкулыклар, зәп-зәңгәр күк, янәшәсендә – яшь микрорайонның якты йортлары.

– Берничә ел буе без республика мәгариф министрлыгына гимназиябез өчен 400 урынлы яңа бина кирәклеген исбатларга тырыштык. 2015 елда, ниһаять, төзелешкә рөхсәт бирелде. Бу вакытка инде җентекле проект әзерләнгән иде. Барысын да бик тиз эшләп чыгу насыйп булды. Бу елның февралендә укучылар һәм укытучылар яңа бинага күчүне бәйрәм иттеләр, – дип сөйли Рөстәм Нуриев.

Гимназия мәгариф стандартларының соңгы сүзенә туры килерлек итеп җиһазландырылган. Дәресләр челтәрен чагылдырган электрон мониторлар, ике телдәге күрсәткечләр, интерактив такталар, табигый-фәнни предметлар буенча лаборатор эшләр

Фото: Александр Ефремов

өчен өр-яңа җайланма-әсбаплар, видиоэлемтә функциясе булган аерым конференц-зал, хәтта беренче класс укучысы буендагы шахматларга кадәр бар... Бүгенге көндә 260 бала укыган гимназия белем бирүнең өзеклексезлек системасы буенча эшли – озакламый биргә янәшәдә генә урнашкан, шулай ук яңа, 7 нче балалар бакчасыннан әзерлек төркеме балалары киләчәк.

– Балаларга, 10 нчы класстан башлап, һөнәр юнәлешен сайлау мөмкинлеге бирү күздә тотыла – социаль-гуманитар, физика-математика, аграр яисә универсаль профильләр. Бу эштә без укучыларның да, перспективалы яшь кадрларга мохтаҗ булган предприятиеләрнең ихтыяҗларын бертигез дәрәҗәдә күз уңында тотабыз, – дип сөйли Рөстәм Нуриев. – Соңгы елларда БДИ буенча яхшы нәтиҗәләргә ирештек. Өлкән класс укучылары бик актив. Район балалар думасы эшли. Аларның проектлары күп, без даими рәвештә очрашып торабыз, мөһим мәсьәләләрне тикшерәбез. Ә инде китүгә йөз тоткан яшьләр өчен «Кайда тудың, шунда кирәкле бул» дигән үз программабызны булдырдык. Муниципалитет стипендия түли яки, әгәр бу бюджет бүлеге булмаса, укыту бәясенең яртысын үз өстенә ала. Аннан соң яшьләр, үзебезгә кайтып, 5 ел эшли. Шул рәвешле без берничә медицина хезмәткәрен укытып чыгардык, хәзер гимназия һәм булачак ресурс үзәге өчен укытучылар әзерлибез.

Урыссу гимназиясенең 11 сыйныф укучысы, Ютазының Район балалар думасы спикеры Полина Никитина (уңнан – өченче) ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда.

«КОЯШЛЫ» ЯКТА

Гимназиядән ерак та түгел – булачак Яшьләр паркы. Әлегә анда шартлы тамгалар гына билгеләнгән, әмма парк та, гимназия дә озакламый яңа «Кояшлы» микрорайонының үзәгенә әвереләчәк.

Республика президент программалары башланганнан бирле район аларда катнаша һәм, әйтергә кирәк, елдан-ел активрак, күп кенә проектларны – башлап җибәрүче ул. Урыссуга алга таба кайсы юнәлештә үсү мәсьәләсе килеп тугач, шушы территория сайланган. Башта ул бистәнең чите генә булган, ә хәзер инде – мантыйкка ярашлы, якты дәвамы булып тора. 2011 елда биредә Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен беренче шәхси йортлар төзелә.

Хәзер «Кояшлы» 600 дән артык җир биләмәсенә бүлгәләнгән.

PRESSA.RU

359ында шәхси төзелеш алып барыла яисә инде тәгәлләнгән, күпфатирлы дүрт йорт төзелгән. Биредә күбесенчә яшь гаиләләр яши, шул исәптән, шәхси торак төзелеше өчен республика программасы буенча җир алган күп балалы гаиләләр дә.

– Гимназия өчен шуңа күрә көрәштек тә инде. Хәзер бу микрорайонда 800 гә якын кеше яши. Якын арада биредә тагын күпфатирлы дүрт йорт төзеләчәк. Халык саны артачак. Биредә яшәүче балалар яхшы мәктәпкә йөрергә, анда исә бөтен балага да урын җитәргә тиеш. 80 урынлы балалар бакчасы бар инде. «Кояшлы» – бер карасаң, районлдагы бөтен яңалыкның символы ул. Биредә мәдәният йорты салырга һәм анда ЗАГС бүлеген дә урнаштырырга уйлыйбыз. Ул чакта инде микрорайон бөтен «гаилә инфраструктурасы» белән тәэмин ителгән булачак, – дип елмая башлык.

СӘНГАТЬ ҺӘМ ТОРМЫШ МӘЙДАНЫ

Алдагы тукталышыбыз – Балалар сәнгать мәктәбе һәм... бала тудыру йорты арасындагы зур булмаган мәйданга туры килә.

– Элек бала тудыру йорты хәзер мәктәп булган бинада урнашкан иде. Без аны район хастаханәсе базасына, күрше бинага күчерергә булдык. Ә аның бинасына капиталь ремонт ясадык. Моның өчен муниципаль бюджеттан 12 миллион сумга якын акча бүлеп бирдек, – дип сөйли Рөстәм Мидхәтович. Сәнгать мәктәбе дә, бала тудыру йорты да, ул күзаллаганча, бердәм архитектура ансамбле булып күренә. – Кешедә

барысы да матур, гармонияле булырга тиеш. Мөмкинлеге бар икән, аның барлык сәләтләрен үстерергә кирәк. Шуңа күрә дә без бу мәктәпне – ә аңа инде 70 яшь диярлек – барлык кирәкле мәйданнар һәм матди-техник база белән тәэмин итү өчен беренче мөмкинлектән үк файдаландык. Балалар тиешле дәрәҗәдә шөгыльләнә алсын, – дип сөйли Рөстәм Мидхәтович.

Фортепиано, фольклор, сәнгать бүлекләре, халык, тынлы һәм кыллы-смычоклы инструментлар бүлекләре – һәр шәһәр мәктәбе дә мондый мөмкинлекләре белән мактана алмый. Ә Урыссу мәктәбе – ала.

Район башлыгы тынлы оркестр белән булган вакыйганы искә төшерә. Бернечә ел элек, җирле ветераннар белән традицион очрашуда өлкән яшьтәге бер кунак: «Менә элек бездә танылган тынлы оркестр бар иде. Татарстанның бөтен көньяк-көнчыгышында данлыклы! Кайда ул хәзер?» – дигән сорауны биргән.

– Дөресен генә әйткәндә, мин беркадәр каушап калдым. Минем бит оркестр турында ишеткәнем дә юк иде, ә монда мин аны таратуда гаепләнгән кебек килеп чыкты… Аннары мин кызыксынып киттем. Белгән кешеләрне чакырдык, – ди Рөстәм Нуриев. – Байтак музыкантлар әлегәчә бистәдә яки күрше-тирәдә генә яши икән. Оркестрны кабат торгызырга булдык. Бөтен инструментларны диярлек сатып алдык. Һәм Ютазы районының 25 еллыгы тантанасында алар яңартылган составта уйнады! Шулай итеп, безнең хәзер үз музыкаль брендыбыз да бар…



ТАБИБЛАР... СМС БУЕНЧА КИСӘТӘ

Юлыбызда очраган һәр бина турында диярлек Рөстәм Мидхәтович: «эшләнде» яисә «эшләнәчәк» дип белдереп бара. Аның беренче инфраструктур проекты (Рөстәм Нуриев районга 2010 елда җитәкчелек итә башлаган) районның барлык социаль объектларының җылыту системаларына һәм түбәләренә ремонт ясау булган. Хәзер мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына капиталь ремонт тәгәлләнеп килә (районда 14 мәктәп һәм 19 балалар бакчасы бар). Республика программасы буенча финанслаудан тыш, муниципалитет акчалары да файдаланыла – алар шактый тузган эчке коммуникацияләрне ремонтлау һәм программага кермәгән башка ихтыяҗлар өчен тотыла.

Үзәк район хастаханәсе янында Рөстәм Нуриев Ютазы предприятиеләре хезмәткәрләре өчен скрининг программасы турында сөйли. Программа Ютазы үзәк хастаханәсе һәм җирле программистларның өр-яңа табышы (ягъни ноу-хау). Аның мәгънәсе шунда: хезмәткәрләр даими рәвештә профилактик күзәтү үтә. Аның нәтиҗәләре базага кертелә. Шулар нигезендә сәламәтлекләре куркыныч астында булган хезмәткәрләр категориясе ачыклана. Бүгенге көндә предприятиеләр һәм бюджет учреждениеләренең медиклары үз эченә 6 мең кешене сыйдырган әлеге базага керү мөмкинлегенә ия.

– Ягъни кеше эш урынындагы медкабинетка берәр зары белән килсә, табиб әлеге базадан аның хәлен динамикада карый ала. Моннан тыш, куркынычлылык төркемендәге хезмәткәр анализлар тапшырыр алдыннан яхшы гына ял иткән яки бәйрәм ясаган булса, аның телефонына смс килә: әйтик, кан басымыгыз югары – алкогольдән ерак торырга кирәк, дип… Аннары ике көн – ипи белән су инде… – дип елмая Рөстәм Мидхәтович. – Ә бит,

PRESSA.RU

житдирәк сүз йөрткәндә, программаның ике ел эшләү дәверендә хезмәткәрләр арасында йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан үлү очраклары ике тапкыр кимеде!

Күптән түгел Ютазы белгечләре республиканың ике дистәгә якын районыннан җыелган медикларны әлеге скрининг программасы белән таныштырганнар. Аның белән күрше Башкортостанда да кызыксына башлаганнар. Ә хезмәт коллективларына даими диспансеризация үткәрү темасын күптән түгел Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та күтәрде.

«КАЙНАР» СОРАУ

Без үзәк урамнан, ягъни районның чирек гасырлык юбилее уңаеннан тулысынча реставрацияләнгән Урыссу урамыннан борылып китәбез. Тротуарлар аерым телгә алынырга лаеклы: байтак урамнарда алар үзара салым пргграммасы буенча җыелган акчаларга ясалган.

– Программага старт 2015 елда бирелде. Дөресен генә әйткәндә, Урыссуда аны зур дәрт белән күтәреп алмадылар. Акчалар бистәне яхшыртуга тотыла һәм өч ел эчендә нәтиҗәләр күренә башлады. Кешеләр хәзер программада бөтенләй башка кәеф белән катнаша, – дип сөйли район башлыгы.

Сүз кәефкә кагылгач, индивидуаль җылытуга күчү белән эшләрнең ничек торуы турында кызыксынам.

– 2016 елда Урыссу ГРЭСы тулысынча ябылды. 3,5 меңгә якын фатирны һәм 23 социаль объектны җылылык белән тәэмин итү туктатылды. Бер фатирны казан белән җиһазлау 100 мең сум тирәсе тора иде. Җиһазлар лизинг килешүе белән республика Газлаштыру фондыннан 7 ел дәвамында түләү графигы белән тапшырыла. Инвалидларга, хезмәт ветераннарына, күп балалы гаиләләргә – ташламалар белән. Процесс катлаулы, озын иде, ләкин гомуми тырышлык белән бу юл үтелде. Сүз уңаеннан, ябылган ГРЭСның 260 ка якын хезмәткәрен без эшкә урнаштырдык, – ди Рөстәм Нуриев.

ЗАЛДА ӘБИЛӘР ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Тормыш Урыссуда гына гөрләми. Бәйрәкә авылында «Батыр» спорт комплексына керәбез. Аны күп еллар элек «СоюзАгро» җирле авыл хуҗалыгы компаниясе төзи башлаган булган, аннары, 2012 елда Бәйрәкәгә килеп киткәннән соң, Президент Рөстәм Миңнеханов ярдәм иткән. Комплексны республика һәм бюджет акчаларына төзеп бетереп, өч ел элек ачканнар.

– Бераз гына соңардыгыз, иртәнге төркем – 60+ ка караган яшьтәге апаларыбыз аэробика белән шөгыльләнә бирәдә. Төштән соң гер күтәрүчеләр килә. Бездә Татарстан призёрлары булган кызлар да бар! – ди комплекс директоры Радик Мөхәммәтҗанов.

Кич белән «Батыр»га волейболчылар, гимнастлар, көрәш белән шөгыльләнүчеләр, шулай ук спорт тренажёрларында физик формаларын камилләштерергә яратучылар килә икән. Монда барлык кирәкле җиһазлар да, экипировка да бар.

– «Батыр» – республиканың көньяк-көнчыгышында авыл комплекслары арасында

иң яхшысы, – ди Рөстәм Мидхәтович. Сүз арасында ул җиңел генә 16 килолы герне күтәреп куя. Ә үзенең яраткан спорт төре – чаңгы шуу икәнен әйтергә дә онытмый.

«Батыр»ның гер күтәрүчеләре Урыссуның «Олимп» балалар спорт мәктәбенә йөрүчеләр белән ярыша. Күптән түгел бу көндәшлеккә Ютазы секциясе балалары да килеп кушылган.

– Анда безнең тулы мәдәни-спорт комплексы – мәдәният йорты белән спорт үзәге бер бинада урнашкан. Аңа капиталь ремонт ясау өчен бер ел элек муниципалитет 23 миллион сумга якын акча бүлеп бирде. Озакламый ачылышы була! – дип белдерә энтузиазм белән Рөстәм Мидхәтович.

АЛЫШТЫРУ ТҮГЕЛ, АЛМАШУ

Сәнгать һәм спорт сараен карарга Ютазыга китәбез. Тышкы яктан комплекс гадәти генә күренә. Эчкә кергәч, бу объектның ни өчен район һәм авыл җирлеге җитәкчелегендә горурлык уятуын аңлыйсың. Иркен холлдан спорт блогына да (яңа спортзал, чишенү, душ бүлмәләре), клубка да узып була. Анысы чып-чын затлы сарай диярсең: түгәрәкләр өчен күпсанлы якты бүлмәләр, ике китапханә һәм, ниһаять, шәһәр шартларында да шактый зур тоелырдай 380 урынлы зал. Стеналар махсус акустик панельләр белән капланган. Аларын Владимир шәһәреннән чакыртылган осталар монтажлаган…

– Без бирегә концертлар белән Татарстан, Башкортостан һәм Россиянең башка төбәкләреннән театр коллективлары һәм эстрада йолдызлары килер, дип өметләнәбез. Әмма яңа сәхнәдә иң беренче үзебезнеке – «Алыш-биреш, яки Синнән – фатир, миннән – ир» дигән тамаша уйналачак, – ди Рөстәм Мидхәтович.

Без залдан чыгабыз да, стеналары төсле мозаика белән бизәлеп, бәйрәм төсмере биреп торган фойега эләгәбез.

– Мозаиканы Мәдәният йорты төзелгәндә, 80 нче еллар уртасында ук эшләгән булганнар, – ди Рөстәм Мидхәтович. – Без, әлбәттә, аны саклап калырга тырыштык. Ә интерьерны аның матурлыгын тагын да ачыграк күрсәтерлек итеп планлаштырдык. Минемчә, шулай дөрес тә – яңаны төзегәндә, элеккенең дә иң яхшы якларын саклап калырга кирәк.

PRESSA.RU

ИРТӘГӘГӘ ИЛТҮЧЕ ЮЛЛАР

Урыссу бистәсендә 2,6 км озынлыктагы әйләнгеч юл төзелеше – «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» МУП өчен үзенә күрә дебют. Шундый әһәмиятле объектта барлык эшләрне – юл нигезен күтәртүдән алып, трассаны кулланышка тапшыруга кадәр – предприятие үз көче белән башкарачак.

Илшат Камалдинов, «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» МУП директоры

Фото: Александр Ефремов

УНИВЕРСАЛ МУП

Төзелештә эшкә җигелгән техника шаккатыра. Әле моннан дүрт ел элек кенә предприятиенең бөтен паркы өч МТЗ тракторыннан торганын, ә еллык эш күләме 5 миллион сумнан гыйбарәт икәнен белгәч – бигрәк тә. «Яшелләндерү-төзекләндерү» тармагындагы башка муниципаль оешмалардан аның әллә ни аермасы булмаган: 17 кеше урам җыештырган, чәчәк түтәлләре ясаган, газоннарны караган… Ләкин 2015 елда Ютазы хакимияте, Татарстанда беренче булып, районның 200 км га сузылган транспорт артериясен үз карамагына ала.

Моңа 2011 елдан ук әзерләнә башлыйлар, ул чакта яңа хакимият башлыгы Рөстәм Нуриев МУП базасында төзелеш тармагын үстерү турында карар кабул итә. Урамнарны яктыртуда акчаны янга калдырып, дүрт елда төрле техника сатып алалар. 2015 елның кышына инде өч «КАМАЗ», өч МТЗ тракторы, ике грейдер һәм бер йөк төягечкә ия булалар, ком һәм реагентлар хәстәрләнә. Хезмәткәрләр санын өчләтә арттырып, юл эшчеләрен туплыйлар һәм төзелеш эшләренә рөхсәт алалар.

«Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» МУП инде дүртенче ел «Татнефтедор» ҖЧҖ подрядчысы сыйфатында юллар челтәрен үстерү программасында хезмәт куя: асфальт сала, чокыр-чакырларны тигезләү яки юл өслеген тулысынча алыштыру кебек ремонт эшләрен башкара, юл читләрен ныгыта, юл билгеләре урнаштыра, ясалма тигезсезлекләр җәя, юл сызыклары төшерә.

Узган елда гына да «Татнефтедор» ҖЧҖ белән килешүләр нигезендә 92 миллион 186 мең сумлык эш башкарылган. Болар – төбәк автомобиль юлларына агымдагы ремонт, Урыссуда һәм районның башка торак пунктларында урам юлларын төзекләндерү, сигез ишегалды территориясен тәртипләндерү, бистәдәге керегә борылып китү урыннарын көйләү.

Моңа өстәмә итеп, урам юлларын ремонтлау программасы кысаларында, Ташкичү һәм Бәйрәкә авыл җирлекләрендә вак ташлы-комлы катнашмадан гыйбарәт өслекле юллар салынган. Муниципаль контрактлар буенча юлларны карап-төзәтеп тору өчен предприятие бер ел эчендә 11 миллион сумнан артык акча алуга ирешкән.

Башкарма хакимиятнең эш коралы булган «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» бюджет программалары буенча районга бирелә торган акчаларны мөмкин кадәр күбрәк үзләштерүгә һәм үзкыйммәтне киметүгә йөз тота. Бу очракта шәхси подрядчылар да роль уйный, чөнки көндәшлекне һич кире кагып булмый. Юлларга хезмәт күрсәткәндә ягулык азрак тотылсын өчен, предприятие хәтта маршрутларны да кыскартуга ирешкән.

Шунысы мөһим: предприятие торак пунктларны төзекләндерү эшләренә, чүп чыгару, яшелләндерүдән кала, төзелеш хезмәтен дә өсти. Урыссуда күпфатирлы йортларның подъезд яннары асфальт белән каплана, машина кую урыннары, балалар өчен мәйданчыклар төзелә. «Татнефтедор» ҖЧҖ Пушкин, Пионер, Урыссу, Чкалов һәм Куйбышев урамнарындагы йорт яны территорияләрен төзекләндерүгә акча бүлеп бирә. «Татнефть» ГАҖ акчасына берничә урамда тротуарларга таш түшәлә.

Йорт яны территорияләрен төзекләндерү программасы кысаларында район үзәгендә 125 ишегалды нормативларга җавап бирерлек хәлгә китерелгән.

«Парклар һәм скверлар» республика программасын финанслау да МУП аша алып барыла, ул подрядчыларның эшләрне тиешенчә башкаруын контрольдә тота. Бистәдә берничә парк төзелә һәм үзгәртеп корыла. Болар – «Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга дан» мемориаль комплексы, Сәнгать мәктәбе янындагы балалар скверы, Чкалов һәм Яшьләр паркы, Гаилә паркы. Былтыр үзгәртеп корылган Гаилә паркын бизәр өчен кече архитектура формалары куела һәм балалар өчен уен җиһазлары көйләнә. Бәйрәкә авылында Гобәйди скверы, Иске Урыссуга борылыш янында Җиңүнең 70 еллыгы паркы төзелә.

Үзара салым программасы буенча былтыр бистәдә тротуарлар төзелешенә 10,5 миллион сум акча тотыла, җиде ишегалды тәртипкә китерелә һәм матурлана. Ел саен чәчәк түтәлләре яңартыла, юл буй-

Реклама Фотолар «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» Муниципаль унитар предприятиесеннән алынды

ларында, скверларда һәм урамнарда агачлар утыртыла.

ӘЙЛӘНГЕЧ ЮЛДАН – КИЛӘЧӘККӘ

Эш күләме үсү белән, предприятиенең техника паркы да зурая, персонал саны да арта. Юл бригадасы барлыкка килә, парклар күбәйгәч, яшелләндерүчеләргә дә эш өстәлә, шәхси кибетләр һәм офислар каршында машина кую урыннары һәм чәчәк түтәлләрен тәртипкә салу буенча хезмәтләр саны да арта. 2016 елга 20 берәмлек техника һәм 53 хезмәткәр белән керсәләр, башкарылган эшләр өчен 120 миллион сумны үзләштереп, елны 30 машиналык парк һәм 72 хезмәткәр белән төгәлләлиләр.

2016 елда бистәнең иң төп Урыссу урамындагы киң колачлы ремонт эшләрен бик кыска срокта – районның 25 еллыгына төгәллиләр, бу исә әйләнгеч юл төзелеше алдыннан үзенә күрә репетициягә әйләнә. Урамдагы ремонт бик катлаулы була. Юл нигезен тикшергәч, иске асфальт астында вак таш урынына метр ярым кара туфракка тап булалар. Уңдырышлы катламны алып, аның урынына инерт материаллар җәяргә туры килә, алар катлам-катлам – ком, вак таш һәм ике кат асфальтлы бетон рәвешендә тыгызлап барыла.

2017 елда инде 153 миллион сумлык эш башкарыла, ә предприятие штаты 80 кешегә җитә. Уртача хезмәт хакы да үсә – 20 меңнән 22,8 мең сумга кадәр. Техника паркына тагын 6 машина өстәлә. Республикадагы лизинг программасы буенча «Беларусь» тракторы базасындагы ике төяү-җыештыру машинасы, коммуналь җиһазлар көйләнгән минитөягеч, өч «КАМАЗ» –15 тонналы ике үзбушаткыч һәм кар чистарту, комлы-тозлы катнашма сибү җайланмалары көйләнгән юл хезмәте машинасы сатып алына.

Предприятие киләчәккә карап үсә. Октябрь аенда «Татнефтедор» ҖЧҖ белән килешү имзалана. Урыссу бистәсендә әйләнгеч автомобиль юлы төзүне күздә тоткан килешүнең смета бәясе 179 миллион сум тора. Өч ел элек юлларда бөтен эш күләме 38 миллион сум тәшкил итә. Зур йөк машиналары үтәргә тиешле әйләнгеч юл бистәдәге транспорт хәрәкәтен җиңеләйтәчәк, бистәдәге юлларны тәртиптә тоту өчен чыгымнарны киметәчәк, экологик вазгыятьне яхшыртачак, тавышны һәм зарарлы төтеннәрне киметәчәк.

– Юлны «нульдән башлап» төзү безнең өчен яңа эшчәнлек юнәлеше, – дип сөйли «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» МУП директоры Илшат Камалдинов. – Объект катлаулы һәм бик җаваплы, чөнки юл бер үк вакытта дамба да булып хезмәт итә. Бу – республика программасы, «Главтатдортранс» заказчы булып тора. 1 апрельгә без 2,6 км га сузылган үз участогыбызда юл нигезен җәеп бетерергә тиеш. Безнең өчен бу имтихан да, киләчәктә юл төзелешендәге мөһим объектларда подряд эшләр башкаруга старт та.

Директор сүзләренә караганда, предприятиенең үсешенә республика җитәкчелеге булышлык күрсәтә. Урыссу предприятиесе өчен өстәмә эшләр «сорап йөдәткән» район башлыгының сүзенә колак салалар, ләкин подрядчы да төшеп калганнардан түгел. Башка районнарда мондый күп юнәлешле идарәләр юк: аларда берничә оешма үз өлкәсенә караган эшләрне генә башкара.

– Универсальлек мәшәкатьле ул, – дип белдерә директор, – документация, лицензияләр, төрле рөхсәтләр алу белән бәйле эш күбәя. Үзебезгә дә укырга-өйрәнергә, хезмәткәрләрне дә эш арасында укытырга туры килә. Әмма шул ук вакытта үз-үзебезне тәэмин итү, туендыру ягы да – үсештә. Бөтен төр юл эшләрен үзләштердек, яңа асфальт җәйгеч һәм грейдер алсак, техника белән тулысынча тәэмин ителгән булабыз. Район башлыгы инде асфальт-бетон заводы сатып алу турында сүз кузгата.

Әлегә асфальтны өстәмә хак белән Башкортостаннан сатып алалар. Октябрьск юлындагы күперне йөк машиналары өчен япкач, логистика мәсьәләсе дә токтарлык китереп чыгара. Үз заводлары, һичшиксез, юл төзелешендәге рентабельлелекне арттырачак. Ә бүген бистәнең, районның юллар системасын үстерү, транспорт һәм җәяүлеләр өчен уңайлы мохит булдыру, юл төзелеше күләмен һәм тизлеген арттыру – идарәнең төп бурычларыннан гына түгел, ә аның бюджетындагы мөһим маддә дә булып кала.

Юл төзүчеләр инде күрше районнар һәм төбәкләрне яулап алу мөмкинлекләрен өйрәнәләр. Техник яктан җиһазландырылу һәм инфраструктура моңа юл ача. Якын-тирәдә файдалы казылмалар, ташлы ком, чуерташ, вак таш, ком җитәрлек. Тимер юл да кул сузымында гына – төзелеш материалларын теләсә нинди күләмдә китереп бирәчәк. Димәк, көндәшлекле өстенлекләр арта гына бара.

PRESSA.RU

КӨНДӘШЛЕККӘ СӘЛӘТЛЕ БУЛУ – ТӨП ШАРТ

«Урыссу химия заводы» ҖЧҖ – Россиядә нефть чыгару тармагы өчен химик реагентлар җитештерү юнәлешендәге иң алдынгы предприятиеләрнең берсе. Ул бу тармак базарының 15 процентын алып тора. Завод 80 нән артык төрдәге реагент җитештерә: ингибиторлар, асфальтлы-сумалалы-парафинлы утырмаларны (АСПО) чистарткычлар, деэмульгаторлар, күкертле водород нейтрализаторлары һ.б.

Николай Лукин, «Урыссу химия заводы» ҖЧҖ генераль директоры

Урыссудагы тәҗрибә-химия заводына СССР Нефть сәнәгате министрлыгы карары белән 1987 елда нигез салына, ә бер елдан инде ул нефть чыгару нәтиҗәлелеген арттыру һәм промысел җиһазларын саклау өчен химик реагентларның тәүге партиясен җитештерә. Болгавыр 90 нчы елларда завод ябылу чигенә җитә, ләкин 2003 елда яңа хуҗалар һәм җитәкчелек аңа икенче сулыш өрә. Икътисадый сәясәтнең үзгәрүе, җиһазларны яңарту һәм кирәкле кадрларны әзерләү яхшы нәтиҗә бирә: предприятие базарга көндәшлеккә сәләтле продукция белән чыга.

2003 елдан 2017 елга җитештерү күләме өч тапкырдан күбрәккә артып, аена 3000 тоннага кадәр җитә. Реагентларның дөнья стандартларына җавап бирүен предприятиенең халыкара күргәзмәләрдә алган бүләкләре һәм ГОСТ ISO 9001-2008 стандарты буенча сертификацияләнгән сыйфат менеджменты системасы раслый.

Бүген компания 80 нән артык төрдәге реагент эшләп чыгара. Химик реагентлар ассортиментында – парафинлы утырмаларны чистарткычлар, коррозия ингибиторлары, деэмульгаторлар һәм коррозия деэмульгатор-ингибиторлары, күкертле водород нейтрализаторлары, бактерицидлар.

Төп заказчылар – реагентлар җитештерүчеләр, «НИИНефтепромхим» АҖ, «Напор» АҖ, «Химтехно» Фәнни-җитештерү үзәге» ЯАҖ, «Технотэк» компанияләр төркеме» ҖЧҖ, «ЭТН Фәнни-җитештерү үзәге» ҖЧҖ, «Гектор» Фәнни-җитештерү фирмасы» ҖЧҖ, «Миррико» ҖЧҖ кебек компанияләр. Продукцияне кулланучылар исә – Россиянең һәм якын чит илләрнең алдынгы нефть чыгару компанияләре.

Химия заводының финанс ягыннан уңышлылыгын 2017 ел йомгаклары да дәлилли: бу елда 32 мең тонна продукция эшләп чыгарылган. Предприятие Россиядә җитештерелә торган химик реагентлар базарының 15 процентын биләп тора. Сүз уңаеннан, әлеге базарда көндәшлек бик көчле: 2008 елда Россиядә мондый предприятиеләр өч-дүрт кенә булса, хәзер аларның саны ике дистәгә җитә.

Былтыр Урыссу заводының сатудан кергән акча күләме 749 миллион сумны тәшкил иткән, предприятие 76 миллион сум салым түләгән. Әмма мондый нәтиҗәләргә ирешү җиңел бирелми.

– Заводны җылылык һәм зәһәр технологик пар белән тәэмин иткән Урыссу ГРЭСы ябылу аркасында, җылылык үзәкләре төзү һәм газлаштыру өчен 53 миллион сум сарыф итәргә туры килде. Бу максат белән алынган бурычлар капланып бетсен өчен, сигез еллап вакыт кирәк, ләкин җитештерү процессын туктатмау хакына без бу мәсьәләне хәл итүгә бар көчебезне салдык, – дип аңлата заводның генераль директоры Николай Лукин.

2016–2017 елларда монда 1,3 км озынлыктагы җир асты газүткәргече салалар, җылылык трассасын, заводның барлык биналарында һәм участокларында җылылык системасы җиһазларын тулысынча алыштыралар. Элеккеге җылылык ноктасын газ җылылык үзәге итеп үзгәртеп корып, яңа бүлекчә – җылылык белән тәэмин итү цехын оештыралар. Предприятиене су белән тәэмин итү өчен берничә скважина көйләүгә 6 миллион сум чамасы акча тотыла. 2017 ел өчен капиталь кертемнәрнең гомуми суммасы 54,8 миллион сумны тәшкил итә.

Сыйфат ягын тәэмин иткән хәлдә, завод сату бәяләрен иң түбән дәрәҗәдә тота. Шул ук вакытта заказчыларга күрсәтелә торган өстәмә хезмәтләр исемлеге арта бара: химик реагентлар процессингы һәм нефть продуктларын саклауга логистика сервисы һәм куркыныч йөкләрне китереп бирү хезмәте өстәлә. Предприятие болар өчен кирәкле һәрнәрсә белән тәэмин ителгән: үз автомобиль һәм тимер юл цистерналары паркы, 25 мең тонна товар сакларлык резервуарлар паркы бар.

2018 елга бурыч – заказ күләмнәре кимесә дә, җитештерүне саклап калу. Ел саен 4,8 мең тонна реагентка заказ бирә торган «Татнефть-Химсервис» компаниясенең китүе дә шактый сизелерлек югалту була. Бу мәсьәлә яңа клиентлар җәлеп итү аша хәл ителә: хәзер

Фотолар «Урыссу химия заводы» ҖЧҖнән алынды

Реклама

җиһазлар кабат тулы куәтенә эшли, перспективалы заказчылар да бар. Шуңа күрә коррозия ингибиторлары концентраты җитештерә торган тагын бер җайланма төзеләчәк.

– Без җитештерү җиһазларын яңарту өчен якынча 40 миллион сум тоттык, – дип сөйли директор. – Хәзер кулланыштагы җайланмада реакторларны алыштырдык, корылачак аппарат өчен яңа реакторлар кайтарттык. Тимер юл цистерналарын арттырдык, лаборатория өчен яңа җиһазлар сатып алдык. Төрле куркынычсызлык системалары өчен дә чыгымнар тотабыз, аерым алганда, административ бинадагы янгын сүндерү системасын алыштырдык.

2018 ел өчен капиталь кертемнәр буенча инвестицияләр планы 37 миллион сум чамасын тәшкил итә. 1 нче цехны, су әзерләү җиһазларын көйләү бинасын, җылылык үзәкләре операторлары өчен корылманы үзгәртеп кору планлаштырылган. Электр энергиясе тапшыру җиһазларын яңартырга һәм киңәйтергә ниятлиләр, чимал һәм әзер продукцияне саклау өчен яңа мәйданчыклар төзү каралган. Җитештерү һәм лаборатория җиһазлары, су әзерләү өчен җиһазлар, җылылык үзәге өчен өстәмә җайланмалар сатып аласы бар.

Предприятие сәнәгый иминлекне тәэмин итү һәм экологиягә зарарлы тәэсирне киметү юнәлешендә шактый зур акчалар тота. Яңгыр сулары һәм юынтык сулар өчен чистарту җайланмалары сатып алынган һәм эшләтеп җибәрелгән, чистарту корылмаларындагы исне бетерү өчен «ПЛАЗКАТ-аэро» җайланмасы эшли.

Предприятиедәге 182 хезмәткәрнең эш шартлары җитәкчелекнең бу юнәлештәге кайгыртучанлыгы турында сөйли: кирәкле барлык йорт җиһазлары һәм җайланмалар булган вакытлы торак бүлмәләре, цех башлыкларының җиһазландырылган кабинетлары, хезмәткәрләрне уку-укыту һәм аттестацияләү өчен компьютерлаштырылган система, үз медицина ярдәме пункты һәм скрининг өчен җиһазлар...

Заводта 28 мең сумга җиткән хезмәт хакының тотрыклылыгы һәм социаль гарантияләр коллектив шартнамә белән көйләнә. Социаль түләүләргә һәм гарантияләргә бер елда 2 миллион сум тотылган. Болар – бала туганда, гаилә корганда каралган компенсация түләүләре, лаеклы ялга чыкканда һәм һөнәри бәйрәм уңаеннан бер тапкыр бирелә торган матди бүләкләүләр һ.б.

Завод бистә һәм район тормышында актив катнаша, төрле иҗтимагый бәйрәм-кичәләр оештырганда, хәйрия акцияләрендә акчалата ярдәм күрсәтә.

Уруссинский химический завод

PRESSA.RU

Сирин Галиев, «Агромир» ҖЧҖ-нең гамәлгә куючысы

«АГРОМИР» – ЗУР МӨМКИНЛЕКЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Ютазы районының Бәйрәкә авылы музеенда совет чоры байраклары саклана. Үткән чорның башка артефактлары белән чагыштырганда, алар һич тә пафослы, урынсыз яисә архаик булып күренмиләр. Мөгаен, авылда колхоз эшчеләренә ирешкән уңышлары өчен тапшырылган бу байракларны саклап кала белгәннәре һәм тиешле урын тапканнары өчендер. «АгроМир» хуҗалыгы әнә шулчакта ирешкәннәрдән үсеп чыккан да бит инде.

«БИК ЯХШЫ» БИЛГЕСЕНӘ АВТОМАТЛАШТЫРУ

Сыер абзары уртасыннан робот үтеп йөри. Ул идәнгә чәчелгән печәнне «сизеп», аны, сыерлар үрелеп алырлык итеп, аратага этә. Сыерларның канәгать мөгрәвенә караганда, роботны биредә күптән үзләренеке дип саныйлар.

Мондый «уенчык»ны алу теләсә кайсы хуҗалыкның кулыннан килми (аның бәясе 1 миллион сумнан артык). Әмма «АгроМир»да ул үз бәясен аклый, диләр. Әгәр ул нинди дә булса сәбәп белән эшләми торса, савылган сөт күләме тәүлегенә 300–400 килограммга кими икән. Әмма роботтан башка да «АгроМир» район өчен рекордлы күләмдә сөт сава. Дөрес, моның өчен хуҗалыкта башка технологик могҗизалар да, мәсәлән, «»Европараллель» савым залы да мөмкинлек бирә.

– Хәзер бездә өч мең баштан артык мөгезле эре терлек исәпләнә, шуларның 800е – савым сыерлар.

Бер сыердан тәүлегенә 16–17 литр сөт савыла. Мондый күләмне саклап калу өчен, беренчедән, саву технологиясен сакларга, икенчедән, аны мөмкин кадәр оптимальләштерергә кирәк. Без боларның беренчесенә дә, икенчесенә дә ирештек, – дип сөйли терлекчелек цехы җитәкчесе, «АгроМир»ның баш зоотехнигы Айдар Ханбеков. Хуҗалык автоматлаштырылган савуга республикада беренчеләрдән булып күчкән. Саву залы кеше хезмәтен, шуның белән бергә кеше факторын минимумга калдырырга мөмкинлек биргән – сыер абзарында бер сменада, ветеринарны һәм аның ярдәмчесен дә кертеп, 13 кеше эшли. Шул ук вакытта «АгроМир»дагы хезмәт хаклары районда иң югарылардан.

– Сатып алу бәяләренең төшүе Татарстанның башка сөт җитештерүчеләренә дә, безгә дә бердәй тискәре йогынты ясый. Әлегә без 4,2% майлылыктагы сөтнең литрын 19 сумнан сатабыз. Ә кибеттә майлылыгы 3,2% булган сөтнең 940 граммлы шешәсе күп тапкыр артыграк бәягә сатыла... Мондый чагыштырма бераз кәефне төшерә. Безнең хуҗалык территориясендә яңа объектлар төзү планыбыз бар иде. Күрәсең, әлегә моны читкә куеп торырга туры килер. Шулай да «АгроМир»ның пессимизмга караганда, оптимизм өчен сәбәпләре күбрәк. Безгә проектларыбыз өчен кредитлар алырга туры килмәде, шулай булгач, чагыштырмача мөстәкыйльлек саклыйбыз. Моннан тыш, хуҗалыкның үз механизмнары бар, шулар ярдәмендә базар вазгыяте кыенлыкларын бераз киметә алабыз.

РАЦИОНАЛЬ ОРЛЫК

Орлыкчылык – илебезнең иң яхшы традицияләре сакланып

Фото: Александр Ефремов

Реклама

калган хәлдә һәм фәнни мөнәсәбәт белән – Бәйрәкә хуҗалыгының ныклы нигезе әнә шуңа корылган. 7,6 мең гектар сөрүлек җирләрдән 2,2 меңгә якын гектары бодай чәчү өчен каралган, 600 гектары – рапска. Калган җиргә арпа, терлек-туар өчен һәм азык борчагы, кукуруз, күпьеллык үләннәр чәчелә. Чәчү өчен бары тик элита һәм супер-элита орлыклары гына алына, барысы да – югары продуктив сортлар.

– Бөртеклеләрне без сату өчен үстерәбез, бу безнең «куркынычсызлык мендәре». Безнең үз ашлык саклау урыныбыз бар, анда хәзер 4 мең тоннага якын бодай саклана. Бу сезонда сатып алу бәяләре белән хәл бик шәптән түгел, шулай да без аны югалтуларсыз сатарга өметләнәбез. Ә менә саклау өчен үз мәйданнары һәм корылмалары булмаган хуҗалыкларга авырга туры килә. Гомумән алганда, югары уңышка ирешү – эшнең яртысы гына әле. Аны дөрес итеп сата белергә дә кирәк, – ди «АгроМир» идарәчесе Нәсим Вәлиев.

Ә инде уңышлы сату өчен сыйфатлы итеп сакларга кирәк. Һәм «АгроМир»да ашлыкның ничек саклануы тагын бер кат хуҗалыктагы барлык белгечләрнең әйтелмәгән кагыйдәсен раслап тора – профессионаллар өчен вак-төяк була алмый. Ашлыкның һәр сортына маркировка ясалган, склад яхшы вентиляцияләнә, хезмәткәрләр даими рәвештә температура һәм дымлылык дәрәҗәсен тикшереп торалар. Яз көне склад капкалары ачыла, ашлык кояшта җылытыла. Шулай эшләгәндә, ул тизрәк шытып чыгачак.

– Баштан ук үсемлекчелек безнең өчен, терлекчелек кебек үк, өстенлекле юнәлеш булды. Һәм эш монда ашлык сатудан керем алуда гына түгел, хәер, монысы да бик мөһим. Без бүгенге көндә терлекләрне балансль рацион белән тәэмин итәрдәй азык үстерергә һәм әзерләп куярга мөмкинлек бирә торган технологияләргә һәм тәҗрибәгә ия. Һәр төркем өчен ул рацион аерым. Шулай итеп без ит һәм сөт продуктлылыгында иң яхшы нәтиҗәләргә ирешәбез, – дип аңлата «АгроМир»ны гамәлгә куючы Сирин Галиев.

– Бу – Татарстанның бөтен көньяк-көнчыгышында иң югары технологияле фермаларның берсе. Районда «АгроМир» терлекчелектә дә, үсемлекчелектә дә әйдәп бара. Соңгы елларда алар нәсел хуҗалыгы статусына ия булды – Россия төбәкләренә һәм якын чит илләргә таналар саталар. Ә бит терлекләр нәсел таләпләренә туры килсен өчен, хуҗалыкка күп төрле параметрларны сакларга кирәк – авырулар буенча чисталыкны, югары продуктлылыкны һәм репродуктивлыкны һ.б., – ди Ютазы районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Аяз Шәфигуллин.

– Боларның барысына, шул исәптән хезмәтнең бик яхшы оештырылуы, технологияләрне даими камилләштерү нәтиҗәсендә, боларның барысын башкаручы профессионаллар командасы ярдәмендә ирешелә. Сатыла торган сөтнең сыйфаты һәм дәрәҗәсе буенча «АгроМир» берсүзсез сөтне сәнәгатьтә җитештерүчеләр белән көндәш була ала.

pressa.ru

«ВОЛМА-ӘБСӘЛӘМ»: БАРЫСЫ ДА ТӨЗЕЛЕШ ӨЧЕН

Ютазы районында моннан биш ел элек «ВОЛМА-Әбсәләм» ҖЧҖ тарафыннан сафка бастырылган гипс-картон табаклар һәм уемлы-сырлы бүлем плитәләре производствосы – бүгенге көндә Татарстан төзелеш индустриясенең иң эре предприятиеләреннән берсе. Ул Идел буен һәм Уралны заманча экологик төзелеш материаллары белән тәэмин итә.

Уникаль үзенчәлекләргә ия табигый төзелеш материалы буларак, гипс борынгы мисырлылар тарафыннан киң кулланылган, бизәү, измәләр ясау, диварларны штукатурлау өчен алебастрдан файдаланганнар. Бәйләвеч үзлекле гипс нигезендәге материаллар биналарның эчке бүлемнәрен ясаганда һәм биналарны бизәүнең барлык этапларында диярлек кулланыла.

Материал агулы түгел, исе дә юк, аллергия дә булдырмый. Гипс кушылган конструкцияләр җиңел, җылылык һәм тавыш изоляторлары буларак та яхшы. Гипсның һаваның дымлылыгына карап, артык дымны йота һәм кайтара алу сәләте, әлеге төзелеш материалын бина эчендәге микроклиматны көйләүче буларак куллану мөмкинлеген дә бирә.

Россиянең «ВОЛМА» компаниясе Россия һәм ЕАЭСның төзелеш-бизәү базарында коры төзелеш катнашмалары һәм гипс картон табаклар җитештерү күләме буенча икенче урында* тора (беренче урында – бөтен дөнья буенча 170 предприятиесе булган Германиянең КНАУФ предприятиесе), ә уемлы-сырлы плитәләр җитештерүдә әйдәп бара. Россиядә компаниянең җиде заводы бар: Воскресенскида, Майкопта, Оренбургта, Чилбедә, Волгоградта (икәү) һәм Әбсәләмдә.

Әбсәләм авылындагы җирле төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты мәйданының бер өлешен алгач, компания этаплап иске корпусларны һәм җитештерү линияләрен үзгәртеп кора. 2013–2014 елларда гипс-картон табаклар җитештерүен (ГКЛ), шул исәптән – һаваны чистарту системасын яңартып коруга «ВОЛМА-Әбсәләм» ҖЧҖ тарафыннан 60 миллион сумнан артыграк акча тотыла. Тагын 120 миллион сум 2014–2015 елларда уемлы-сырлы плитәләр (ПГП) җитештерүен яңартып коруга китә. Гипс кайнату егәрлекләре барлыкка килә, аның өчен чимал күршедә генә урнашкан Мәгъсут карьерыннан алына.

Өзлексез эшләү режимы көйләнгән, җитештерү процесслары автоматлаштырылган, халыкара сыйфат стандартлары кертелгән, хезмәткәрләр укытылган-өйрәтелгән. 10 миллион сумнан артыграк акча җитештерү егәрлекләрен арттыру өчен өстәмә электр тапшыру линияләре төзелешенә инвестицияләнгән. Махсус су суырту скважинасы бораулангаң.

Реклама Фотолар «ВОЛМА-Әбсәләм» ҖЧҖнән алынды

* Гипс төзелеш материаллары җитештерүчеләрнең соңгы рейтингына ярашлы рәвештә

– Республикабыз да төзелештә безнең продукцияне активрак куллансын иде, – ди «ВОЛМА-Әбсәләм» ҖЧҖ директоры Игорь Степанов. – Безнең продукцияне төзүчеләр белә, әмма еш кына аны куллану бәрабәренә экономия ясауга бара алмыйлар, чөнки проектлау стадиясендә үк башка материаллар файдалану күздә тотылган була. Әгәр проектны алыштыра башласаң, башкару срокларын өзәчәксең һәм барысын да югалтачаксың гына.

Ә ГКЛ һәм ПГПдан ясалган бүлемнәр, шул ук вакытта, традицион кирпечтән өелгәннәре белән чагыштырганда, үзкыйммәте белән 20-30 процентка отышлырак. Кирпечкә караганда җиңелрәк булулары исә – бүлемнәрнең материалында экономия ясау бәрабәренә – бөтен проектны җитди арзанайтырга мөмкинлек бирә. Гипс-картон һәм уемлы-сырлы бүлемнәрне монтажлауның гадилеге сәбәпле, төзелеш сроклары да кыскара.

ПГП куллану исәбенә, мәсәлән, эчке бизәү эшләре дә арзаная. «ВОЛМА» тарафыннан камилләштерелгән материалларның кулланыштагы үзенчәлекләре совет аналогларыннан күпкә югарырак: плитәне штукатурларга кирәкми (шпаклёвка җитә), конструкция бүлемнең уемнарына су торбаларын һәм электр үткәргечләрен урнаштыру мөмкинлеген бирә.

Продукциянең үзкыйммәтен киметү өчен компания технологик процессларны оптимальләштерә: гипс кайнату линиясе өлешчә автоматлаштырылган, ГКЛ линиясендә сыйфат контролен автоматлаштыру чаралары үткәрелгән, эш дәвам иттерелә. 2019–2020 елларга коры катнашмалар линиясен төзү күздә тотыла.

Гипс-картон табакларны бер айда җитештерү күләме биш ел эчендә өч тапкыр диярлек арткан, бу сатуларның күләмен Татарстанда гына түгел, Башкортостанда, Самара, Түмән һәм Чиләбе өлкәләрендә дә арттырырга мөмкинлек биргән.

2017 елда предприятиедә 8 миллион квадрат метрдан артыграк гипс-картон табак һәм 400 мең квадрат метрдан артык уемлы-сырлы плитә эшләп чыгарылган.

Хезмәткәрләр өчен социаль пакет үз эченә бушлай комплекслы төшке ашларны, бассейнга абонементларны ала.

Төрле дәрәҗәдәге бюджетларга 22 миллион сумнан артыграк акча күчерелгән.

PRESSA.RU



АВАНГАРДТА – **ПЛАСТИК**

Район башлыгы Рөстәм Нуриев инициативасы буенча муниципалитет милке итеп калдырылган элеккеге базаның буш торган мәйданын дүрт ел элек «Горизонт» ҖЧҖ идарәсенә тапшырганнар. «Урыссу» сәнәгать мәйданчыгы эшли башлаганнан бирле, биредә 87 эш урыны булдырылган, инвестицияләр күләме 100 миллион сумнан артып киткән, ә узган ел 60 миллион сумлык продукция төяп озатылган.

2017 елның декабрендә, бу мәйданга сәнәгать паркы статусы бирелгәннән соң, аның территориясендә паркның инженерлык инфраструктурасын төзү буенча әзерлек һәм эзләнү эшләре башкарылган, аның өчен республика бюджетыннан 12 миллион сумнан артыграк акча бүлеп бирелгән. Төзелеш үзе быел башланачак.

– «Горизонт» ҖЧҖ идарә итүче компаниясенең төп эшчәнлеге булып полипропиленнан халык куллануы товарларын җитештерү һәм сату бурычы тора, – ди компания директоры Ринат Нәфыйков. – Бу азык контейнерлары, чиләкләр, тазлар, төрле зурлыктагы һәм формадагы савыт-саба, гөл чүлмәкләре, көрәкләр, боз чаналары… Ассортимент төрләре 35 гә кадәр җитте инде.

Азык контейнерлары өчен беренчел полипропилен «Уфа Оргсинтез», «Казан Оргсинтез» һәм «Түбән Кама Нефтехим» предприятиеләреннән килә. Азык өчен булмаган әйберләр өчен сәнәгатьнең пластик калдыкларын эшкәртәләр. Булган егәрлекләр аена 50 тонна чимал эшкәртергә мөмкинлек бирә, әмма эш сәүдә заказына карап эшләнә. Продукцияне (аеруча сезонына карап) алып бетерәләр: кыш көне – көрәкләрне һәм «ледянкаларны», язга – үсемлек өчен нәни ванналарны. Әмма заказларның төп өлеше – «эконом» сегменты сәүдә челтәрләреннән алына, һәм компания бәяләрне үзкыйммәте дәрәҗәсендә тота диярлек.

Пластик эшкәртүдән алынган керем – 33 миллион сумга якын.

Мәйданның бурычы – яңа проектларга ярдәм итү: җитештерү инфраструктурасы һәм инженерлык коммуникцияләре булган мәйданнарны ярашлы бәяләрдән арендага бирү. Паркта суүткәргеч, канализация һәм электр челтәрләренә тоташу мөмкинлеге бар. Озакламый газ кертеләчәк. Резидентлар субсидия программаларыннан файдалана ала, шул исәптән, «Лизинг-грант» программасы буенча алынган җиһазлар өчен чыгымнарның яртысы кире кайтарыла.

Бүгенге көндә паркта алты резидент бар. Бетон эшләнмәләр җитештерү һәм корпуслы җиһаз җыю белән «БлокСтрой» ҖЧҖ шөгыльләнә. «Экосистемалар» ҖЧҖ көнкүреш калдыкларын (ККК) җыя, төяп-озата һәм утильләштерә. «Семечкин» ҖЧҖ кыздырылган көнбагыш орлыкларын эшкәртә һәм төргәкләргә төрә. «ШЭ Катков И.Б.» төзелеш һәм такта материалларын ваклап һәм күмәртәләп сату белән шөгыльләнә. «ШЭ Кольцова Л.Р.» ашханә тота, шул ук вакытта читкә чыгып та хезмәт күрсәтә, тантаналар оештыра.

Бораулау скважиналарын ремонтлау өчен яңарту эретмәләре әзерләячәк «Таграс-химсервис» ҖЧҖ әлегә биредәге мәйданнарны рәсмиләштереп һәм тест үтеп йөри.

Мәйдан логистика ягыннан да кызыклы. Эре нефть табу һәм нефть эшкәртү җитештерүләре белән янәшәдә булганга, һәм «Мәскәү – Чиләбе» М-5 федераль трассасыннан 20 километр гына арада торганга, ул Куйбышев тимер юлына чыга ала: биредә паркның теләсә кайсы ноктасына йөк китереп җиткерү мөмкинлеге бирә торган берничә километр керү юллары, тепловоз, 2 тимер юл һәм 4 күпер краны бар.

Территориянең 20 гектарының дүрттән бер өлешеннән күбрәге – ачык җирдә вак таш, ком-таш катнашмасы, гравий һәм башка сибелүчән материалларны өю һәм саклау мәйданын тәшкил итә, коры цементны төяү-бушату, саклау һәм тутыру комплексы бар. Коры төзелеш катнашмаларын кабул итү пункты аларны автотранспортка төяүне дә күздә тота. Парктагы 40 тан артык сәнәгать-склад биналары 2,1 гектардан артыграк җирне били, аларга керү юлларына һәм мәйданнарына асфальт җәелгән. Дүрт склад кран-балкалар белән җиһазланган. Хезмәткәрләр һәм кунаклар өчен кунакханә комплексы эшли.

Парк яңа резидентлар көтә. Перспективада берничә яңа җитештерү һәм авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең ветлабораториясе һәм сәүдә рәтләре булган «АгроМир» базарын ачу күздә тотыла.

Фотолар «Горизонт» ҖЧҖнән алынды

Реклама

ИННОВАЦИЯЛӘР ПОТЕНЦИАЛЫ

Авиация, космик техника һәм диңгез техникасы өчен герметик электр тоташтыргычлар җитештерү белән шөгыльләнә торган «Электросоединитель» АҖ Россия оборона сәнәгатенең алдынгы предприятиеләреннән санала. Урыссу заводы продукциясен радиотехника, нефть һәм газ сәнәгате, фәнни-тикшеренү үзәкләре киң куллана.

Рәшит Нәбиуллин, «Электросоединитель» АҖ генераль директоры

Ярты гасыр элек Казан радиокомпонентлар заводының СССР Электрон сәнәгать министрлыгы боерыгы белән авыл җирлегендә оештырылган филиалы совет чорында бер-бер артлы рекордлар куя – 1990 елда эшләп чыгарылган электр тоташтыргычлар күләмен әле хәзер дә уза алганнары юк. Ләкин оборона сәнәгатенең социализмнан базар мөнәсәбәтләренә күчеше предприятиене банкротлык чигенә китереп җиткерә: 1995 елга җитештерү күләме 25 тапкыр кими, завод халык куллану продукциясе җитештерүгә күчәргә мәҗбүр була.

Әнә шул катлаулы заманда предприятиегә җитәкче итеп Рәшит Нәбиуллин билгеләнә. Шушы районның Әбсәләм авылында туып-үскән ир-егет ул вакытка инде заводта мастердан алып баш механикка кадәр хезмәт юлы узарга өлгерә. Аның кул астында предприятие тәҗрибәле белгечләрнең төп өлешен саклап калуга һәм 1999 елда керемгә эшли башлауга ирешә.

Бүген завод – Ютазы районының иң эре салым түләүчеләреннән. 2017 елда монда 433 мең электр тоташтыргыч эшләп чыгарылган, сатудан килгән акча күләме 794 миллион сумны тәшкил иткән, ә бюджетның төрле дәрәҗәләренә 198 миллион сум салым түләнгән.

«Радиоэлектрон технологияләр» концерны составына кергән предприятие өчен бу тармакта импорт товарларны алыштыру программасы үсеш кыйблась әйләнә. 2002 елда завод Татарстан Республикасының иң яхшы экспортеры дип таныла. Аның продукциясеннән Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә 900 дән артык предприятие файдалана.

Акционерлык җәмгыяте Россиянең барлык әһәмиятле хәрби-тематик күргәзмәләрендә катнашып килә. Минскида узган Халыкара «АВТОМАТЛАШТЫРУ ЭЛЕКТРОНИКА-2017» күргәзмәсендә завод үз продукциясен бик уңышлы тәкъдим итә, нәтиҗәдә төрле халыкара килешүләр төзелә.

2010 елның сентябреннән башлап, завод электр тоташтыргычларын үзе әзерләп, уйлап чыгара. Товар номенклатурасын арттыру һәм сату базарын киңәйтү максатында яңа буын герметик электр тоташтыргычлары үзләштерелә һәм аларны җитештерү җайга салына. Бу тоташтыргычлар чит ил аналогларыннан калышмый торган типономиналларның (СНЦ146Г, СНЦ156, СЦ220) югарырак характеристикалары на һәм шактый киң үзенчәлекләренә ия. Космик сәнәгать тармагы өчен 9Р тоташтыргычларын җитештерү җайга салына, Россия заводлары аларны элек Украинадан сатып ала торган булган. Пресслаган үтәли ИСПП-1а, ИСПП-1г пыяла изоляторлары җитештерү яңадан торгызыла. Күләмле һәм басма монтаж өчен югары дәрәҗәдәге герметиклыкка, шул исәптән термокомпенсацияле контактка ия вилкалар җитештерү үзләштерелә. Геофизика комплексы һәм атом сәнәгате өчен яңа эшләнмәләр тәкъдим ителә.

Пыяла пресс-порошокны сиптерү һәм һавада килеш хәлендә киптерү ысулы белән үз җитештерүләрен көйләп җибәрәләр. Бу исә заводка Россиядә пыяла изоляторлар һәм пресс-порошок белән тәэмин итүче иң эре оешмаларның берсенә әверелергә мөмкинлек тудыра. Завод җитештергән тоташтыргычларның төп конструктив үзенчәлеге шунда: саклагыч атмосфералы, конвейерлы электр мичендә пыяла изоляторларны тимер-никель эретмәләр белән югары температурада ябыштыру бик яхшы электротехник сыйфатлар бирә.

Предприятие ел саен югары технологияле яңа җиһазлар сатып алуга, җитештерү мәйданнары һәм корылмалары төзүгә капиталь кертемнәрне сизелерлек арттыра бара. «Электросоединитель» АҖ куәтле фәнни-техник базага һәм югары квалификацияле кадрларга ия. Аның төп байлыгы – кешеләр. Монда социаль партнерлык сәясәтенә зур игътибар бирелә. Заводта 900 гә якын кеше эшли, уртача хезмәт хакы 28 мең сумны тәшкил итә. Квалификацияне күтәрү, бу тармактагы башка һөнәрләрне үзләштерү өчен бар мөмкинлекләр тудырылган. Заводның профкомы һәм яшьләр комитеты актив эшли, корпоратив бәйрәмнәр һәм спорт чаралары уздырыла, «Завод хәбәрләре» газетасы предприятие тормышын яктыртып бара.

Фотолар «Электросоединитель» АҖнән алынды

Реклама

PRESSA.RU



АВЫЛДАГЫ КЕЧЕ БИЗНЕС: **ХЕЗМӘТ ҺӘМ САБЫРЛЫК**

Өч ел элек Ютазы районының Подгорный бистәсендәге гаилә кошчылык фермасы хуҗасы – шәхси эшкуар Линиза Ильясова эш көннәрен бер җөмлә белән генә аңлатып биргән иде: «Сезон вакытында фермада кунабыз». Тормыш рәвешендә, күргәнебезчә, тамырдан үзгәрешләр булмаган, әмма моның җитди һәм күңелле сәбәбе бар – кошларның саны өч тапкырга диярлек арткан.

Рафис Ильясов

Ирле-хатынлы Ильясовлар гаилә бизнесына керешкәнгә алты ел үтеп киткән инде. Подгорныйда алар, көч һәм акча туплап, берничә ташландык сыер абзары да булган 5 га җирне сатып алганнар, һәм аны ремонтларга тотынганнар.

Бурычлар, кредитлар, тәүлек әйләнәсе диярлек эшләү чоры төрле җиһазлар һәм җайланмалар, азык, препаратлар һәм кошларның үзләрен – күкәй салучыларын һәм бройлерларын – сайлау һәм сатып алу мәшәкатьләре белән алышынган. Баштарак төзелеш, күпләп кош үстерү буенча тәҗрибәсезлек һәм кошчылыкта ветеринария белемнәре булмау кыенлыгы эш барышында артта калган. Ә инде чебиләр сатып алуның еш кына фермада кунып калуга тиң булуын Линиза һәм Рафис Ильясовлар гадәти хәл буларак кабул итәргәияләшкән.

Тере организмдай үсә барган киң күләмле проект өч ел эчендә югары технологияле кош фермасына әверелгән. 700 һәм 440 квадрат метрлы яңадан төзелгән һәм җиһазландырылган ике бинада (берсендә – 15 мең, икенчесендә 9 мең кош асрала) 2015 елда ук 20 мең күкәй салучы тавык һәм өч мең бройлер исәпләнә. Аларның саны даими рәвештә язларын Свердловск нәсел заводыннан сатып алынган чебиләр һәм йомыркалар белән тулыланып тора. Беркадәр үстергәч, аларны Ильясовлардан Саратов, Самара, Удмуртия, Тамбов, Красноярск һәм Россиянең башка төбәкләре күмәртәләп сатып ала: чөнки аларның кошлары үлми диярлек, ныклы, сәламәт була. Немец нәселле күкәй тавыкларының сакланышы – 99 процентка, бройлерларныкы 95 процентка җитә. Шул ук вакытта тавыклар елына 320–350 данә сайлап алырлык эре йомырка салалар.

Әлбәттә, рентабельле җитештерү – җентекле хезмәт нәтиҗәсе, шул исәптән рацион ягыннннан да. Әзер комбиазыклар рационына хуҗалыкта 12 ингредиент кушып үзләре ясалган азыкны да өстиләр. Моның өчен ашлык склады төзелгән, тегермән өчен җиһазлар һәм ваклагычлар сатып алынган.

Әле 2014 елда ук, районның иң яхшы фермеры буларак, Линиза Ильясовага ТР Дәүләт Советы Рәисе грамота тапшырган. Әмма дәүләт хуплавы моның белән генә чикләнми.

2015 елның җәендә Ильясовлар районның алты бәхетлесе исемлегендә ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2015–2017 елларга крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» программасы буенча грант откannар.

Үсеп килүче хуҗалык өчен бик тә уңай форсат булган грант: банк кредитлары ставкаларының югарылыгын барыбыз да беләбез, хуҗалыкның ай саен түли торган кредитлары гына да ул чакта 200 мең сум тәшкил иткән. Ә планда – тагын 900 квадрат метрлы бер сарай төзү һәм кошларның баш санын 40 меңгә җиткерү.

Язуы да күңелле: хезмәт сөючән фермерлар грантны тулысынча нәтиҗәле итеп файдаланган, баш санын арттыру хыялына да ике тапкыр арттырып ирешкәннәр. Тагын бер сарай яңартып корылган, җиһазландырылган һәм кулланыла башлаган. Кошларның, күкәй салучы тавыкларның («Хайсекс браун» һәм «Декалб уайт» нәселле) һәм бройлерларның баш саны 2015 елдан башлап тагын 36 мең башка арткан (2016 елда – 36 меңгә, 2017 елда – 56 меңгә кадәр). Шуңа бәйле рәвештә, җитештерү күрсәткечләре дә арткан. 2017 ел нәтиҗәләре буенча 145,8 тонна кош ите җитештергәннәр (2016 елда – 118,9 тонна). 128,9 тонна сатылган (2016 елда – 106,6 тонна). Керем 16 миллион 143 мең сум тәшкил иткән (2016 елда – 15 миллион 261 мең сум).

Ә менә яшәү рәвеше, өч ел элек ничек булса, бүген дә шундый ук – хезмәт һәм сабырлыкка бәйле булып калган.

Фотолар «Л.Ильясова ШЭ»нан алынды

Реклама

«ХӘВЕФ ФАКТОРЫНА» БАСЫМ

Ютазы районында «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ хезмәткә сәләтле халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары барлыкка килү факторларын ачыклау проектын тормышка ашыра.

Светлана Шакирова, «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУның баш табибы

Ике ел дәвамында медиклар һәм район хакимияте, ышандыру чаралары һәм еш кына административ мәҗбүр итү юлы белән, предприятиеләрдә эшләүчеләрнең үз сәламәтлекләренә һәм табибларның киңәшләренә тиешенчә игътибар итүләренә ирештеләр. Нәтиҗәдә хезмәт яшендәге кешеләр арасында йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан үлүчеләр саны кискен китмеде. Республикада бу сан 1000 кешегә 21,1 очракны тәшкил итсә, районда исә – 18,6.

– Бу идеяне безгә район башлыгы Рөстәм Нуриев тәкъдим итте, – ди үзәк хастаханәнең баш табибы Светлана Шакирова. – Хезмәткә сәләтле гражданнар арасында авырулардан үлү очраклары – конкрет индикатор. Бу төркемдәге факторларны анализлау үлемнәрнең төп сәбәбе – йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан булуын күрсәтте. Без район хакимияте һәм предприятие җитәкчеләре белән бергә скрининг программасын төзедек, аны республика Сәламәтлек саклау министрлыгы да хуплады.

Әмма пациентка киңәшләр бирү – бер нәрсә, аның үтәлүенә ирешү исә – икенче мәсьәлә. Һәм монда популяр булмаган чаралар да кулланырга туры килә.

Светлана Шакирова, иң гуманлы белгечлекләрнең берсенә ия табиб – акушер-гинеколог, ләкин пациент белән сөйләшкәндә, шактый таләпчәнлек күрсәтергә туры килүен яшерми:

– СМС лар юллыйбыз, кайберәүләргә предприятие җитәкчелеге һәм хакимият учреждениеләре аша да йогынты ясыйбыз, хастаханәгә килгән туганнары аша да каралырга килүләрен сорыйбыз.

Ничек кенә булса да, район йөрәк-кан тамырлары авыруларының кимүендә сизелерлек нәтиҗәләргә ирешә һәм күптән түгел шуның нигезендә хезмәткә яраклы халыкның сәламәтлеген саклау буенча республика семинары узды.

Хезмәткәрләренең саны буенча районның иң эре алты предприятиесе (беренчеләрдән – «Электросоединитель» һәм химзавод), цехлардагы медпунктларны һәм «контроль нокталары»н җиһазлау өчен акча бүлеп биреп, программага кушылып китте. Эшчеләр аларда үзләре өчен уңайлы булган теләсә кайсы вакытта берничә минут эчендә мөстәкыйль рәвештә авырлыкларын һәм буйларын, кан басымнарын үлчи ала. Мәгълүматлар компьютер программасына кертелә.

«Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» республика конкурсында «Хезмәтләр» номинациясендә II дәрәҗә дипломга лаек булган «1С предприятие медицина кабинеты»ның камилләштерелгән программ тәэминаты кулланыла.

Һәр хезмәткәр турында мәгълүматы булган система хәвеф факторына кергән кешеләрне барлый, һәм белгеч аларга якынча киңәшләрен бирә, киңәшне һәр хезмәткәр турыдан-туры предприятиедә үк ала. Зуррак игътибар таләп ителгән очракта, пациентка табибның кабул итү вакытын һәм, хастаханәгә ятып, өстәмә дәвалану билгеләнә. Хастаханә өр-яңа диагностика җиһазлары белән тәэмин ителгән, һәм капиталь ремонттан соң тулысынча норматив таләпләргә туры килә.

«Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ – бу 314 хезмәткәр (алардан 40ы – квалификацияле табиблар), административ һәм дәвалау корпуслары, бала тудыру бүлеге, реанимация бүлеге, балалар консультациясе, дәвахәнә һәм ашыгыч медицина ярдәме бүлеге. Хастаханәдә 76 койка исәпләнә. Хастаханәнең тәүлеклек 10 койкасы булган акушерлык-гинекология бүлегендә бала тудыру залы һәм операция бүлмәсе бар. Районда шулай ук ике табиблык амбулаториясе һәм 18 ФАП урнашкан.

Реклама

Фотолар «Урыссу ҮРХ» ДАССУ нән алынган

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

PRESSA.RU

ХЕЗМӘТ СӨЮЧӘНЛЕК **БАРЫСЫН ДА ҖИҢӘ**

Иске Каразирек авыл җирлегендә нибары 680 кеше яши, ул Ютазы районының иң аз халыклы авыл җирлеге. Шул ук вакытта җирлек авыл хуҗалыгын үстерү өчен субсидияләр алу буенча даими рәвештә районда әйдәп баручылар сафына керә.

2015 елдан 2017 елга кадәр район башлыгы Рөстәм Нуриев контролендә тормышка ашырыла торган программалар буенча Каразирек фермерларына бүлеп бирелгән субсидияләрнең суммасы 920 мең сумны тәшкил иткән. Шул ук вакытта шәхси ярдәмче хуҗалык тотучылар өчен сөткә дотацияләр күләме 2017 елда 415 мең сумга җиткән.

Александр Ефремов фотосы

Модульле ветеринария пункты 2015 елда Каразиректә республика президент программасы буенча төзелгән. Монда участок ветеринария табибы кабинеты, даруханә, ясалма орлыкландыру пункты, хайваннарны карау пункты урнашкан. Пункт эре һәм кечкенә йорт хайваннарына үз вакытында һәм сыйфатлы ярдәм күрсәтү өчен бөтен кирәк-ярак белән тәэмин ителгән.

ПРОДУКТИВЛЫККА ЙӨЗ ТОТУ

Авыл җирлеге башлыгы Рамил Вәлиев бу күренешне бик җиңел генә аңлата: «Иске һәм Яңа Каразирек авылларында иң хезмәт сөючән кешеләр яши», – ди ул.

Гафиятовлар фермасында безне бертуган Фәйруз белән Эльвир каршы алды. Хуҗалыкка 1995 елда аларның әтиләре нигез салган. Яшьләрнең булачак хуҗалык өчен җаваплылыкны үз өсләренә алырга әзер булуларын күргәч, Фирдәүс Гафиятов КФХ белән идарә итүне уларына тапшырган.

– Без балачактан ук әтигә булыша идек, шулай булгач, тәҗрибәбез бар. Мин Казанда ветеринария академиясен тәмамладым, туганым – авыл хуҗалыгы институтын, – ди Фәйруз.

Җирлектә 722 баш мөгезле эре терлек исәпләнә, аларның 282се – Гафиятовларныкы.

– Фермабыз иске инде, зур да түгел. Үз көчебез белән ремонт ясадык. Көтүдә 62 баш савым сыерыбыз бар. Бер сыердан тәүлегенә 11 литрга якын сөт савабыз. Планда – савым сыерларны 80 гә җиткерү. Соңрак, барып чыкса, йөзгә кадәр, – дип аңлата Фәйруз.

Киләчәк турында ул саклык белән генә фикер йөртә – ашлыкка һәм сөткә сатып алу бәяләренең түбән булуы киләчәкне фаразларга мөмкинлек бирми. Әмма Гафиятовлар авырлыклардан курыкмыйлар. Алар моңа күптән ияләшкән инде.

– Техникабыз күп түгел, машиналарыбыз да күптәнге. Яңа агрегетлар бик кыйммәт тора. Берничә тапкыр акча җыярга тырышып карадык, тик һәрвакыт чираттагы бәяләр күтәрелү комачаулады, – ди фермер. Сүз уңаеннан, КФХның сөрүлек җирләре аз түгел – 870 гектар. Моннан тыш, 130 гектардан артык көтүлек җирләре, печәнлекләре, авыл хуҗалыгы җирләре бар.

– Продуктлылыкны арттыруга йөз тотабыз. Ике ел инде югары продуктлылыкка ия бозаулар үстерәбез, шуларның нәселен булдырырга уйлыйбыз. Район булыша, югары продуктлылыклы көтү өчен тотыла торган чыгымнарның бер өлешен түли. Шулай булгач, перспективалар бар, – дип нәтиҗә ясый Фәйруз.

МИНИ-ФЕРМАДАН – МАКСИМАЛЬ НӘТИҖӘЛЕЛЕК

Шәхси ярдәмче хуҗалыклар үсешенә республика дәүләт ярдәме чаралары нәтиҗәсендә соңгы ике елда җирлектә берничә мини-ферма төзелгән. Субсидия бирү шартлары буенча, ШЯХта, ким дигәндә, 50 %ка әзер булган мини-ферма, 3 баштан да ким булмаган сыер (8 башка каралган мини-фермага субсидия алу өчен) яки 2 баштан да ким булмаган сыер (5 сыерлы мини-фермага) асралырга тиеш. Беренче очракта субсидиянең максималь күләме – 200 мең сум, икенче очракта 120 мең сумны тәшкил итә. Шул ук вакытта хуҗалык башлыгы алдына, финанслар алынган көннән башлап, ярты ел эчендә ферманы кулланууга кертү, аннан соңгы алты айда өстәмә рәвештә 5 яисә 3 сыер (беренче һәм икенче очраклар өчен) сатып алу бурычы куела. 2016 елда Татарстанда әлеге документ кабул ителгәч, җирлектә шул ук елда 8 әр баш сыер өчен 4 мини-ферма төзелгән. Рамил Вәлиев әйтүенчә, тагын ике ШЯХ субсидия алу өчен гариза бирергә җыена.

Программада катнашучы Фәйрүзә белән Марат Килдияровлар нәтиҗәләрдән әлегә канәгать.

– Башта безнең биш савым сыерыбыз бар иде. Мини-ферма төзедек, субсидия алып, аның шартын үтәү өчен, баш санын унга җиткердек. Хәзер 13 савым сыерыбыз, симертелә торган берничә үгезебез, бозауларыбыз бар. Сыерлар бозаулаганнан соң, сөт күләменең артуын көтәбез, – ди Марат Килдияров. – Хуҗалыгыбыз иске, ул инде безгә ата-аналарыбыздан калган. Акрынлап аны яңартабыз. Шулай булгач, мини-фермалар программасы яхшы гына ярдәм булып чыкты.

Реклама

МАХСУС ПРОЕКТ

30нчы чыгарылыш

Татарстан юбилярлары

Ринат Ханбиков,
«Газпром межрегионгаз Казан» ЯАЖ генераль директоры, апрельдә 60 яшьлеген билгеләп үтә.

Фото «Газпром межрегионгаз Казан» ЯАЖ-нән алынды

Рафкать Кантюков,
«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ генераль директоры

Энергияне – тормышны ямьләүгә

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович!

«Газпром трансгаз Казан» җәмгыяте һәм шәхсән үз исемемнән Сезне тормышыгыздагы әһәмиятле дата – 60 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм!

Сез үзегезнең юбилейны елның гүзәл вакытында – табигать уянган һәм кешеләрне яңа хыялларга һәм өметләргә рухландырган чакта билгеләп үтәсез.

Сезнең бөтен хезмәт эшчәнлегегез Татарстан белән бәйле. Сез туган республикагызның мәшәкатьләренә һәм шатлыкларына, өметләренә һәм эш көннәренә чын күңелдән бирелгән кеше, өстәвенә, анда яшәүче халык мәнфәгатьләрен закон нигезендә ТР Дәүләт Советында яклыйсыз.

Сез бинеһая зур хезмәт тәҗрибәсенә ия зат. Зур чыныгулар алган һәм заманча карашларга ия шәхес. Сезнең югары профессиональлегегез һәм оештыру сәләтегез республикабызның бүгенге көн ягулык-энергетика комплексы үсешендә зур роль уйнады.

Карала торган мәсьәләләргә нигезле якын килү, максатка омтылудагы үҗәтлек, киң күләмдә фикерли белү – Сезне җитәкче буларак та, кеше буларак та бизи торган сыйфатлар. Эшлекле дөнья нәкъ менә Сезнең кебек актив, дәрт-дәрманлы, булдыклы, даими рәвештә эшне камилләштерү юлларын эзләүче кешеләрнең иңендә тора.

Мин Сезнең уңышларыгызга чын күңелдән шатланам, чөнки безнең алда гомуми бурыч – туган республикабыз өчен лаеклы хезмәт итү бурычы тора.

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович, 60 яшьлек юбилеегыз белән котлап, Сезгә ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек, иминлек, барлык идеяләрегезне тормышка ашыру өчен бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман, оптимизм һәм озын-озак бәхетле гомер телим!

Фото «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ-нән алынды

ПРЕДПРИЯТИЕ ТУРЫНДА КЫСКАЧА ТАРИХИ БЕЛЕШМӘ

«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ (оешкан вакыты – 1955 елның 1 июле) – «Газпром» ГАҖнең 100 %ка бүлендек җәмгыяте. Җәмгыятьнең төп бурычы – магистраль газүткәргечләрне, түбән басымлы газ челтәрләрен эксплуатацияләү, газ белән тәэмин итү системаларын проектлау, гамәлдәге газүткәргечләргә һәм газ хуҗалыгы объектларына капиталь һәм яңарту ремонтлары ясау, Россия кулланучыларына углеводород чималын озату һәм ирештерүдән тора.

«Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ Россия Федерациясенең иң эре газ бүлүче оешмаларыннан берсе санала.

Предприятие ел саен Россия Федерациясенең үзәк төбәкләренә, якын һәм ерак чит илләргә 240 млрд куб. метрдан артык табигый газ озата. Җәмгыять ел саен Татарстан Республикасы кулланучыларын 15 млрд куб. метрдан артыграк газ белән тәэмин итә. (2015 елның феврале – Татарстан Республикасына рекордлы 600 млрд куб. метр газ бирелгән.)

ТР табигый газ белән газлаштыру дәрәҗәсенең күрсәткече Россиядә иң югарылардан берсе – 99,5%. Республикада бүгенге көнгә 1 млн 500 меңгә якын фатир һәм йорт хуҗалыгы газлаштырылган.

Предприятиенең стратегик бурычы табигый газны ышанычлы һәм өзлексез рәвештә озатуны тәэмин итүдән һәм РФ бердәм газ белән тәэмин итү системасының (ЕСГ) газ транспорты системасын һәм үз җаваплылык зонасындагы газ бүлү челтәрен үстерүдән, Татарстан Республикасы һәм Идел буе Федераль округындагы кайбер төбәкләрнең: Оренбург, Самара, Ульяновск, Киров өлкәләренең, Башкортостан, Удмуртия һәм Чувашиянең газ бүлү челтәрләренә хезмәт күрсәтүдән гыйбарәт.

Реклама

Рөстәм Сүлтиев,
«ТАИФ» ААҖ
Директорлар советы рәисе

Заманча җитәкче үрнәге

Кадерле Ринат Сәгыйтович! Сезне тормышыгыздагы истәлекле дата уңаеннан кайнар котлыйм. Сездәге заманча әйдәп бару осталыгы, җаваплылык хисе һәм үзегез җитәкчелек иткән «Газпром межрегионгаз Казан» ЯАҖ хезмәткәрләре турында даими кайгыртып тору кебек сыйфатлар тирән ихтирам уята. Сездәге энергия, лаеклы нәтиҗәләргә ирешергә омтылу, тәҗрибә һәм тормышны белү коллективта Сезгә карата зур ышаныч булдырды.

Сез «Газпром межрегионгаз Казан» ЯАҖ үсешенә, яңа проектларны тормышка ашыруга биниһая зур өлеш керттегез, җитәкчелек тарафыннан алдыгызга куелган бурычларны уңышлы хәл итәсез. Ринат Сәгыйтович, Сез – хезмәткәрләрне туплый белүче һәм нәтиҗәле конструктив партнёрлык төзи алучы заманча җитәкче үрнәге! Тирән белемегез, оештыру сәләтегез, карарларны барысын да алдан үлчәп кабул итүегез Сезгә киләчәктә дә иң амбициоз планнарыгызны һәм башлангычларыгызны уңышлы тормышка ашырырга булышыр, дип ышанам.

Тормышыгыз игелекле эшләр, шатлыклы вакыйгалар, күтәренке кәеф, бәхет һәм иминлек белән тулып торсын! Сезгә һәм якыннарыгызга иң изге теләкләребезне юллап калабыз!

Фотолар «ТАИФ» ААҖнән алынды

PRESSA.RU

Сергей Шевченко,
«Аммоний» АҖ
генераль директоры

Берләштерү осталыгы

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович!

«Аммоний» АҖ коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән ихластан котлыйм. Сезнең адреска бүген уңыш, бәхет теләп әйтелгән барлык изге теләкләр дә, һичшиксез, киләчәк казанышлар һәм җиңүләр өчен стимул булыр. Сезгә хас куәтле лидерлык һәм югары профессиональлек сыйфатлары, җитәкчелек таланты һәм карарлар кабул итүдәге кыюлык моңа ышаныч уята.

Турыдан-туры Сезнең катнашыгыз белән тормышка ашырылган төп проектларның берсе – ул «Аммоний» АҖ. Бүген әлеге компания – тулысынча экспорт юнәлешле заманча завод. Япония, Кытай һәм Россия катнашкан бу күп миллиардлы проект бик катлаулы булды, дип әйтү генә аз булыр. Аны тормышка ашыру тарихы 2004 елда башланган иде: ул чакта республика хөкүмәте Сездән бөлгенлеккә төшү алдында торган һәм, совет елларында ахыргача төзелеп бетмәгәнгә күрә, көндәшлеккә сәләтле продукция чыгара алмаган «Татазот» заводын кризистан чыгаруны сорады. Проектны тормышка ашыруның финанс мәсьәләләре иң югары баскычта каралды. Әмма илдәге икътисадый кризис предприятие төзелешен башлап җибәрү вакытына барыбер үз төзәтмәләрен кертте – мәйдандагы беренче эшләр 2011 елда гына башланып китә алды.

Ил һәм республика җитәкчелегенең турыдан-туры ярдәме әлеге гаять катлаулы мәсьәләне уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирде: завод беренче продукциясен 2015 елның июнендә эшләп чыгарды.

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович! Сезнең оештыру талантыгыз, фикердәшләрегезне үз тирәгезгә туплый белү сыйфатыгыз ихтирамга лаек. Юбилей көнендә Сезгә ныклы сәламәтлек, фикердәшләрегезнең даими ярдәме һәм уңышлар юлдаш булуын телим! Эшкә җигелгән көчегез һәм дәрт-дәрманыгыз һәрвакыт яхшы нәтиҗәләр генә китерсен!

Фотолар «Аммоний» АҖнән алынды

Реклама

Реклама

Фото «Татэнерго» АҖнән алынды

Раузил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Бәяләп бетермәслек партнёрлык

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович! «Татэнерго» АҖ коллективы һәм үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән ихластан котлыйм!

Бу – Сезнең адреска хөрмәт сүзләрен җиткерү өчен бик яхшы форсат. Сез – оста оештыру сәләтенә ия булган, өстенлекләрне төгәл билгели алучы һәм республикабыз халкының мул тормышы хакына гаять зур бурычларны хәл итә белүче җитәкче. «Газпром межрегионгаз Казан» ЯАҖнә күп еллар дәвамында җитәкчелек итеп, Сез компаниянең лаеклы инвестицион, инновацион һәм социаль сәясәтен булдыра алдыгыз.

Безнең компания республикада табигый газны төп кулланучы булып тора. Татарстанга бирелә торган газның өчтән берен кулланып, без сәнәгать төбәгенең барлык тармакларының ихтыяҗларын тәэмин итәрлек электр һәм җылылык энергиясе эшләп чыгарабыз. Нигезендә газ һәм электр энергиясе торган сәнәгать һәм социаль өлкәләр өчен бердәм технологик чылбыр булдырылды. Шуңа күрә дә республика өчен безнең партнёрлыкны бәяләп бетерү мөмкин түгел диярлек. Безнең компанияләрнең язмышлары үткән тарихта да, киләчәктә дә аерылгысыз бәйләнгән.

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович! Нәтиҗәле хезмәттәшлек елларыбыз өчен Сезгә ихлас рәхмәтемне җиткерәсем, сәламәтлек һәм күп елларга сузылырлык бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман телисем килә. Барлык эшләрегездә һәм башлангычларыгызда да уңышлар һәм илһам юлдаш булсын!

Фото «Түбән Кама ЖЭҮ» ЖЧҖнән алынды

Алексей Юмангулов,
«Түбән Кама ЖЭҮ» ЖЧҖ
җитәкчесе

Республика халкы әйбәт яшәсен өчен...

– Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович! 60 яшегез уңаеннан ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Сезнең тормышыгыз һәм профессиональ эшчәнлегегез – акыллы, инициативалы, хезмәт сөючән кешенең уңышка һәм абруйга ирешү үрнәге. Сезнең замана белән бер адымда атлап барырга омтылуыгыз, җитәкче буларак, үз хезмәткәрләрегезнең тормыш сыйфатын чын күңелдән кайгыртып яшәвегез, Татарстан Республикасы өчен прогрессив булган проектларны тормышка ашыруыгыз зур ихтирамга лаек.

Безнең предприятиеләр арасындагы партнёрлык елларында нәтиҗәле эшлекле элемтәләр барлыкка килүгә сөендерә. Монда Сезнең, «Газпром межрегионгаз Казан» ЯАҖ җитәкчесе буларак та, республиканың Дәүләт Советы депутаты буларак та, Татарстан халкының яхшы тормышы хакына катлаулы һәм күптөрле бурычларны хәл итәргә гадәтләнгән булуыгыз сизелерлек роль уйный.

Бу көндә үз исемемнән һәм «Түбән Кама ЖЭҮ» ЖЧҖ коллективы исеменнән сезгә сәламәтлек һәм уңышлар телибез. Бай тәҗрибәгез, аралашу осталыгыгыз һәм эшлеклелек сыйфатларыгыз моннан соң да Сезгә һәрдаим юлдаш булсын, яңа казанышларга гарант ролен үтәсен!

PRESSA.RU



Зирәклек һәм тәҗрибә үрнәге



Рөстәм Габделхаков,
«Казэнерго» АҖ
генераль директоры

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович!

Юбилеегыз көнендә Сезгә «Казэнерго» АҖ коллективы исеменнән бәхет һәм иминлек теләргә рөхсәт итегез. Сез бу датаны күркәм нәтиҗәләр белән каршылыйсыз. Сез җитәкчелек иткән юнәлеш Татарстанның үсеш стратегиясендә үзенчәлекле урын алып тора, киң күләмле республика проектлары тормышка ашырыла, нәтиҗәле идарә итү карарлары кабул ителә.

Казан халкы үзен йортларында һәм фатирларында гына түгел, бәлки шәһәрнең теләсә кайсы почмагында уңайлы хис итсен өчен, «Казэнерго» АҖнең тотрыклы, эшкә сәләтле коллективы, үзе оешканнан бирле, гаять зур эшләр башкара. «Казэнерго» АҖ халыкны өзлексез рәвештә җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итә, шулай ук шәһәрнең тышкы яктылыгын тәэмин итүдә ышанычлы һәм сыйфатлы хезмәт күрсәтә. Бүгенге көндә без гамәлдәге җитештерүләрне үзгәртеп коруга һәм яңаларын булдыруга, прогрессив технологияләр кертү һәм үзләштерүгә аерым игътибар бирәбез. Предприятиедә казаннарны комплекслы реконструкцияләү, автоматлаштыру һәм диспетчерлаштыру системаларын кертү, кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен модернизацияләү, шәһәрне ышанычлы һәм сыйфатлы итеп электр белән тәэмин итү буенча озак вакытка исәпләнгән күпсанлы программалар тормышка ашырыла.

Күңелле форсаттан файдаланып, Сезгә бергәләп эшләгән елларыбыз өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә. Безнең үзара нәтиҗәле хезмәттәшлегебез һәрвакыт Казан халкына уңайлы шартлар тудыруга юнәлтелгән.

Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович! Сезнең эшлеклелек һәм шәхси сыйфатларыгыз каршында баш иеп, көч-куәтегезнең киләчәктә дә ташып торуын телибез. Бүгенге көндә Сез туплаган бай тормыш тәҗрибәсе гармонияле рәвештә зирәклек һәм тирән белем белән тулылана бара, шактый эш башкарылган, ә алда – тагын да зуррак планнар. Аларны тормышка ашыру өчен сәламәтлегегез һәм дәрт-дәрманыгыз җитсен, һәм бөтен күркәм уй-ниятләрегез тормышка ашсын!

Фотолар «Казэнерго» АҖ нән алынды

Реклама

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

PRESSA.RU

МОГҖИЗАЛЫ СӘПӘЙ

Мартның карлы-буранлы бер көнендә Азнакай районының Сәпәй авылында булып кайттык. Серле дә, үзенчәлекле дә тоелды ул. Биредәге тау итәкләренә, болын куеннарына әллә никадәр могҗизалы тарих яшеренгән икән. Алар үзе бер очсыз-кырыйсыз дәрья…

Автор:
Руфия Фазылова

ТАБИГАТЬ ҺӘЙКӘЛЕ

Сәпәй – Азнакай шәһәренә орынып диярлек тора, алты гына чакрым ераклыкта урнашкан. Шуңа да җирле халык ныклы ышаныч белән: «Безнең авыл беркайчан бетмәячәк», – ди. Мондый ышанычның икенче ягы да бар: Азнакайның күп балалы гаиләләренә Сәпәйдән җир бирәләр икән. Өч ел эчендә 86 җир кишәрлеге бүленгән.

Авылда Мирфаяз Солтанов белән таныштык. Тимирязев исемендәге Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлаган зыялы, белемле кеше булып чыкты ул. Әлмәт муниципаль университетында проректор, Казан икътисад, идарә һәм хокук институтының Бөгелмә филиалында директор урынбасары, кафедра мөдире булып эшләгән. Бүген лаеклы ялда.

– Әти-әнием вафат инде, – диде Мирфаяз абый. – Алты бала үстек без. Төрлебез төрле якка таралыштык. Шулай да төп нигездә еш җыелабыз. Мин үзем авылдашлар белән аралашудан тәм табам, табигатькә чыгып рәхәтлек алам. Очсыз-кырыйсыз мәгърур таулар яшәргә көч тә, илһам да бирә кебек…

Мирфаяз Солтанов туган авылы турында китап язган. Узган елны дөнья күргән ул китап. Башта егерме еллап мәгълүмат туплаган. Әле китабы әзер булгач та, ике еллап нәшер итә алмаган. «Акчам булмады», – ди. Инде икенче китабын әзерли, анда авыл кешеләренең шәҗәрәләре тупланачак икән.

Авыл тарихы турында Мирфаяз абый менә нәрсәләр сөйләде:

– Сәпәй турында мин эзләп тапкан иң борынгы документта (Самара өлкәсе дәүләт архивында саклана) 1696 елда авылда мәчет булган дип язылган. Закон буенча, XVII гасырда мәчет салу өчен авылда, ким дигәндә, 200, ә соңрак 300 ир-ат яшәргә тиеш булган. Менә шуннан чыгып фикер йөртергә була: яңа җиргә 2–3 гаилә күченеп утырып, халык санын 200 ир-атка җиткерү өчен, ким дигәндә, 100–150 ел гомер кирәк. Шуңа күрә Сәпәй һәм якындагы башка борынгы авылларның нигезләнүе 1500–1550 нче елларга барып тоташа, дип фаразларга була.

Сәпәйнең тирә-юнен таулар чолгап алган. Иң кызыгы – биредә һәр тауның үз исеме бар: Кызлар тавы, Бүләк тавы, Сыер тавы, Әгер тавы, Мәндәй тавы һәм Чатыр тау. Соңгысы турында аерым язарга кирәктер, чөнки ул рәсми рәвештә тау статусы алган.

– География фәне критерийлары буенча ул «тау» дип санала алмый (тау статусы 500 метрдан узган очракта гына бирелә), – диде Мирфаяз абый. – Димәк, асылда Чатыр тау калкулык, сырт (возвышенность, хребет – авт.) төшенчәсенә күбрәк туры килә. Тик халык телендә барлык биеклекләр, калку җирләр «тау» дип атала. Шуңа күрә безнең авыл тирәсендә урнашкан калкулыклар да «тау» исемен йөртә. Чатыр тауның биеклеге элегрәк 321,7 метр дип исәпләнә иде. Хәзер инде аны 334, 5 метр дип язалар. Сәбәп нидә? Юкса Чатыр тау – борынгы, иске калкулыклардан исәпләнә, ул күптән үсүдән туктаган. Җавап бик гади – XXI гасыр башында биеклекне үлчи торган җайланмалар үзгәрде, алар төгәлрәк эшли башлады. Шуңа да Чатыр тау бераз «үсте»…

Фото: Александр Ефремов

Татарстан Министрлар Советы боерыгы буенча 1972 елда Чатыр тау һәм аның тирә-ягында 130 гектар җир «табигать һәйкәле» дип игълан ителгән. Ә 1999 елның июненнән башлап, Чатыр тау бу төбәктәге «Чатыр тау» Дәүләт табигать заказнигы» статусын алган. Һәм бүген тауның мәйданы 2000 гектарны тәшкил итә. Биредә Кызыл китапка кертелгән бик күп җәнлекләр яши, бу тирә-якка гына хас булган иллелән артык төр үсемлек үсә. Аларның күбесе шулай ук Кызыл китапка кертелгән. Тагын сирәк очрый торган күбәләк, таракан, кырмыскалар бар. Чатыр тауның башка могҗизалары – бакыр, малахит, азурин, нефть. Шуның белән бергә җир астыннан саф сулы чишмәләр дә ургылып чыга. Моны табигать могҗизасы дими, тагын нәрсә дияргә?!

– Халык телендә Чатыр тауда Пугачев качып яткан дигән сүзләр йөри, – ди Мирфаяз Солтанов. – Әмма бу турыда тарихи документлар табып булмады. Пугачев гаскәре белән Казан ягына барганда Уфа – Минзәлә тирәсеннән үткән. Чынлап та, бәлки андый хәл булгандыр. Чатыр тау итәгендә әле тагын без белмәгән күп тарих яшеренгән, монысы – бәхәссез.

МӘКТӘП ЮК, Ә ДИМӘК...

Авылда мәктәп юк. Гөрләп торган ике катлы, матур биналы тугызъеллык мәктәпне 2015 елда япканнар да куйганнар. Янәсе, бала саны аз. Дөрес, район җитәкчелеге, башлангыч сыйныфлар кала дигән булган. Тик әти-әниләр, үзара килешеп, башлангычта белем алучы балаларны да Азнакайга йөртергә карар кылган. Автобус укучыларны иртән килеп ала, китереп куя. Шулай итеп авылның алтмыш баласы бүген Азнакайга йөреп укый. Ә Сәпәйдәге ике катлы мәктәп бинасыннан балалар бакчасы ясаганнар.

Авылның өлкән бер апасы белән сөйләшеп тордык. Мәктәп ябылу турында зур тетрәнү белән сөйләде ул:

– Заман әллә нинди. Авыл мәктәпләренең дәрәҗәсе юк. Ата-аналар балаларын район үзәкләренә, шәһәрләргә йөртергә омтыла. Имеш, мөмкинлекләр күбрәк, шәһәрдә русча укыталар. Ә бит иң укымышлы кешеләр, иң атаклы түрәләр авылдан чыккан. Мин дә өч бала үстердем, барысы да тормышта үз урынын тапты. Сәпәй авылында мәктәп 1850нче елларда ук булган. Аны беренче һәм икенче Бөтендөнья сугышы елларында да туктатмаганнар. Ачлык вакытында да мәктәп эшләгән. Ә бүген, тыныч тормышта, тук елларда авыл мәктәпсез калды. Аңламыйм, башыма сыймый. Мәктәпсез авылның яме юк...

Бу фикерне Мирфаяз Солтанов та куәтләде:

– 2014/2015 уку елында Сәпәй мәктәбендә барлыгы 37 бала укыды. Аларга 13 укытучы белем бирде. Безнең авыл мәктәбе Азнакай шәһәренең 9 нчы урта мәктәбе филиалы булып калган иде. Шул рәвешле соңгы елларда илдә барган оптимальләштерү Сәпәй мәктәбенә дә кагылды. Авылда мәктәп ябылуның икенче сәбәбе дә бар: халыкның тәртибе. Берәүләр булса, мәктәпне ябалар дип, бөтен республикага чаң кагарлар иде, безнекеләр сөенә-сөенә балаларын укырга шәһәргә җибәрде. Сәпәй авылында сабыйлар тумый, дип әйтеп булмый. Авылда ел саен 10–12 бала туа. Ләкин бу сабыйларның күбесен ата-аналар Азнакайга йөртә, имеш, анда яхшырак. Анда 25 баланы бер тәрбияче карый, ә Сәпәй бакчасында 10 бала. Әле Азнакайга йөрүче сабыйларны җәен-кышын иртән сәгать 5тә уятып, салкын машинага чыгарып утыртып, шәһәргә алып барырга кирәк. Ә бәлки балаларны вакытында уятып, иртән әбисе яки бабасы белән әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, очраган кешеләр белән исәнләшеп, бакчага ашыкмый гына барып җитәргә кирәктер?

Авыл җирлеге башлыгы Фәния Галиева мәктәп вакытлыча гына ябылды, дип ышандырды.

– Районның күп балалы гаиләләренә бирелгән 86 участокның унысына йорт салып яталар. Бүгенге көндә ул җирләргә газ кертү өчен проект эшләттек. Федераль яки республика программасына кереп, якын киләчәктә анда газ кертербез, дип уйлыйм. Акрынлап авыл Чатыр тау итәгенә таба киңәя бара. Дөресен әйтим, Сәпәйгә яңа гаиләләр килүне бик сөенеп кабул иттек. Димәк, авылда балалар саны арта, эшче көчләр күбәя. Һәм балалар бакчасы да зураер, мәктәп тә янә эшли башлар, дигән бер ышаныч-өмет белән яшибез. Мәктәп бинасын күз карасы кебек саклап тотабыз, ул яңадан укучылар кабул итәр, иншалла!

PRESSA.RU

Радик Закиров хуҗалыгында әлегә җиде баш мөгезле эре терлек бар.

«СЫЕРЛАР АСРАРГА ДИП, ШӘҺӘРДӘН КАЙТТЫМ!»

Сәпәйдә 263 хуҗалык бар, 700 гә якын кеше яши. Авылда рәсми теркәлгән 11 шәхси эшкуар бар. Берәүләр каз-үрдәкләр ыслап сата, икенчеләр машина төзәтә, өченчеләр сәүдә эше белән шөгыльләнә. Әле менә бер гаилә пилмән, токмач ясап сатарга дип йөри икән, документлар җыялар, цех өчен урын карыйлар. Кыскасы, заман шартларына яраклашып, халык ничек тә яшәргә омтыла.

Мал асраучылар да байтак. Шуларның берсе – Радик Закиров. Берничә ел элек Азнакайдан гаиләсе белән Сәпәйгә күченеп кайткан.

– Чамасы булган кешеләр шәһәргә якын җирдә йорт салырга тырыша бит хәзер, – диде Радик абый. – Саф һава, ыгы-зыгы юк дигәндәй. Шул ук вакытта шәһәр цивилизациясеннән дә читтә калмыйсың. Уйлаштык та туган авылга кайтырга булдык. Яңа тормышны котлап, шушы көннәрдә генә дүртенче балабыз – улыбыз туды. Ә оныкка ике яшь…

Радик Закиров хуҗалыгында әлегә җиде баш мөгезле эре терлек бар. Планнары исә зурдан – КФХ булып теркәлеп, ферма төзү. Инде документлар артыннан йөри башлаганнар.



– Сыерларны үзем карыйм, – диде Радик абый. – Саву аппараты белән савам, аның авырлыгы юк. Хатын балалар, өйдәге эшләрдән бушый алмый.

– Быел сөтнең бәясе төште, сыер асрау үз-үзен аклыймы соң? – дим.

– Малларны яраткач, файдасы турында уйламаска тырышам. Аларга нык ияләндем, гаилә әгъзалары кебек. Аннан, эшли башлаганда гына бер эш тә акча китерми. Булыр дим, Алла боерса. Күңелдә фермер булу теләге күптән бар иде, эшләп карыйсым килде. Алга таба күз күрер, үкенеч булып калмасын. Әле менә дәүләт бер сыерга өч, ике сыерга дүрт, өч сыерга биш мең сум акча бирә, шуларга документлар җыйдым. Ул акчалар кайтса, янә бер файда була, иген алырмын, дим. Малларга азыкны сатып алам. Әлбәттә, күп кирәк. Тик нишлисең, без булмаган җирдә генә рәхәт ул.

Радик Закиров, чын ирләрчә, бер дә зарланмый. Бар күңеле белән фермерлык эшенә мөкиббән киткән. Нефть чыгару өлкәсендә дә хезмәт куйган, аннан шәхси эшкуар булып тәзелеш белән дә шөгыльләнгән. Менә хәзер, үзе әйткәнчә, «җанлы бизнес»ка килгән. Аның өчен монысы иң рәхәте икән. Тик тормыш иткәндә, балалар үстергәндә җан рәхәтеннән тыш, акча да кирәк шул. Радик абыйның теләк-ниятләре кабул булыр, фермерлык эшеннән күңеле кайтмас, дип ышаныйк.

«АВЫРУЛАР САНЫ АРТТЫ»

Сәпәйгә баргач, Азнакайның «Нефтемаш» заводына да сугылдык. Бирелә бөтен республика өчен кызгылт-сары төстәге атаклы ФАПларны ясыйлар. Алар хәзер һәр районда бар. Завод бу эш белән 2012 елдан бирле шөгыльләнә. Халык санына карап, корылмаларны ике төрле проект белән эшлиләр. Авылда яшәүчеләр 800 кешедән артса – 83,3, азрак икән, 62,5 квадрат метрлы бина салына. Завод ФАПларны тулаем эшләп чыга: бинаның тышкы һәм эчке ягын тышлау өчен төзелеш материаллары әзерләнә, каркасы ныклы металл эшләнмәләрдән коела. 2012 елдан бирле заводта 400ләп ФАПны әзерләп тапшырганнар инде. Моннан тыш бирелә ветеринария өчен бөтен кирәк-яракны үз эченә алган вагон-булмә, автолавка һәм башка күп төрле корылмалар әзерләнә.

Андый корылмаларның икесе – медицина пункты һәм авыл

Шушы авылда гомер итүче Галия апа Хәева яңа ФАПка сөенеп бетә алмавын сөйләде.

җирлеге идарәсе бинасы – Сәпәйгә дә кайткан. Узган ел китереп куйганнар. Халык аеруча медицина пунктына сөенгән, чөнки әлегә кадәр авырулар салкын, иске клуб бинасына йөргән.

– ФАПыбыз яңа булгач мөрәҗәгать итүчеләр саны бермә-бер артты, – диде фельдшер-акушерлык бүлеге мөдире Зөлфия Динмөхәмматова. – Бүген 665 кешегә хезмәт күрсәтәбез. Җирлектә 18 яшькә кадәрле 108 бала исәпләнә. Шушы көннәрдә тагын өч нарасый дөньяга килде.

Яңа медицина пунктына Азнакайдан башка табиблар да килә икән. Шушы авылда гомер итүче Галия апа Хәева яңа ФАПка сөенеп бетә алмавын сөйләде:

– Җылы, рәхәт. Бөтен уңайлыклары бар. Кан басымын үлчисеңме, йөрәкне яздырасыңмы. Күбебез табиб ярдәменә мохтаҗ. Авылда медпунктларны, фельдшерларны бетерә күрмәсеннәр, бөтен җирдә оптимальләштерү барганда, шунысына борчылабыз. Хәзер авыл картая, безгә шәһәргә, районга барып йөрү бик кыен. Терапевтка барып күренеп кайтабыз да биргән уколларны биредә ясатабыз. Кан басымын үлчәтергә дә йөрибез. Олы кешенең төрле вакыты була бит.

...Сәпәйдә борынгыдан килгән күркәм йоланы яңартканнар – Чатыр тауның көньяк итәгендә агучы Изгеләр чишмәсе янына барып «изге чәй» эчәләр.

– Иң беренче мәчет картлары белән киңәшләштем, – ди Фәния Галиева. – Алар фатиха бирде. Шулай итеп ике ел рәттән җәй уртасында борынгыдан килгән йоланы билгеләп үттек.

Изгеләр чишмәсе буенда башта өлкәннәр Коръән укып, дога кыла икән. Балалар исә төрле уеннарда катнаша, кызлар милли киемнәр киеп, су ташу буенча ярыша. Җыр, бию – ул көнне Чатыр тау гөрләп тора. Самоварлар кайный. Яшьләр белән картлар аралаша. Соңыннан бөтен халык табын янына җыела. Изге чишмә суы белән чәй эчәләр. Шуннан бар халык өйлә намазы укый, теләк тели. Мәҗлес тәмамлангач, өлкәннәрне машиналарга утыртып, өйләренә озаталар. Сәпәйлеләр Изгеләр чишмәсе янындагы бәйрәмне быел да уздырырга җыена. Теләге булган һәркемне чакырып калдылар.

«Туган җирем Кайбыч районы Кошман авылында Утташ чаты, Уңар үзәнлеге, Гәрәй талы басуы, Шәрәп борыны, Сәет бабай үзәне, Изге кыз каберлеге, Керәшен зиратына бәйле кызыклы риваятьләр, телдән-телгә сөйләнеп, буыннан-буынга күчеп, бүгенгәчә яшәп килә», – дип язды безгә күптәнге авторыбыз Хәмидә Гарипова. Бүген шуларның тагын берсе белән сезне дә таныштырып үтәбез.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: ШӘРӘП БОРЫНЫ

Кошман авылыннан Кордонга таба бара торган юл буендагы Маш асты басуында Шәрәп борыны дигән куркыныч урын бар. Аннан кояш баткач узган юлаучылар басу өстендә утлы шарлар биешкәнен, капюшонлы кожан кигән, бите коточкыч ямьсез, күз чокырлары янып торган, борынсыз, ике аяксыз адәм кыяфәтендәге өрәкнең игеннәр өстеннән очып яки кыр буйлап ары-бире чабып йөргәнен күреп, әлегәчә өннәре алына.

Кем соң ул Шәрәп? Нилектән аның рухы тынычлык таба алмыйча кешеләрне бимазалый?

Революциягә чаклы Кошман Зөя өязенә кергән кантон үзәге булган. Иген игеп, мал-туар асрап, кирпеч сугып көн күргән татар авылына әллә кайдан бер зимагур кайтып урнаша.Үзен сыендырган халыкка рәхмәтле буласы урынга, мал-туар урлап, күпләрнең канына тоз сала ул. Беркөнне ул каяндыр чандыр гәүдәле, моңсу күзле ятим малай ияртеп кайта. Хезмәтчесен үзенең гөнаһлы шөгыленә өйрәтә башлый. Шәрәфи киреләнсә, аяусыз кыланып, чыбыркы белән яра. Малай исәя төшкәч, мәҗбүриләп үзе белән ат урларга йөртә башлый. Еллар уза, Шәрәфи егет булып җитешә. Аның бу кансыз зимагурның коллыгыннан котыласы килә. «Газыйм абзый, унбер ел сиңа бил бөктем, бөтен авыр эшеңне башкардым. Рәхмәт, ачлыктан үтермәдең. Миңа үз куышымны җиткерергә, башлы-күзле булырга вакыт. Яхшылык белән җибәр мине. Күпкә өмет итмим, аякка басу өчен бераз акча бир», – ди ул.

Хәйләкәр зимагур: «Ярар, синеңчә булыр. Тик әүвәле Канаш баеннан миңа ике, үзеңә бер нәселле чабышкы урлап кайтыйк. Атка атланып китсәң, тизрәк тернәкләнерсең», – ди. Хуҗасына буйсынган кол бурлыкка берничә мәртәбә бара, тик вәгъдә ителгән аргамакларның берсе дә аңа тәтеми. Хуҗа тулпарларны йә чегәннәргә аткара, йә суеп сата. Өмете киселгән егетнең моңа җен ачуы чыга. Ул хуҗасының күзенә туры карап: «Караклыгың турында өяз башлыгына хәбәр итәчәкмен!» – дип әйтеп сала. Кансыз бәндә егетне башына сугып миңгерәйтә, гәүдәсен ат арбасына чыптага төреп салып, ерак басуга – Маш астына алып чыгып китә. Канга баткан егет басу уртасында җан бирә. Аның авылда күренмәвен яхшыга юрыйлар, вәхши тырнагыннан качып котылуына сөенәләр. Чынбарлык урак өстендә ачыклана. Бер тол хатынның чалгысы зыңгылдап каты әйбергә барып керә. «Күз карасыдай кадерләп саклап тоткан үткен чалгымны ташка бәреп харап иттем, кылны кырыкка ярырлык чагымда, ике кулсыз калдым?» – дип такмаклап елый фәкыйрь хатын. Чалгысын тартып ала алмый изалангач, ярдәмгә күршесен чакыра. Баш сөягенә кадалган чалгыга ияреп, Шәрәфинең ярымтаркалган гәүдәсе җирдән күтәрелә...

Ат урлап кайтып, зират өстендә суеп, тунап маташкан Газыймны чувашлар эзәрлекләп килеп, күсәкләр белән кыйнап үтерә. Ниһаять, авыл иркен сулыш ала, Шәрәп борыны турындагы риваять тарихка кереп кала.

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Бөгелмә. Тимер юл вокзалы. 2018 ел.

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА
БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Бөгелмә. Тимер юл вокзалы.1963 ел.

Фото www.bugulma.ws сайтыннан алынды

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ